1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 ФЕВРАЛЬ № 2

Сөембикә

МАЛАЙЛАР ЕЛЫЙ БЕЛӘМЕ?
әти-әниләргә киңәш

МИН АЧКАН АНТАРКТИДА
мәңгелек боз илендә

АЙГӨЛ ГАРИЕВА СЫЙЛЫЙ
итле «кабартма»лар

Лилия ЯРУЛЛИНА:

«МИН КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНАМ»





70
1945–2015

Сугыш язган хатлар

«Әллә өнем, әллә төшем, / Әтием белән күрештем...» Тирә-күрше апалар урамда очраган саен кечкенә Рузаниянең җырлавын сорыйлар, ә үзләре гел күз яшьләрен сөртәләр... «Әтиең китәргә дип чыккач: «Мин бит төпчек кызымны кочмадым!» — дип капка төбеннән кире борылып керде», — дип сөйли торган була әнисе. Әтиләреннән дүрт бала кала алар. Иң кечкенәсенә — яшь ярым, яңа тәпи атлап киткән чагы... «Әтигә җибәрергә дип фотога төшкән идек. Өлгермәдек... Үлгән хәбәре килде. 1943 елның көзе иде ул...» Нурия апага бу вакытта тугыз яшь, сеңлесенә караганда аңарда хатирәләр күбрәк. Әтисенә язган җырларына кадәр истә. «Фронттан килгән бу хатлар әни өчен әтидән калган иң кадерле истәлек булды. Аларны укыган саен безгә сиздермәскә тырышып елый иде...» — дип сөйли Нурия апа.

Хәбәрләшү

Дустым Хәдичәгә Нуретдиннан бик сагынып сагынычлы сәлам язып калам. Һәм дә кызым Зәйтүнәгә бик сагынычлы сәлам. Һәм дә Нуриягә эткәеңнән сагынып сагынычлы сәлам. Һәм дә кызым Рузаниягә сагынып сагынычлы сәлам. Һәм дә улым Наилгә сагынып сагынычлы сәлам. Һәм дә этиләргә барча җәмәгатьләре белән аермаенча сагынычлы сәлам. Һәм дә тирә-күршеләргә барчасына сагынычлы сәлам. Үзем исән-сау. Һәм сезләрне дә шулай дип беләм. 3 сентябрьдән бирле фронтта без. Бүген исәнлегебезгә куанабыз. Янәдән ике иптәшебезнең берсе үлде. Һәм дә үзегезнең 26 нчы октябрьдә һәм 30 нда язган 2 хатыгызны бер көнне алдым 22 ноябрьдә. Һәм шул ук вакытта мин сезгә язып салам исәнлек хәбәремне. Моннан элек тә күп хатларны язып салдым. Наил белән Нуриягә бишәр сум хат эченә тыгып җибәргән идем. Алдыгызмы? Мин элеккеге хатларга посылка салыгыз дип язган идем. 25 октябрьдәге ахыргы хатны алмагансыз. Алгач бияли, оекбаш һәм булса берәр .... ярап китәр иде. Тәмәке һәм ашарга кирәкми, җитә, ач түгел. Ул яктан кайгырмагыз. Но исән-сау кайтып, сезнең белән күрешергә ходай насыйп итәрме? Бүрек тә сораган идем, бүрек кирәкми хәзер. Посылка салсагыз, действуюший армиягә 5 кила мөмкин. Үземнең исемгә салырга, 1 нче январьга кадәр алалар. Посылкагызны бик таза ящик ясап, тышлатырсыз. Ярый, минем башка язар сүзем юк. Хуш сау булыгыз. Сездән хат көтеп калам. Яздым 22/ XI - 42 ел.

Наил белән Нуриягә тагын сагынып бик күп сәлам.

Әй илләрем, илләрем,
Илләрем, бәгырьләрем.
Герман җирләрендә
Булмасын каберләрең.

Наил, син әйткәнсең, ник кайтмыйсың дип, мин фашистларны бетергәч кайтам, син зур үсәрсең инде мине каршы алырга.

Рядовой Нуретдин САФИНның бу хаты Кайбыч районы Борындык авылында яшәүче кызы Нурия апа Шәмсетдиновада саклана. Хатны үзгәртмичә-төзәтмичә тәкъдим итәбез.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!





© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2011 елның 23 мартында «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы ПИ № ФС 77-44363



2007, 2008, 2009 елларда журнал Россия матбугатының Алтын фондына кертелде.

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа»
ачык акционерлык җәмгыяте
Казан,
Академия урамы, 2.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рафикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны	222-09-77
Директор урынбасары	
Рәмзия Кашапова	222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары	
Гөлнур Хәсәншина	222-09-78
Җаваплы сәркатип	
Лариса Маликова	



Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламалар аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова
Pre-press:
Игорь Глушков

Тышлыкта:
Лилия Яруллина
Фото: Газинур Хафизов

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Роза Камалетдинова
Асия Юнысова
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы: 73002

Нәшер итүченең адресы: Казан, Академия урамы, 2, ААҖ «Татмедиа».

Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Күләме 8 басма табак.

Басарга кул куелды: 13.02.2015 ел.
Заказ О-346.
Тираж 7663

ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы булышлыгы белән гамәлгә куелды

Журналны тарату мәсьәләләре белән абунәчеләр – җирле элемтә бүлегенә; элемтә бүлекләре – нәшриятның газета-журнал экспедициясенә (420066, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. Тел.: 562-10-66) мөрәҗәгать итә ала.

Банк реквизитлары:
Филиал ОАО «Татмедиа»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Журналда полиграфия кимчелеге булган очракта нәшриятның техник контроль бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Тел.: 519-44-61.

Сату бәясе – килешү буенча.



Армиядә хезмәт итү ирләр шөгыле ул дигән фикергә күнеккәнбез. Ләкин кайбер закон чыгаручылар «хәрби хезмәткә җәлеп итү мәсьәләсендә» арырак адым ясарга, ягъни «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы канунга тиешле төзәтмәләр кертергә карар кылдылар. Шундый тәкъдимне депутат Татьяна Москалькова кертте. Әлегә хатын-кызларга хәрби комиссариатка чакыру кәгазьләренең килгәне юк, чөнки төзәтмәләр канунда беркетелмәгән. Шулай булса да, РФ Кораллы көчләрендә 50 меңләп хатын-кыз хезмәт итә инде, шуларның 3 меңе – офицер чинында.

Дәүләт Думасындагы депутатларыбызның соңгы закон чыгару инициативалары уйландыра.




Димәк, 18 яше тулган кешегә икенче кешене үтерергә рөхсәт ителә, әмма 21 яшең тулмаган килеш аракы эчәргә ярамый. Иң башта, һичьюгы, бу саннарның урыннарын алыштырып кую дөресрәк булмас идеме икән?

ХАТЫН-КЫЗЛАР ҺӘМ КОРАЛЛЫ КӨЧЛӘР

ОБЪЕКТИВ КАРАШ

Үзегезнең улыгыз, абыегыз, ирегезнең (хатыныгызның) армиядә хезмәт итүен теләр идегезме (Россия, 2014)



Хатын-кыз армиядә хезмәт итәргә тиешме





ИЗРАИЛЬ
хезмәт итү | 21 ай
1959 елдан башлап
18-24 яшьлек, кияүдә булмаганнар
33% хәрби хатын-кызлар

ТӨНЬЯК КОРЕЯ
хезмәт итү | 7 ел
2003 елдан башлап,
18 яшьтән алалар,
22% хәрби хатын-кызлар

АКШ
контракт нигезендә хезмәт итү
1948 елдан башлап,
14,5% хәрби хатын-кызлар

ИТАЛИЯ
контракт нигезендә хезмәт итү
1999 елдан башлап
11% хәрби хатын-кызлар

ГЕРМАНИЯ
контракт нигезендә хезмәт итү
1975 елдан башлап
8,9% хәрби хатын-кызлар

ПАКИСТАН
контракт нигезендә хезмәт итү
2006 елдан башлап
5% хәрби хатын-кызлар

Ә менә Грециядә яшь егетне иң элек бик озаклап сәнгать төрләренә, Геродоттан өзекләрне яттан сөйләргә өйрәткәннәр.



Аннары ул өйләнгән, 10-11 балага ата булган, өй салган, агач утырткан. Шуннан соң гына аңа сугышка китәргә, дошманнарга каршы көрәшергә рөхсәт ителгән. (!) Бик акыллы сәясәт!



Жанна д' Арк
Франциянең милли каһарманы, Йөзъеллык сугышта гаскәр башлыкларының берсе. Еретик дип хөкем ителә, учакта яндырыла. Аннары изгеләр рәтенә кертелә.



Надежда Дурова
1812 елгы Ватан сугышы каһарманы. Полкка ир-ат киеменә киенеп килеп керә. Смоленск һәм Бородино янындагы сугышларда зур батырлыклар күрсәтә.



Мәгубә Сыртланова
46 нчы Тамань гвардия хатын-кызлар авиация полкы командиры урынбасары. Советлар Союзы Герое. 1942 елдан башлап 780 хәрби очыш ясаган.



Хәрби кешегә кияүгә чыгу әле кайчан гына зур бәхет дип санала иде. Погонлы ир-атларның патша режимы вакытында да, совет власте елларында да дәрәҗәсе зур булды. Һәр ике чорда да матди тотрыклылыктан тыш, хәрбиләрнең белемле саналуы, намус һәм абруй кебек сыйфатларга ия булулары да бәяләнде.

77% Россия хатын-кызлары үзләренең киләчәген хәрби кеше белән бәйләргә каршы түгел. Соңгы сораштыруларның нәтиҗәсе бу. Ни өчен дигәндә, алар түбәндәгечә җавап бирә:

46% хәрбиләр – чын ир-атлар!
12% хезмәт хаклары әйбәт
10% гел сәяхәт итү мөмкинлеге бар
9% фатир мәсьәләсе җиңел хәл ителә

Баш мөхәррир сүзе



Юк, кирәкми! Хатын-кызның урыны армиядә түгел! Әйе, илгә афәт килгәндә, ул ирен дә, улын да, кызын да сафка бастырыр, үзе дә, ир-егетләрне уздырып, дошманга каршы күтәрелер, соңгы кан тамчысын бирер. Ә тыныч вакытта соң аның кулына – корал, күңеленә кургаш салу нигә кирәк? «Нәфрәт өчен – бер, ярату өчен икенче йөрәк булалмый». Бу сүзләрне Бөек Ватан сугышында яшьлеген, садәлеген калдырган, иң якты хисләрен һәм иң ихлас ышанычларын канга манып кайткан хатын-кыз әйткән. Светлана Алексиевичның фронттан исән әйләнеп кайта алган хатын-кызлар белән әңгәмәләреннән төзелгән «Хатын-кызлар сугышта: сөйләнми торган чынбарлык» китабыннан өзекләрне без тетрәнеп укыдык. Сезгә дә, бәлкем, әле укытырбыз – бу тарихларны кабул итәргә әзер булсагыз. Чынлап та, бу хакыйкатьне аңлап, чамалап булса да, бу – без белмәгән һәм белергә дә теләмәгән әрнүле, куркыныч, аяныч чынбарлык. Хатын-кызны, солдат итеге кигертеп, пычрак землянкаларга, канлы үлем кырына ыргыткан сугышның чын йөзе бу. Вәхши йөзе. Бу хакта алар сөйләргә теләми. Ләкин бу мәхшәр аша Җиңү хакына узган алар. 800 меңгә (ә бәлки, күбрәктер дә) якын хатын-кыз фронтта сугышкан. Калганнары сугышка үз ясакларын түләгән. Кайтарылмаслык. Онытылмаслык. 70 ел узып та кичерелмәслек. Аларның һәркайсы каһарман. Һәркайсы һәйкәлгә лаек – нәфис куллар граната алырга мәҗбүр булган кыз да, пулялар астыннан яралыларны ташыган мәрхәмәтле сеңел дә, бар баласын сугышта югалткан ана да, ирен көтеп ала алмаган хатын да...

Төзәлмәслек ертык яралар, төзәтелмәслек ватык язмышлар безнең ил тарихында гына калмаган. Берничә бестселлер авторы Джоджо Мойесның «Кәләшләр корабы» китабы да шул теманы күтәргән икән. Икенче Бөтендөнья сугышы чорында солдатларга кияүгә чыгып өлгергән кызларның, үз илләрен, туганнарын бөтенләйгә ташлап, ниһаять, кияүләре белән кавышыр өчен хәрби корабта Австралиядән Англиягә китеп барулары турында. Безнең хатын-кызларыбызның күргән-күтәргәннәре белән чагыштырып булмаса да, бу да җиңел сәфәр түгел. Сугыш беркемне дә аямый. Хатын-кызны бигрәк тә. Булмасын! Җитәр! Кирәкми!!!

Ләйсән ЮНЫСОВА







БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

ИРТӘГӘНЕ УЙЛАП...
Э. Мәҗитова

8





ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



12
КӘШӘКӘЛЕ КЫЗЛАР
Ф. Мостафина

18
АВЫЛ БЕТМӘС, ЯШӘР УЛ!
М. Авзалова



22
СИН БУЛГАНДА...
М. Кашапова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





26
БАР УЛ СИН ЭЗЛӘГӘН КЕШЕ...
Г. Хәсәншина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



36

ГАШЫЙКЛАР БҮЛӘГЕ
О'Генри

ЯШӘЕШ 

48



ЯЛГЫШЛАРЫМ – УРМАН...
Л. Камалиева



54

АНТОН РАЙХШТАТ: «АНТАРКТИДАНЫ АЧТЫМ!»
Э. Закирова

ШУЛАЙ УК: 

МАЛАЙЛАР ЕЛЫЙ БЕЛӘМЕ? — 16
Л. Гәрәева

ЧИГҮЛЕ КҮЛМӘК — 34
Ф. Яруллин

АВЫЛЛАР ИПИ КӨТӘ — 42
Г. Сафиуллина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

58



АЛТЫН-КӨМЕШ КЕНӘ ДИМӘГӘН...

##ҺӘР САНЫБЫЗДА: 

БЕЗНЕҢ ПОЧТА — 6

ДӨНЬЯ ГАМЕ — 21

ШИГЪРИЯТ — 32

БЕР ҖЫР ТАРИХЫ — 40

РӘССАМ СӘХИФӘСЕ — 64







Татар милләтен дөньяга танытkан шәхесләр дигәндә, *Салих Сәйдәшевне, Габдулла Тукайны, Муса Җәлилне, Илһам Шакировны атар идем.*

Танылган музыкант, СССРның халык артисты Мстислав Ростропович Илһам Шакировның «Кара урман» җырын ишетеп шакката, җырчыны өенә кунакка чакыра. Татар җырының аһәңен ил җитәкчеләре Н. Хрущев, А. Косыгиннар Илһамнан ишетәләр. Китапларда, матбугат битләрендә күңелләрне әсир иткән сихри моң иясе турында йөзләрчә язма басылып чыга. Сарман районында яшәүче шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Дамир Гарифуллин сүзләренә язылган «Чыгарсыңмы каршы алырга» җыры (Валерий Әхмәтшин көе) Илһам Шакиров башкаруында узган гасырның 70 нче елларында һәр мәҗлестә генә түгел, бәлки, чит илләрдә дә яңгырагандыр. Татарстанның элекке җитәкчесе Фикрәт Табеев аны Япониядә ишетеп кайтуы турында да әйтә.

Илһам Шакиров исеме һәр татар кешесенең җанына сеңгән. Әле миңа 10 яшь тә тулмаган чагымда, авылга Илһам Шакиров килде. Күрше малае белән без, бөтен халык белә торган кеше нинди икән соң ул, дип, аны күрергә урамга чыктык. Озак көтәргә туры килмәде: клуб белән кибет арасындагы юлда бик ыспай киенгән бер абый, безне туктатып, исемнәребезне сорады. Без мулла кушкан исемнәребезне атадык: мин – Хәкимулла, миннән бер яшькә кечерәк дустым – Мирхафизан. «Карале, чын татар исемнәре, чын татар авылы икән бит бу, – диде ул. – Ә мине беләсезме?» – диюгә, ашыга-кабалана исемен атадык. Узган гасырның 60 нчы елларында бу исемне Юрий Гагаринны белгән кебек белә идек.

1997 елның гыйнварында «Казан» шифаханәсендә Илһам Шакиров концерты булды. Шунда ял итүчеләр арасыннан безнең белән аралашып йөргән берәү сәхнәгә менде дә халык җырларын баянга кушылып матур гына итеп җырлый башлады, ахырда Илһам Шакиров белән дә бер җыр башкардылар. Бу кеше мәшһүр җырчыбызның бертуган абыйсы Кыям Шакиров булып чыкты. Шуннан соң Кыям аганы ял итүчеләр, нишләп атаклы җырчының туганы булуыңны әйтми йөрдең, дип, тинтерәтеп бетерделәр.

Сүземнең ахырында Илһам Шакировның 80 яшьлек юбилее мөнәсәбәте илә тәкъдимем бар. Гадәттәгечә, шау-гөр килеп узар ул, бәлки, телевидение аша туры эфирдан да күрсәтелер, машина ачкычы да тапшырылыр. Яшь башкаручыларга татар җырын башкару эталоны Илһам Шакиров икәнлеген раслау өчен болар гына җитми, минемчә. Олуг шәхескә хөрмәт күрсәтеп, милләтне зурлау форсаты да чыгып тора бит, җәмәгать. Ничек итеп дигәндә, аңа «Россия Федерациясе Хезмәт Герое» исемен биреп. Ил Президенты указы нигезендә мондый югары исем 2013 елда гына булдырылды. Татарстанда беренче булып бу исемгә Илһам Шакиров лаек булса, моңа беркем дә гаҗәпләнмәс иде.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.
Азнакай.
(Җәүдәт Ситдыйков фотосы)

Үз өебезне җиткергәнче, безгә әниемнең әнисе – Фәгыйлә әбиемнәрдә яшәп торырга туры килде. Читән коймалы, озын сәкеле иске өй иде ул. Әбием үзе Әлмәттәге улы – төпчеге Җәүдәт абыйларда яшәде.

Хәзер инде үземнең яшем илледән узып бара, әбием дә, Җәүдәт абыйлар да дөньялыкта юк. Нигеземне сагынам дип, әби кунакка еш кайта торган иде. Бу 1970 нче еллар. Миңа сигез яшь. Әбием чисталык ярата. Кунакка кайткач, иң элек дөбердәтеп өйләрне җыештырып чыгара. Ул кайтса, безгә бәйрәм. Өйләр нурлана, тәмле ризыклар пешереп, безне сыйлый. «Кыз баланың бәхете чиста өйдән башлана», – ди иде әбием. Әбием тарихның тере шаһиты иде. 1911 елда шушы авылда туган, шунда яшәп картайган. Олыгайса да, хәтере әйбәт иде. Яшьлек елларында авылыбызда укып белем алуын, мәдрәсәдә гарәпчә укырга-язарга өйрәнүен, латин әлифбасын өйрәнүен сөйли торган иде. Ләкин без аның сүзенә әллә ни илтифат бирми торган идек. Янәсе, сезнең белем белеммени ул, менә безгә совет мәктәбендә генә дөрес белем бирәләр. Әбиемнең китап киштәсендә гарәп хәрефләре белән язылган

китаплар күп иде. Без, замана балалары, аларга әйләнеп тә карамадык. Әбием бер кайтуында аларның барысын да җыеп алып китте.

Заманалар үзгәрде. Диннең дә кешегә бик кирәк булуын, бер дә искелек калдыгы түгеллеген аңладык. Һәр ел, көз җиткәч, үзем кебек ханымнар белән дин гыйлеме алырга дип, мәдрәсәгә җыелабыз, гарәп телен үзләштерәбез, гарәпчә укырга-язарга өйрәнәбез. Әмма бер нәрсә күңелне борчый: арабызда яшьләр бик аз. Яшьләр турында сүз чыккач, тагын бер нәрсәне әйтәсем килә. Телевизорны кабызсаң, ачыктан-ачык әхлаксыз тотнаксызлыкны, зинаны пропагандалаучы фильмнарга юлыгасың. Яшьләр бик яратып карый аларны. Әмма болардан нәрсәгә өйрәнә соң яшь буын?! Егетләрнең, нәсел айгыры сыман, әле бер кыз, әле икенче кыз белән мәхәббәт уйнап йөрүләре, кызларның бай кесәле ирләр «аулавы», һәм шуларны уңай герой итеп бирүләре – замана фильмнарының төп эчтәлеге. Тугрылыкны, саф хисләрне чагылдырган кинолар күбрәк булсын иде ул.

Бүгенге көндә авылларда яшәүче өлкән яшьтәге абый-апалар да, егыла-бетә, татарчага тәрҗемә ителгән сериаллар карый. Геройларның исемнәре үк колакка ятышсыз булса да, татарча булгач, йотлыгып карыйлар. Үзебездә төшерелгән яхшы, тирән эчтәлекле фильмнар булса, үзебезнекен карарлар иде. Юк бит андые. Исемнәре гасырлар эчендә югалган үз каһарманнарыбыз турында, милли тарихыбызны чагылдырган, үзебез белән горурланырлык булсын иде алар. Халык татарча нәфис фильмнар көтә.

Гөлсинә ТӨХБӘТУЛЛИНА.
Чаллы.

Безнең якта әбиләр теләк теләгәндә: «Ходаем, ут хәвефеннән сакла, бурдан кала, уттан – юк», – диләр иде. Бик дөрес теләгән алар. Гомер буе тырышып төзегән йорт-җиреңнең мизгел эчендә янып көл булуын күрергә берәүгә дә язмасын икән.

Бу хәсрәтне узган ел үзебез татыдык – 10 ноябрьдә Биектау районы Мәмдәл авылында яшәүче әти-әнием – Сания һәм Мөхәммәтгали Мусиннар хуҗалыгы тулысынча янып бетте. Әнигә – 81, әтигә 82 яшь. Алар энем Илгиз, киленебез Энҗе белән яшиләр иде. Янгын лапастан чыккан. Әтинең малларны ашатып-эчертеп йөргән чагы булган. Төтенне күреп, энемне чакырып чыгарган. Икесе сүндермәкче булып караганнар, тик ул арада кипкән печәнгә ут кабып, бөтен җир дөрләп яна башлаган. Янгын сүндерү машиналары да килгән килүен, бернәрсәне дә коткарып кала алмаганнар. Абзар эчендәге бар терлек-туар – атыбыз, танабыз, ике бозау, унбер баш сарык кычкырып янган. Хәтта этебез дә чыга алмаган. Янгын сүндерәм дип, үзенең дә битләре, куллары пешкән энем Илгиз, ут эчендә басып торган атның мөлдерәмә тулы күзләрен искә төшереп, ачыргаланып елый. Әле ничек үзләре исән калган?! Андый чакта кеше бик каушый бит ул. Абзар яна башлагач та, өйдәге әйберләрне коткарып калырга мөмкин булган әле. Соңыннан энем белән килен: «Өйгә йөгерешеп керәбез дә, нәрсәгә тотынырга белмичә, йөгерешеп чыгабыз», – дип сөйләделәр. Бер иске микродулкынлы мич белән, телевизорны гына алып чыга алганнар. Гомер буе җыйган мал-мөлкәт, кием-салым, хәтта документлар да ут эчендә калган. Әле алай гына да түгел, күршедә яшәүче туганнарыбыз йортына да ут кабып, шактый зыян салган. Безнең ихатадан кисәү башлары белән көл генә калды. Әти белән әнинең өсләрендә бер кат иске күлмәк, аякларында – мал арасында кия торган иске галош. Алар хәзергә миндә яшиләр.

Янгыннан соң калган кисәүләрне, җимерекләрне, үлгән хайван үләксәләрен көч-хәл җыештырдык. Андый чакта кешеләр ярдәменнән башка булмый. Эшкә тотыныйм дисәң, бернәрсә юк – ни көрәгә, ни сәнәге... Ирем белән мин, килен белән энем тик әйләнеп йөрибез йорт урынында. Кузгатып карыйбыз – көч җитәрлек түгел. Авыл җирлеге башлыгына шалтыратып, трактор бирүләрен, ярдәмгә кеше җибәрүләрен сорадым. Рәхмәт яусын, килделәр, булыштылар. Әти ничә еллар рәттән өйне иминиятләштерә торган иде, ике ел элек бу эшен ташлады. Иминиятләштергән булсак, азмы-күпме акчасы булыр иде, болай бары тик үз көчебезгә генә таянырга кала. Йорт кадәр йорт салырга җитәрлек акчаны каян табасың инде? Дөрес, Биектауның социаль яклау бүлегеннән утыз мең, район хакимиятеннән ун мең сум акча бирделәр. Ул гына җитми шул. Әти, бичаракаем, аптыраганнан, халык арасына хәер сорарга чыгып китте. Үзе ояла, гарьләнә. Халыкның да төрлесе бар бит. Шулай да татар авылларында иманлы кешеләр күп икән, кем илле, кем йөз сум булса да бирә, буш чыгармый, ди. Бик зур рәхмәт аларның барысына да. Беркөнне Лаеш районы Имәнкискә авылында берәүләр егерме мең сум акча биреп чыгарганнар. Куып чыгаручылар да бар. Әтне куган кебек, җилтерәтеп чыгаруларына гарьләнеп, үксеп-үксеп елый әтием. Картайган көнемдә болай йөрермен дип уйладымыни соң ул? Йөрмичә дә булмый. Казанда яши алмый шул ул авыл кешесе. Үзебезнең нигездә кечкенә генә булса да бер йорт салырга хыялланa әти. Бу хатны язуымның да сәбәбе – шул. Миһербанлы, мәрхәмәтле кешеләр безгә бераз булышмаслар микән? Тамчыдан күл җыела диләр бит. Зинһар, ярдәм итегезче. Телефон номерым: 8-987-424-26-80 – «МТС» операторыныкы. Акчаны шушы номерга да салып була, банкта исәп-хисап счетым да бар.

Алдан ук бик зур рәхмәтемне әйтеп,
Филсинә ГАЛЛӘМОВА.
Казан.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: suyumbike@telebit.ru

БИЗМӘН ЙОЛДЫЗЛЫГЫННАН УЛ. ҺӘРЧАК ҺӘРНӘРСӘНЕ БИЗМӘНГӘ САЛЫП КАРЫЙ ТОРГАН.

Кешеләргә мөнәсәбәтне, кылган эш-гамәлләрне, уй-максатларны, тырышлыкны, хис-кичерешләрне... Холкындагы һәр халәт, һәр үзгәреш, салават күпере төсләре кебек балкып китеп, аны тагын да тирәнрәк ача төсле.



Эльмира МӘҖИТОВА

ИРТӘГӘНЕ УЙЛАП...

«Сезне яратабыз!»

...Кулына сары розалар бәйләме тотып, «Булдыралар! Акыллы шул алар!» – дип сөйләнә-сөйләнә, сөенечтән балкып килеп кергән чагына эләктем. «Әле генә бик катлаулы диплом эшләрен якладылар! Мин шуннан... – диде ул соклануын һәм горурлыгын яшерә алмыйча. – Күзләре ничек янганын күрсәгез! «Ура! Заводка барабыз!» – дип торалар. Бу җиңү түгелмени?! Шуннан армиягә китәчәкләр, өйләнеп кайткач та эшләрен шунда дәвам итәрләр, кайберләре исә эшли-эшли кичке якта КАИда укыр...»

Һәм китте, китте мактап! «Биредә укыган балаларны мактап туймаслык», – ди. «Бездә очраклы гына килеп эләккән балалар юк», – дип тә куя. Әти-әниләре дә искиткеч кешеләр икән... Әнә, бер малайлары укуыннан бушаган арада «Радиоприбор»да эшләп, айга 8 мең хезмәт хакы алган ди әле. Әйбәт бит! Радиоэлектрон аппаратлар һәм приборлар монтажлау белгечлеге буенча 3 нче курста укучы Айнур Мингәрәев WSR һөнәри осталык милли чемпионатының сайлап алу турында җиңүче булган. Инновацион идеяләре белән дә көллият укучылары арасында беренче урынга чыгып, җиңүче-призер исемен яулаучылар бар. Һөнәри белем бирү учреждениеләре студентлары арасында ел саен уздырыла торган «Киләчәк безнең кулларда!» дигән республикакүләм фәнни-тикшеренү эшләре конкурсында да алар – «Радиомеханика колледжы» укучылары гел алдынгылар бит! Бүген оборона предприятиеләренә фән белән бәйле производстволарда эшләр өчен югары квалификацияле эшчеләр һәм инженер-техник белгечләр кирәк. Көллият бу бурычны үтәүгә аерым игътибар бирә икән: үз хезмәт биографияләрен нәкъ менә шушы юнәлештә башлардай егетләрне җыя. Аны тәмамлаучылар инде оборона комплексының бик күп эре предприятиеләрендә эшли.

Мин остаханәдә мавыгып, үз эшләренә чумып утырган малайларны күрдем. Кулларында – буш плата. Шуңа төрле детальләр – диодлар, транзисторлар тезеп, төгәл



■ **Лилия Яруллина** – Казан «Радиомеханика колледжы» директоры, педагогика фәннәре кандидаты, «Ел менеджеры» Бөтенроссия конкурсы җиңүчесе, «Ел хатынкызы» бәйгесенең (2013) «Ел үрнәге» номинациясендә җиңүче.

■ **Шигаре:** Иртәгәгә карый бел, киләчәк өчен эшлә!

■ **Ярата:** бакчада казынырга, чәчәкләр үстерергә, балык тотарга, гөмбә җыярга, китап укырга, дуслар белән аралашырга.



схемалар ясарга өйрәнәләр. Ювелирлар диярсең! Уйларында – диңгездәге су асты көймәләре, хәрби корабльләр, күктәге самолетлар... Бүген бу укучылар искиткеч төгәллек белән дөрес схемалар ясау серен үзләштерә, ә иртәгә инде заводта аларга катлаулы микросхемалар ясауны да ышанып тапшырырлар. Алар ясаган приборлар төрле өлкәдә кулланыла ала. Һәм, әлбәттә, иң элек хәрби техникада! Очкычларда, корабльләрдә!

Директорны аерым бер якынлык, җылылык белән яраталар. Хезмәттәшләре, укучылары, ата-аналар. Ул электрон почтасын ачып, укучылары язган хатларны укыганда рәхәт бер дулкынга күчеп алды. «Лилия Фәритовна! Без Сезне яратабыз!», «Балаларыбыз да үскәч Сезгә киләчәк», «Лилия Фәритовнаның иң шәп сыйфаты – аңа ышанырга була!», «Яратабыз. Ышанабыз».

«Мин киләчәккә ышанам», – дип, Лилия Яруллина үзе рухландырган түгелме соң аларны? Җиңүчеләр булырга өйрәткән. Яратырга өйрәткән – әти-әнине, кешеләрне, эшне, туган җирне, Ватанны... Ул сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый, әнә шундый нәтиҗәләр ясыйм. Аның белән сөйләшү, аны тыңлап утыру рәхәт. Кабинетындагы һәрнәрсә Лилия Фәрит кызы образын тагын да баетып җибәрә сыман. Гөлләр, китаплар, картиналар, курчаклар, пианино... Хәтта тәрәзәдән күренгән агачлар, кар каплаган алмагачлар да нидер сөйли... Кайчандыр үзләре утырткан бакча бит ул!

Лилиянең тормышка, яшәешебезгә, халкыбызга, туган телебезгә кагылышлы кызыклы фикерләре бар. Еракка китеп кара икән, дип, Финляндиядән алган тәэсирләре белән бүлешә. «Хельсинкида фин татарлары белән аралаштык. Татарстан, Казан, халкыбызның бай мирасы, гореф-гадәтләребез турында сөйләштек. Күңелләрне җирсү-сагыну катыш горурлык биләде. Еракта туган тел дә, җырларыбыз да сагындыра, аларның кадере бермә-бер арта икән...»

Юл башы

51 нче мәктәптән соң, финанс-икътисад институтын тәмамлап, төрле дәрәҗәдәге уку йортларында укытучы-методист булып эшли, ә КАИда инде доцент Лилия Фәрит кызы Яруллина икътисад кафедрасында лекцияләр укый. «Бухучет» минеке түгел дип, педагогикага кереп китә. «Колледжда икътисадый әзерлек процессында студентларның социаль үсеше» дигән темага фәнни хезмәт язып, диссертация яклый. Гүзәл Мөхәммәтҗанова, Флера Зыятдинова кебек дәрәҗәле, талантлы

> *Иртәгә инде Ватаныбыз иминлеге шушы эшләренә бәйле булачагын аңлап, тырышып укый бит алар!*

ханымнар аның фәнни җитәкчеләре була. Аннары Президент программасы буенча укулар. Мәскәүдәге Плеханов исемендәге академиянең халыкара ресурслар үсеше үзәгендә менеджмент буенча тест узганнан соң, Японияга бер айга стажировкага китү. Анда персонал белән эшләү, кадрлар алмашу буенча күп нәрсәләрне үзләштерү. Германиядә, Кореядә исә колледжларда укытуны оештыру нигезләренә өйрәнеп кайтулар... Казан радиомеханика көллиятен җитәкләү дәверендә бөтенесе Лилия Яруллинаның эшендә чагылыш таба, ялтырап күренеп китә тора.

Казан радиомеханика көллияте оешуга инде 48 ел. Предприятиегә кадрлар әзерләү максатыннан, 1967 елда 51 нче техник училище оештырыла башта. 1970 елда завод уку бинасын төзи, укыту-җитештерү остаханәләре һәм комбинатлары булдыра. 1995 елда эшчедән алып радиоэлектроника инженерларына кадәр әзерли торган өзлексез һөнәри белем бирү системасы кертелә. 2000 елда исә А. Н. Туполев исемендәге КГТУ базасында



2 нче сыйныфта укучы кызым Майя бик иҗади бала. Сәнгать мәктәбенә йөри, рәсемнәр ясый, нәфис гимнастика белән шөгыльләнә. «Үземне дә, кызымны да 60 нчы еллар фильмнары үрнәгендә тәрбиялим. Алар чиста, кешелекле.



радиоэлектроника һәм тармак менеджменты кафедрасы ачыла. Укыту процессын фәнни-методик ысулда алып бару, колледж–КАИ–ААҖ «Радиоприбор» уку кластерлары механизмын булдыру нәкъ шушы чорга туры килә инде. Бүген ул «Радиоприбор» заводын кадрлар белән тәэмин итүче «Казан радиомеханика колледжы». Ике коллективның – завод һәм көллиятнең – кулга-кул тотынып эшләве Россия сәнәгатен алга җибәрүче зур көч икәнен чамалау кыен түгел.

Шундый җаваплы эшкә ничек тәвәккәлләп алынган соң бу ханым? Нинди юллар аша килгән? Нинди сынаулар үтеп? Радиомеханика, техника, электроника... Хатынкыз түгел, ир-егетләр эше ич бу!

Лилия, ачылып, үз дөньясына алып кереп китте.

Мин үз эшемне, хезмәттәшләремне, укучыларымны яратам.

Әти ышанычын аклау

Әтием Фәрит Юныс улы хәрби кеше иде. Вольскида Югары хәрби училище тәмамлаган. Кызганыч, узган көз арабыздан китеп барды... Бик юксынабыз аны! Ул 1940 елда туган, сугышта һәлак булган әтисен күрми дә үскән. Әнисе дүрт бала белән калган. Шигырьләр ярата, җыр ярата, кешеләр ярата торган искиткеч кеше иде әтием: барысы белән уртак тел таба, һәммәсен җайлый-көйли белә, кызыма татарча китаплар укый. Хәзер кызым үзе татарча укый, шигырьләр сөйли. Минем хезмәтемне аңлап, күреп үсә, укытучы эшенә тирән хөрмәт белән карый ул. Менә шул була инде оясында ни күрсә... Бу чынлап та шулай.

Менә мин яшьләрне һөнәргә өйрәтү юнәлешендә эшлим. Радиоэлектрон аппаратура һәм приборлар монтажчылары, техник-электрониклар, токарьлар, машина төзелеше белгечләре әзерләп, оборона комплексы предприятиеләренә җибәрәбез. Бу нииндидер сынау, үзеңнән соң матур дәвам калдыру өчен форсат дип уйлыйм. Ничек кенә кыен булса да, алга барырга кирәклекне балачактан үзләштердем мин. Кем булырга гына хыялланмадым! Укытучы эше – иң ошаганы булгандыр...

Студент чакта, финанс-икътисад институтында укыганда ук балалар бакчасында эшләп йөрдем! Музыка дәресләре үткәрергә, «утренник»лар әзерләргә йөгерәм. Мәктәпкә озату бәйрәмнәре аеруча дулкынландыргыч була иде. Шуңадыр, сиреньнәр һәм лаләләр – минем өчен иң кадерле чәчәкләр...

Кайчандыр бакчада йөргән балалар инде мәктәптән соң көллиятне тәмамлады, заводка урнашты, инде үз балалары алар сукмагыннан китеп бара. Шулар белән очрашкач, гел әтинең дәвам турындагы сүзләре искә төшә. Мөгаен, мин аның ышанычын аклаганмындыр. Алар яныма килә, үткәннәрне сагынабыз, уңышларыбызны уртаклашабыз...

Алтын йөрәкле әни

Мин һаман бер мәкальне кабатларга яратам: «Урын кешене түгел, кеше урынны бизи». Һәм шундук әниемне күз алдыма китерәм. Миңа да, табибә булып эшләүче сеңлем Эльмирага да күп сыйфатлар әниебездән күчкән. Күпләр әнине Мәүсилә Харис кызы Яруллина буларак белә. Легенда дисәң дә ярый аны. Ул барысына да кирәк, гел кирәк. Тынгысыз, эшчән, җаваплы, зирәк, максатчан, кешелекле безнең әни. «Радиоприбор» заводына ул 50 ел гомерен биргән. Ә Яруллиннар династиясенә инде 300 елдан да артык. Мин дә шулар арасында – гаиләбез эшләрен дәвам итәм. Кайчандыр әнием, 16 яшьлек кыз, радиоэлектрон аппаратуралар монтажчысы булып заводка эшкә килгән. Бүген көллият

шул бик кирәкле белгечләрне әзерли. Үзем дә егерме елдан артык завод белән иңгә-иң торып, яраткан көллиятемдә эшлим. Әниемнең мактау кәгазьләре, диплом, Рәхмәт хатлары, башка бүләкләре арасында берсе – минем өчен иң кадерлесе: ул «Алтын йөрәкле кеше» исеменә лаек булуы. Бер генә түгел, өч тапкыр бит! Шәкертләрем, яратабыз, ышанабыз, дип әйтә икән, димәк, дәвам бар. Әтидән, әнидән күчкән дәвам...

Без – бер команда!

Менә хәзер дә тормыш, яшәү мәгънәсе турында уйланам. Коллективымны, студентларымны, эшемне яратам. Үз алдымда торган бурычларны аермачык күрәм, миннән нәрсә таләп итәселәрен беләм. Чынлап та, нәрсәдер эшләү, хәл итү, кайбер чакта төзәтмәләр кертү, авыр тоелган мәсьәләләрне чишү, ситуацияне үз кулыма алу барып чыга минем. Ахыргы сүзне үзең әйтү бик мөһим бит ул! Соңгы нәтиҗә синнән тора дигән сүз. Нинди эш соң ул, диярсез. Үзеңә шатлык, башкаларга файда китерә торган яраткан эш турында әйтүем. Аңа бөтен җаным, кендегем белән береккәнмен инде. Мин генә түгел, биредә йөрәкләрендәге бар җылыны, яхшылыкны, тупланган белем һәм тәҗрибәне балаларга бирергә әзер гаҗәеп фидакарь җаннар эшли! Предприятиеләргә кемнәрне әзерләргә кирәген яхшы беләбез. Эшче кадрларга һәм электроника, машина төзелеше өлкәсе белгечләренә булган ихтыяҗ динамикасын һәрчак күзәтеп, өйрәнеп барабыз. Үз эшебезнең патриотлары буларак, эш белән тәэмин итүчеләрдән, социаль партнерларыбыздан һәм, гомумән, дәүләт тарафыннан житди ярдәм дә өмет итәбез. Бердәмлектә – көч, диләр. Бергәләп тотынып, Россия электроникасының абруен дөнья күләмендә тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрәчәкбез әле без. Колледж никадәр белгеч укытып чыгарды! 5 меңнән артык технарь! Һәм күбесе үз белгечлеге буенча эшли.

Минем ныклы терәгем бар: ул – «Радиоприбор» заводы, колледжыбызны эш белән тәэмин итүче предприятие. Авиация борты аппаратуралары җитештерү буенча Россия Федерациясендә иң алдынгы предприятиеләрнең берсе, илебез радиоэлектроникасының чын мәгънәсендә флагманы ул! Генераль директор Шабаев Илдар Мирсәҗан улы кебек бер сүздән аңлый, хәлгә керә белә торган чын җитәкче булганда эшләве дә күңелле шул! Без – бер команда. Бездән чыккан монтажчылар туп-туры шунда барып урнаша. Республикада бездән башка бер уку йорты да әзерләми аларны. Алар һәрчак кирәк, аларга ихтыяҗ зур. Бу белгечлеккә сорау арта гына барачак әле. Илдә иң кыен чорларда күпләп экономистлар, юристлар әзерләп чыгардылар. Ә без шул чакта ук машина төзелеше белгечләре, токарьлар укытуга керештек. Өзмичә укытабыз, эшче квалификациясе алырга мөмкинлекләр тудырабыз, аннары ул белгечләр КАИга укырга керә. Россия Президенты оборона сәнәгатен үстерү, икътисадый потенциалны күтәрү бурычын куйды. Без аңа алданрак та килдек әле. Бүген бу идея инде үзенең апогейена күтәрелде. Хәзер Татарстанда «Ростехнологияләр» дәүләт корпорациясенә кергән ААҖ «Радиоприбор», В. И. Шимко исемендәге «НПО Радиоэлектроника», ААҖ «Казан электротехника заводы», ААҖ «Казан оптика-механика заводы» радиоэлектрон кластер предприятиеләре интенсив үсеш ала. Дәүләт Программасының уңышлы үтәлеше максатларында, республикадагы радиоэлектрон һәм оптоэлектрон сәнәгать предприятиеләре ихтыяҗы өчен «Радиомеханика колледжы» базасында заманча укыту үзәге концепциясе булдырылды. Алдыбызда яңа перспективалар, яңа бурычлар. Җиңеп чыгачагыбызга ышанам мин!

Үзен табалмыйча адашып калган укучыларым юк минем. Кирәкле булуларын аңлап яши алар!

Бәхет турында

...Кичен Майяны мәктәбеннән аласы, гимнастика студиясенә илтәсе бар. Кызын балерина итеп күрәсе килеп, үзе сокланган Уланова, Павлова, Майя Плисецкаяларны телгә ала. Кызы да бит Майя! Лилиянең кәефе шәп бүген – тьфү-тьфү, күз генә тимәсен! «Девчата» фильмындагы яраткан җырына күчмәс иде: «Снегопад, снегопад, снегопад давно прошел... Майя Кристалинская шулай җырлаган...» Абау, тагын Майя! Лилия ул арада укучыларында, яшьләрдә, ниһаять, кызында күрергә теләгән сыйфатлар, тәрбия, һәр балага барып җитә алу, игътибар һәм җылылык турында сүз башлый да, күңел җылысы, патриотизм хисләре салып төшерелгән фильмнарның азлыгына, балаларга карата кулланылган тыюкуркытулар, «кирәкми», «ярамый»ларның күплегенә эче пошып куя... Үзара чиста мөнәсәбәтләр урнаштыру, битараф калмау, башкаларга ярдәм кулы суза белү, җаваплылык хисе – менә ничек күрергә тели ул кешеләрне. Башкаларны шатландыра алу – бәхет аның өчен. Ул сөйли, көлеп җибәрә, укучыларын, хезмәттәшләрен мактап ала, фәлсәфәгә кереп китә. Һәм яңача ачыла бара...


«Бездә укыган егет-кызлар очрый да, якын итеп һәр укытучының хәлен сораша. Шундый рәхәт булып китә!»

«Өч-дүрт ел сизелми дә уза ул. Ә шул арада алар бездә тормыш сабакларын үзләштерә! Шәхес булып, һөнәр алып чыгалар. Үзләренең ныклы «мин»ен раслыйлар! Ышанасызмы, якты, яхшы киләчәккә ышаналар!»

«Гаиләм – илһам чыганагы. Мин анда яраткан, кадерле әни, кайгыртучан кыз һәм апа, тугры дус булып ачылам. Кунаклар каршылау, «фирменный» ризыклар белән сыйлау, бакча эшләре, чәчәкләр үстерү ошый миңа».

«Һәр җирдән матурлык эзлим. Иҗади, эшкә бирелгән, тугры, җаваплы, ярдәмчел, иртәгәсе көнгә ышанган кешеләргә хөрмәтем зур. Һәм шундый сыйфатларга ия хезмәттәшләремне күреп, күңел куана. Чын патриотлар алар. Идея өчен эшлиләр, ахыры җиңү белән тәгәлләнәсенә ихластан ышаналар, һич арттырусыз, алар бүгенге көн геройлары диясем килә».


РОССИЯ
DYUBANOK




25


TISSO


РОССИЯ




KRAFT
KEYVILLE
CANADA
22


33
RBK

КӘШӘКӘЛЕ КЫЗЛАР



Фәнзилә МОСТАФИНА

Хоккей уйнар өчен нәрсә кирәк? Шул да булдымы сорау – боз, кәшәкә һәм алка, диярсез әлбәттә. Ә минем кызларым бу фикер белән килешеп бетми. Кулыңа кәшәкә алгансың икән, аңа күңелеңне салырга кирәк, ди алар. 18 яшькә кадәрле кызлар арасында Америкада узган Дөнья чемпионатында океан аръягын шаулатып, чех кызларын елатып, III урын алып кайткан Татарстан кызларының сүзенә ышанмый мөмкин түгел!

Әлеге төр дисциплина буенча Дөнья чемпионатында Россия җыелма командасы 7 ел рәттән катнашты. Узган ел, безнең кызлар дүртенче урынны яулагач, их, җиңү кул сузымында гына иде бит, дип уфтанып куйган идек. Һәм быел, ниһаять, безнең кызлар пьедесталга менү бәхетенә иреште. Алтынга тиң бронза булды ул! Шул медальне илгә алып кайткан кызлар арасында дүрт татар кызы да булуы икеләтә куаныч.

Кәшәкәле кызларның икесе – Лиана белән Фәнүзә бүген Коми Республикасының Ухта шәһәрендә, Алсу белән Ландыш – Түбән Новгородта. Чемпионат бетте дә ял итәбез түгел – кызлар хәзер үз командаларында ил беренчелеге өчен көч сынаша. Туган якларына ялга нибары бер айга, анысы да җәй көне генә кайтачак әле алар. Җәй җиткәнен көтсәк, уңыш төмен югалтыр, дидек – тренировкалардан бушаган арада кызларны интернет челтәрендә «эләктердек».

Малайлар белән уйнап үскән Фәнүзә

Фәнүзә Кадыйрова – Кукмара районы Сәрдекбаш авылы кызы. 16 гына яшь әле аңа. Шушы яшеннән америкалыларның күңелен яулаган ул. Шулай булмаса, чемпионаттан соң кызның перчаткаларын Торонтодагы Хоккей даны залына куярга соратып алырлар идемени?! Фәнүзә чемпионатның иң яхшы бомбардирларының берсе булып та танылган. Иң шәп булу өчен нибары бер очко җитмәгән. Анысы куркыныч түгел. Кыз үзе әйтмешли, җиңүләрнең зурысы алда булыр әле.

Фәнүзәнең әтисе Фәһим Кадыйров – Кукмарада билгеле кеше. Күрәшче, районда хоккейны үстерүгә зур өлеш керткән шәхес. Кызны бозга бастыручы да – әтисе. Мин шалтыратканда, Фәһим абый интернеттан кызы Фәнүзә уйнаган «Арктик-Университет» командасының матчын карап утыра иде. Яраткан шөгыленнән бүлдереп, эти кешегә сорауларымны бирдем:

– Ни өчен Фәнүзәне нәкъ менә хоккейга бирдегез?

Көлеп җибәрде Фәһим абый. Бу сорауны гел бирәләр, күрәсең.

– Ул вакытта районда фигуралы шуу юк иде әле. Ә хоккей бар. Үзебез дә урамда малайлар белән алка куып үстек. Мәктәп янында хоккей тартмасы ясаттым да малайларны уйнарга өйрәтә башладым. Хатыным Гөлзия эштә, Фәнүзәне балалар бакчасыннан мин алам. Алам да үзем белән бозга алып киләм. Шулай итеп тимераякка басты ул. Башта алка җыеп кына йөрде. Көннәрдән бер көнне бер малай уенга килми калды. Фәнүзә аның формасын киеп карарга рөхсәт сорады. Шуннан ул киемен салдырып булмады инде.

– Хоккейда җәрәхәтләр дә булырга мөмкин бит. Курыкмадыгызмы?

– Хатын-кызлар хоккее ирләрнеке кебек тупас түгел бит ул, йомшаграк. Үзем дә уйнагач, кызым өчен курыкмадым. Әнисен дә күндердек. Аннан соң Фәнүзә беркайчан да үзен җәберләргә юл куймады. Малайлар төртеп китсә, артларыннан кәшәкә белән сугып кала, үзләрен бортка китереп сылый иде. Хоккейда бәргәләшеп алулар була инде, моңа



гадәти күренеш итеп карыйм. Каты сугышма, дип кисәтәбез үзе.

Фәһим абый Фәнүзә турында да, хоккей турында да тәмләп һәм озаклап сөйли ала. Уллары Булат Әлмәттә шулай ук хоккей уйный. Ә Фәнүзәне, чемпионатта күреп алып, Америкага чакырганнар! «Әле беркөнне, мин китәм, дип маташа иде. Америкадан ике клуб шалтыраткан. Кеше анда укырга да эләгә алмый, миңа уку бушка була, уйнавын да бөтенләй башка дәрәҗәдә уйнаячакмын, ди. Сезонны бетерик әле, аннары сөйләшербез ул турыда, дидек», – ди Фәһим абый.

Фәнүзәнең хыялы – Олимпия уеннарында катнашу. Шул максатына таба ныклы адымнар белән атлый кыз.

Фәнүзәнең үзе белән дә сөйләштем. «Иң яраткан тренерың кем?» – дип сорыйм. Уйлап та тормыйча: «Әти!» – ди.

– Әгәр яраткан хоккейчың белән бер бишлектә уйнарга мөмкинлек бирелсә, кемне сайлар идең?

Хоккей сөюче теләсә кем исемен атарга мөмкин: Илья Ковальчук, Александр Овечкин, Павел Дацюк... Мин белми торган тагын кемне әйтер дә оятка калырмын икән, дип уйлап та бетермим, кыз шартлатып җавап бирә:

– Абыемны!

Абый тимераякларыннан башланган карьера

Актаныш районы Иске Байсар авылы кызы Лиана Ганиеваны хоккей уйнарга абыйсы өйрәткән. Дөресрәге, аның тимераяклары. Лиана ясле яшендә үк абыйсының тимераякларына кызыккан. Үсә төшкәч, аның тимераякларын урлап, бозлавыкка кача торган булган. Кызның хирыслыгын күреп, әтиәнисе Лиананың үзенә дә тимераяк алып бирергә мәҗбүр булган.

«Районда зур кызлар арасында шорт-трек ярышы узганда, Лиананы сынап карарга булдык. Ул вакытта дүртенче сыйныфта гына укый иде, ә 11 нче сыйныф кызларын «эһ» тә итми узып китте, беренче урынны алды. Тренер өметле икәнен сизеп алып, миңа әйтте. Шуннан хоккейга бирергә булдым. Әнисе баштарак борчылды, әлбәттә, тик Лиананың уйныйсы килү теләге ташып тора иде – әнисе дә карыша алмады», – ди кызның әтисе Альберт Ганиев.

Бозда бәргәләшүләр турындагы соравымны Альберт абыйга да бирәм. «Кызларга сугышу килешми, шуңа күрә уен вакытында да бәрелешләргә катышмаска тырыш, дип әйтәбез. Тик үзен һәм команданы якларга туры килә икән, монда бер сүз дә әйтеп булмый. Лиана кечкенә вакытта тыныч булса да, үзен бērәүдән дә кыерсыттырмый иде».

Лиана ил җыелма командасында икенче сезонын уйный. «Узган ел өченче урын өчен Чехия командасына каршы уйнаган идек. Алар җиңде – без аларга кыарап еладык. Быел киресенчә булды: безнең кызлар өченче урында – чех кызлары безгә карап елады», – дип хисләре белән уртаклаша кыз. Лиана Ухта шәһәрендәге урман көллиятенең 1 нче курсында укый. Үзе дә, әти-әнисе дә Лиана Ганиеваны киләчәктә Олимпия уеннарында күрәләр.

Лиана хоккейчы кызларның бер көнен тасвирлап та күрсәтте. «Иртәнге җидедә торабыз. Җиңелчә зарядка ясаганнан соң, укырга китәбез. Хәлебезгә кереп, имтиханнарда «автомат» куя торган укытучылар да, «батыра» торганнары да бар. Сәгать дүртләр тирәсендә тренировка башлана. Болай сөйләгәндә гел бертөрле, күңелсез кебек, тик без кызыклы шөгыльләр табарга тырышабыз, чана шуарга барабыз, шәһәр буйлап йөрибез. Шунысы бар: кичке «һава сулау»дан соң урамга чыгарга ярамый. Тәртип көчле монда. Мәсәлән, «прогулка»га, тренировкаларга бер минутка соңга калсаң, 100–300 сум штраф. Ул акча командага җыелып бара». Кызларга ай саен хезмәт хакы түләнә, голларны күбрәк кертсәң, премия дә өстәлә. Төгәл суммасын гына әйтмәде Лиана, сер булып калсын диде.

Американы ошаткан кыз. Сакчы Лиана Ганиеваны, Чехия белән уеннан соң, Америка арбитрлары Россия җыелмасының иң яхшы уенчысы дип таныганнар.

«Хоккей – тормыш рәвешебез»

Алсу Рәхимова белән Ландыш Фәләхова – Саба районыннан. Бүген Түбән Новгородның «СКИФ» командасында уйныйлар. Нижгар өлкәсенең Олимпия резервы училищесында белем алалар. Ландыш – 10 нчы, Алсу 11 нче сыйныфта.





Аларның командасы узган сезонда Россия чемпионатында беренче урынны яулаган. Быел менә уңышларына тагын берәү – бронза медаль өстәлде. Дөнья чемпионаты медале!

«Укырга кергәнче үк авыл малайлары белән елгада боз катканын көтеп ала һәм көннәр буе хоккей уйный идек. Боз сараена 3 нче сыйныфта укыганда йөри башладым. Гаиләбездә башка хоккейчылар юк. Ике абыем да укытучылыкка укыйлар: олысы – математика һәм информатика, кечесе физкультура буенча», – ди Ландыш. Кыз рәсем ясарга ярата, дизайнер булырга хыяллана. «Ә хоккей?» – дип кызыксынам. Җавап озак көттерми: «Киләчәк турында уйлаганым юк. Тик мин хоккейны яратам һәм уйнавымны дәвам итәргә телим».

Ландышның әле уйланырга, булачак һөнәрен сайларга бер елы бар. Ә Алсуның инде мәш килеп бердәм дәүләт имтиханына әзерләнеп йөргән чагы. Мәш килеп, дип, хоккейдан бушаган арада, әлбәттә. Нинди һөнәр сайлаячаксың, диюемә: «Әле ул турыда уйлап бетермәдем шул», – дигән җавап алам. Үзе әйтмәсә дә, тел төбеннән шул аңлашыла: Алсу да киләчәген хоккейсыз күз алдына китерми. «Мин 6 яшемдә уйный башладым. Заманында әтием хоккей уйнаган. Хәзер икетуганнарым һәм 12 яшьлек кечкенә сеңлем Айсылу да хоккейга тартыла», – ди ул. Алсу әти-әнисе кочагыннан бик иртә чыккан. 12 яшендә Түбән Новгородка чакырганнар аны. Ә 2012 елда ил җыелма командасына алганнар. «Зурлар җыелмасына эләгәсе генә калды», – дип елмая кыз монитор аша. Уңышларын иң элек әтисе белән уртаклаша икән.

«Көне-төне хоккей уйнагач, үзеңне гүзәл зат итеп тоярга вакыт каламы соң?» – дип кызыксынам Алсудан. Кыз интернеттан җавап сырлаган арада, үз соравыма үзем үк җавап биреп тә куям: теләк кенә булсын, вакыт һәрчак табыла! Алсудан да шундый җавап килә: «Буш вакыт аз кала. Аны үзем өчен үткәрергә тырышам. Кибетләрдә йөрергә яратам. Өйдә булганда тәмлүшкәләр пешерергә өйрәнәм».

* * *

Җиңү пьедесталына менеп караган кешегә нинди сорауны бирми калу мөмкин түгел? Ничек ул анда басып тору, дигәнен! Кәшәкәле милләттәшләребезгә дә бирдем бу сорауны. «Рәхәт!» – ди кызлар. Һәм, алдан сүз берләшкәндәй, өстәп куялар: «Без ил данын якларга тиеш идек. Кулыбыздан килгәнне эшләдек, тик тагын да югарырак күтәрелеп тә булыр иде. Анысы – киләсе елга!»





БЕЛМӘСӘҢ БЕЛ

■ Хатын-кызлар спорты бүген гадәти хәл. Әмма бу мәйданда урын яулау җиңел булмаган – озак вакыт хатын-кыз спортның үзе сайлаган төрләре белән түгел, ә бәлки рөхсәт ителгәннәре белән генә шөгыльләнә алган. Хатын-кызларның җәмгыятьтәге урыны төрлечә булган кебек, аларның спортка керү процессы да төрле илләрдә тигез бармаган. Бүген инде үсеп килүче илләрдә дә меңнәрчә кызлар спортның төрле төрләре белән шөгыльләнә. Ләкин бу – спортка мәхәббәт дигән сүз түгел, ә кияүгә уңышлырак чыгу өчен спорт ачкан мөмкинлекләрне күз алдында тоту гына: физик күнегүләр белән мавыккан кызлар сәламәт, матур, сылу гәүдәле була. Гаиләле булуга, хатын-кызлар спортны ташлый.

■ Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң колониаль бәйлелектән котылган Африка илләрендә дә спортка тартылу күзәтелә. Әмма ирләр катнашкан спорт төрләре белән хатын-кызлар күптән түгел генә шөгыльләнә башлаган. Моңарчы алар бию, музыка һәм төрле уеннар белән генә шөгыльләнә алган.

■ Ирак хөкүмәте 1958 елга кадәр хатын-кызларга халыкара ярышларда катнашуны тыйган. Иранда, гомумән, хатын-кызларга физик күнегүләр белән янында ире булганда гына шөгыльләнергә рөхсәт ителгән.

■ XX гасыр ахырында спорт мәсьәләләре белән шөгыльләнүче дәүләт оешмаларында хатын-кызның статусы бермә-бер үсә. Алар халыкара спорт берләшмәләрендә дә күбрәк катнаша башлый. 1981 елдан 1987 елгача Халыкара олимпия комитеты составына җиде хатын-кыз кертелә.

■ XX гасырда япон хатын-кызларының да спортка мөнәсәбәте үзгәрә. Моның сәбәбе – Японииядә Олимпия уеннары узуы.

■ Чирәм хоккее белән хатын-кызлар Беренче бөтендөнья сугышына кадәр үк шөгыльләнгән. 1927 елда Англиядә «Хатын-кызлар хоккей клубының халыкара федерациясе» дип аталган халыкара спорт оешмасы барлыкка килә. Ишкәк ишү спорты да нәкъ шул чорларда колач җәя. 1914 елны АКШ, Канада, Бөекбритания, Франция, Швеция һәм Германиядә Милли федерацияләр оештырыла. Спортның бу төре буенча ярышлар беренче мәртәбә 1925 елда узса да, хатын-кызлар уеннарга бары 1948 елда – XIV Олимпиада вакытында гына кертелә.

■ Хатын-кызлар арасында шайбалы хоккей уены беренче тапкыр 1892 елда уза.



Фото: Газинур Хафизов

Малайлар кызлардан кай яклары белән аерыла дисәм, кычкырып көләчәксез. Юк, җенес аермасын күздә тотуым түгел. Малайлар дөньясы һәм аларны кыю да, батыр да, тәвәккәл дә, шул ук вакытта миһербанлы да, олы йөрәкле дә ир-егет итеп үстерү турында уйлануым. Интернет киңлекләрендә шактый кызыклы нәрсәләргә юлыктым. Шуларны сезнең белән дә уртаклашасым килә.

МАЛАЙЛАР ЕЛЫЙ БЕЛӘМЕ?

Узган гасыр ахырында кешелек бер нәрсәне абайлап алды: без малайларны тәрбияли белмибез икән. Алар ялкау, начар укыйлар, җавапсызлар, кыңгыр эшләрне дә ешрак алар кыла.

Малайларны тәрбияләү эшенә битарафлыктанмы бу? Әллә соң малайлар дөньясына ачыласы ишекнең ачкычын таба белмибезме? Күрәсең, соңгысы дөреслеккә якынрактыр. Киләчәктә чын ир булырга тиеш ул малайларның тәрбия дилбегәсе хатын-кызлар кулында бит. Бакчада аларны без тәрбиялибез, мәктәптә без укытабыз, югары уку йортында тагын без. Хәтта гаилә коргач та ирләргә баш булырга омтылабыз. Ир-егетнең табигате нинди? Алар үзләре чын ир-ат нинди булырга тиеш дип саный? Хатын-кыз моны беркайчан да тулысы белән аңлап бетерә алмас. Әмма бүген бер нәрсәне ачык беләбез: малайларга ир-ат даирәсе җитми. Хатын-кыз арасында гына кайнашканлыктан, ир-атның тормышта тоткан урынын аныкламый үсә улларыбыз.

Сезнең дә хатын-кызлар авызыннан: «Үземне аңлый торган ир-ат очратмадым», – дигәнне ишеткәнегез бардыр. Хатын-кызны аңлый алмаучы ул ир-атны хатын-кыз үзе тәрбияләгән бит югыйсә. Нигә шулай килеп чыга соң? «Әни, сине берәүдән дә рәнҗеттермәм», – дип, йомшак куллары белән әнисенең муенына сарылучы малайдан, нигә соң әле хисләргә саран егетләр үсә? Калыплашкан тормыш кануннары буенча, ир-егет үзен кулда тота белергә, салкын акыл белән эш итәргә, хисләрен ачыктан-ачык күрсәтмәскә тиеш. Хатын-кыздан аермалы буларак, аңа еларга, киреләнергә ярамый. (Малайлар иң күп ишетә торган сүздер ул – «Син кыз мәллә?») Бүгенге психологлар беравыздан тәкрарлый: ир-егетнең хисси үсеше кечкенәдән бастырыла. Ә бит галимнәр күптән ачыклаган: кешенең хисчәнлеге аның интеллектын билгели. Кешенең акыл үсешеннән тыш, әле хисләр дөньясы, хисләр байлыгы да бар. Хисләр байлыгы – үз-үзеңнең һәм башкаларның хис-тойгыларына сизгерлек, аларны аңлый, кабул итә белү. Малайларның хис-тойгыларын бастыру киләчәктә психологик кыенлыклар тудырачак икән. Бу проблема бигрәк тә яшүсмерләргә хас. Эмоциональ наданлык аларга яшьтәшләре белән аралашканда комачаулый. Көчләү, үзара сугышу, берничек тә аңлатып булмый торган вәхшилек-

нең сәбәбе – ир баланың тормыштагы бөтен нәрсәне көч белән үлчәргә омтылуы. Мондый проблемалар булмасын өчен, ир баланы кечкенәдән үз хисләрен аңлый белергә өйрәтергә кирәк, ди алар. Кызларга караганда, малайлар үз-үзләренә бәяне түбәнрәк куя. Аның күңеле көн саен батырлык кылырга чакыра (нишлисең, табигате шундый), ә инде уңышсызлыкка очраса, күңеле шундук боега.

«Сизгерлеген үстерим дисәгез, улыгыз белән хис-кичерешләрегезне ешрак уртаклашыгыз, – дип киңәш бирә психологлар. – Башкаларның да хисләрен тасвирларга тырышыгыз. Музыка, кино, әдәбият – хисләрне үстерүдә иң зур ярдәмчеләр. Улыгызны хисләрен яшермәскә өйрәтегез. Көчсезләрне кызгансын, аларга ярдәм кирәген белсен. Ятим көчекне кызганудан күзләренә яшь тулган балагыздан көлмәгез, оялтмагыз. Аны аңлавыгызны, кече күңеллелегенә куануыгызны белдерегез».

Танылган сексолог һәм социолог, профессор Игорь Конның «Мальчик – отец мужчины» китабында мондый юллар бар: «Балаларны нәрсәгә өйрәтергә кирәген җитәкче әфәнделәр яхшы белә. Ә ничек өйрәтәсен педагогика профессорлары хәл итә... Ә минә социологлар, дөньяның кая таба барганына карап, малайларны ничек тәрбияләргә ярамаганын әйтеп бирә».

Тәрбиянең төп нигезе – үрнәк. Ир бала янында үрнәк алырдай ир-ат булу кирәк дисәк, бу – ачыш булмас. Борынгылар малайларны ничек тәрбияләргә дип, баш ватмаган. Малайны ир-ат тәрбияләргә тиешлеген белгән алар. Ир баланың эчке дөньясын ир кеше генә аңлый ала. Чөнки бу кичерешләрне кайчандыр ул үзе дә кичергән. Әле безнең үзебездә, татарларда да, һөнәргә өйрәнсен, дөнья күрсен, чарлансын, дип, ир баланы берәр һөнәр иясенә өйрәнчек итеп бирә торган булганнар. Бүген бу остазлык вазыйфасын спорт тренерлары, укытучылар, туганнар яки гаилә дуслары арасыннан баланың хөрмәтен казанган берәр кеше башкара ала. Ә андый кешенең булуы бик кирәк.

Ир-егет булып җитлегү дәверендә ир бала өч чор аша кичә. Беренче чорда – туганнан алып алты яшенә кадәр бала әнисенә «чытырдап» ябышкан була әле. Әмма бу әтинең роле аз дигән сүз түгел. Ир бала әти белән үсәргә тиеш. Әти – канун. Әнинең бурычы – баланы ярату булса, әтинең бурычы – өйдәге кагыйдәләрне булдыру, аларның үтәлешен таләп итү. Әти әйткән «ярамый!» һичшиксез үтәлергә тиеш.

Икенче чор үндүрт яшькәчә дәвам итә. Бу чорда бала аңлы рәвештә әтисенә тартыла, аңа карап, ир-ат булырга өйрәнә. Уларын ялгызлары гына үстерүче әниләр аның бу таләбен аңларга тиеш. Әтисе булмаса ни, туганнар, дуслар арасында баланың аңлаучысы, киңәшчесе булырдай кеше табылырга мөмкин. Нәкъ шушы яшьтә ир балалар малайлыкның тәмен-ямен тоя башлый икән.

Өченчесе – яшүсмер балигълыкка ирешкәнчегә кадәрге чор. Бу – иң катлаулы чор. Әти-әни инде икенчерәк планга күчә. Баягы остазлык дигәнебез, шушы чорда аеруча мөһим. Ир балага тормыш югары таләпләр куя. Шәфкатьле дә булсын ул, җебеп тә төшмәсен, кыю да булсын, куркыныч вакыйгаларга да тармасын, акыллы да булсын, эшчән дә булсын, четерекле хәлләрдән чыгу җаен да таба белсен... Шушы сыйфатлар ир балага барысы да берьюлы сыеп бетәргә тиеш.

Төрле чыганаклардан алган бу мәгълүматлар, үндүрт яшьлек егетнең әнисе буларак, миңа шактый кызыклы тоелды. Малайлар тәрбияләү кадәресе сезне дә борчыймы? Әйдәгез, фикер алышуларны журналыбызның сайтында дәвам итик. Сездән хатлар көтәбез.

Лилия ГӘРӘЕВА

Әниләргә киңәш:

- Малайларны кечкенә вакытта иркәләүдән курыкмагыз. Яратуыгызны гел белдереп торыгыз. Сез аның киләчәктә хатын-кыз белән ике арадагы мөнәсәбәтләренә нигез саласыз.
- Ә менә яшүсмер малаегызны алдыгызга утыртып сөю дөрес түгел. Бу яшьтә малайларның сексуальлеге формалаша һәм сезнең иркәләү-назлавыгыз аңарда дөрес булмаган эротик тәэсир калдырырга мөмкин.
- Улыгыз ничә яшьтә генә булмасын, аның кыюлыгын күреп, мактап торыгыз. Аның янында үзегезне көчсез, яклауга мохтаҗ хатын-кыз итеп күрсәтегез.
- Улыгызны «өф-өф» итеп кенә үстермәгез. Үзе тотып карамыйча, чәйнекнең чынлап та кайнар икәненә ышанмаячак бит ул.
- Малайларны гел ачуланып тору, аларда дөньяга карата үч тудыра. Танылган инглиз педагогы Роджер Эшемның мондый сүзләре бар: «Ир балада тырышып уку теләген фәкать мактап кына уятып була».
- Улыгызны ялгызыгыз гына үстерәсез икән, аны һичшиксез, берәр спорт түгәрәгенә бирегез. Түгәрәкнең җитәкчесе ир-ат булсын. Киңәш сорардай ир-ат дусты булырга тиеш аның.

Әтиләргә киңәш:

- Улыгызның күз яшьләреннән көлмәгез. Аны сүз белән «чеметмәгез», бигрәк тә иптәшләре янында.
- Улыгызның гел янbackыгызда чуалуына ачуланмагыз. Киресенчә, кадак какканда, шөреп борганда, базардан бәрәңге алып кайтканда (гәрчә улыгыз өч кенә бәрәңге күтәрә алса да) аның ярдәме алыштыргысыз булуын әйтегез. Үз көченә ышанып үссен.
- Улыгызны кыйнамагыз. Көч куллану һәрвакыт үч алу теләге тудыра. Бала күңелендә бу теләк туплана килеп, ахыры аяныч булырга мөмкин. Джон Локкның 1693 елда язган «Тәрбия турында кайбер фикерләр» трактатында бик үтемле фикер бар: «Кем дә кем улының хөрмәтен казанырга теләсә, ул кеше иң элек улын үзе хөрмәт итсен».
- Яшүсмерлек чорында малайлар өчен әти кеше авторитет булудан туктарга да мөмкин. Чит ир-ат үз әтисенә караганда акыллырак, уңышлырак булып күренә аның өчен. Бер гыйбарәне ишеткәнегез булдымы икән: «Кечкенә вакытында малай үзенең әтисеннән үрнәк ала, яшүсмер чорда әтисен дөньяның бер булдыксызы дип саный. Ә инде үзе өйләнеп, балалар үстерә башлагач, әтисенең ярыйсы гына кеше булганына төшенә».



Фото: Газинур Хафизов

АВЫЛ БЕТМӘС, ЯШӘР УЛ!



Мәдинә АВЗАЛОВА

ДӨРЕСЕН ӘЙТКӘНДӘ, ӨЙГӘ УЛ КУНАРГА ГЫНА КАЙТА. КҮП ВАКЫТ ТӘҮЛЕКНЕҢ УНИКЕ СӘГАТЕ ФЕРМАДА УЗА. ЕЛ ӘЙЛӘНӘСЕ ШУЛАЙ.

Заманында бу хуҗалык нинди генә исем белән йөртелмәгән. Аны Мәшләк агрофирмасы дип тә, берара җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять дип тә йөрткәннәр. Ничек кенә димәсеннәр, иң авыр чорларда да ул авыл халкының терәге, ышанычы булып кала килгән. Узган елның февраленнән крестьян-фермер хуҗалыгына әверелгән шушы зур комплексның җитәкчесе Нияз Шәмсетдинов ул елларны искә төшерә дә, хәзергесеннән канәгать калып, шөкер итә. Хәтта көндәлек кирәге булган ягулыкка да тилмереп торган чаклары бар иде бит аларның. Тырышып, тир түгеп тапкан хезмәтеңне 3 тәңкәгә бәяләсеннәр дә... «Сөтне әйтәм, – дип ачыклык кертә Нияз Габделхәевич. – Өч сумнан сатып җибәрә торган идек бит ул вакытларда».

– Шулай бит, Рәйсә, – дип куя җитәкче. Без сөйләшкән арада әле йөгереп барып, улакларга фураж салып, әле сыер савучылар белән ни хакындадыр гәп куертып мәш килгән ханым, баш кагып куя. Үзе бәләкәй, үзе чандыр... «Бәләкәй генә булса да, ирләргә бирешми ул, – ди уйларыбызны укыгандай Нияз Шәмсетдинов. – Җитмәгән җире юк. Үзе итекче, үзе читекче... Малларны ашатучы-эчертүче дә, укол ясаучы да ул. Кирәк икән, сыер да сава».

«Үзебезнең сыерлар»

– Рәйсә Галимулла кызы Әхсәнова – әлеге хуҗалыкның зоотехнигы. 2014 елның Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан танылган иң яхшы зоотехнигы!

– Ирләр эшләп карады инде бу эштә, – дип дәвам итә сүзен фермер. – Бер ел түзәләр, ике ел, аннары кайсы эчүгә сабыша, кайсы урлашып тотыла. Маллар янында андый кешеләр буталып йөрергә тиеш түгел. Алар барын аңлый. Яратканны да аңлый. Ә без яратабыз, әйеме, Рәйсә, – ди ул янә хезмәттәшенә мөрәҗәгать итеп.

Нияз Габделхәевич эшли башлаган 2007 елларда мал саны 600 ләп була. Бүген ул 860 ка җиткән. Бер баш сыердан көненә 17,2 килограмм чамасы сөт савып алына. «Тәүлегенә 5 тонна сөт озатабыз», – дип горурланып сөйләгән җитәкчедән: «Малларыгыз көр-шәп күренә, әллә чит илдән кайтарттыгызмы? – дип сорыйбыз. Ул канәгать елмая: «Үзебезнекеләр! Мин малларны күбрәк ашату ягында. Азыгы җитте исә, малың чит илнекеннән бер ягы белән дә калышмый». Һәм өстәп куя: «Бер дә аптырамагыз, чит илнеке дә бер-ике елдан үзебезнекенә әйләнә ул. Үзебезчә ашаткач, үзебезчә карагач, үзебезчә яраткач, пропискасы үзгәрә аның. – Без көлешеп алабыз. – Министр да бер килгәч: «Нияз, сыерларың үзең шикелле», – диде әле дип, янә бер көлдереп ала.

Сыер сыртын сыйпый-сыйпый комплекста озак йөрибез. Малларга азыкны трактор тарата. Җитәкче әйтмешли, берсе дә сәнәк-көрәк күтәреп йөрми. Монда да эшләр машина-төймәләргә көйләнгән. Кайчандыр 8 миллион бурычы булган аларның. Хәзер анысы да түләнеп бетеп килә. 72 ләп кешедән торган коллектив малларга азыкны үзе әзерли: үзе чәчә, үзе үстерә, җыеп ала. Фермер: «Биш мең тонна салам-силос әзерләдек. Кышка җитә, яртысы кала да әле, – ди дә, – көненә ун төргәк салам, биш төргәк печән кереп бара», – дип санап китә. Бирегә күрше авыллардан да, Әлмәттән, Мамадыштан да килеп эшлиләр. Вахта бер авылдан икенчесенә йөреп тора. Кыскасы, эшсезләргә менә дигән эш урыны!

Мал да кеше шикелле. Ашыйсы килсә, ярсып тора. Чирләсә, ятып тору җаен гына карый.

Үзеңне кызганмасаң...

Хәер, Нияз Шәмсетдиновның уң кулы Рәйсә Әхсәнова үзе дә бу як кешесе түгел. Тумышы белән ул – Теләче ягыннан. Ә Балык Бистәсенең Мәшләк авылына ул

■ «Әгәр дә хөкүмәттән булышлык булмаса, авылларга яшәве бик авырга туры киләчәк», – дигән иде Нияз Габделхәй улы. Әйе, яз көне ашламага, ягулыкка бәяләрне яртылаш калдырганда, утка 30 процент ташлама ясаганда, акчалата ярдәм күрсәткәндә... яшәргә булыр иде анысы. Ашлыкны арадашчылар 5 сумнан, ә сөтне 20 сумнан җыеп китәләр икән. Бирмәс идең, акча кирәк, хуҗалыкны алып барасы бар. Арадашчылар бетмичә, хөкүмәт белән турыдан-туры эшли башламыйча, рәхәт күрәм димә, кыскасы. «Сөтнең литрын 25–28 сумнан алсалар, җырлап-көлеп кенә йөрер идем», – ди Нияз Шәмсетдинов үзе дә.



Чаллыдан – Казан кулинария училищесын тәмамлап, ашчы булып эшкә киткән җиреннән кайта.

Адәм баласын дөньяның бер читеннән икенчесенә ни йөртә?! Билгеле инде, ризык йөртә. Ә тагын... мәхәббәт! Ул үзе бер белмәгән авылга килеп урнашуын бик гади аңлата. Фатир бирәбез дигәннәр аларга. Яшь гаиләгә шул гына кирәк тә...

Хөкүмәттән ярдәм булмаса, авылны яшәтү авырга туры киләчәк.

Ул чагында «Татэнерго»ның Мәшләктәге ярдәмче хуҗалыгына да эш рәтен белүче тәҗрибәле белгечләр кирәк булгандыр. Тикмәгә генә фатир вәгъдә итмәсләр. Дөрес, Рәйсә кайтуга ук эшкә йөгермәгән. Чөнки ул декрет ялында була. Рәйсә белән Хәмәтнәкыйф Әхсәновларның уллары туа. Ире тракторга утыра. Ел ярым чамасы үтүгә, Рәйсә дә фермага эшкә чыга. Тана-бозаулар карый. Малларны баладай күреп тәрбияләвен күргәннәрдер инде, бераздан аны ферма мөдире итеп куялар. Ул караган терлекләрнең көненә бер килограмм һәм аннан да күбрәк артым бирүе – күрелмәгән хәл, үзе бер хикмәт була. Шуның өчен аны 10 мең сум премия белән дә бүләклиләр әле. Инде менә ул республиканың «Иң яхшы зоотехнигы». Шул хакта сүз башлыйм да, ишеткәнемнән үземчә нәтиҗә ясыйм: бер уйлаганда, уңышларга ирешү, хезмәтеңне бөтен нечкәлекләре белән белү өчен академияләр тәмамлау ул кадәр үк мөһим дә түгел икән. Рәйсә бит әнә белгече буенча – аш-су остасы. «Үзеңне үзең кызганмыйча эшләсәң», – ди ул, уңышларының серен шул рәвешле аңлатып. Ә үз-үзеңне кызганмау, аныңча, малларны ярату. Ул аларны «йоклатып», төн уртасында гына өенә кайта, ә иртән – алар баш калкытканчы, тагын килеп җитә. Әйтерсең, фермадан китеп тә тормаган. Бәлкем, шуңадыр да, малның хәлэтен йөрәге белән тоя. Хастага сабышкан малга уколны да ул үзе ясый, үзе аерым рацион белән ашата да. Бозаулаган сыерларны да күздән ычкындырасы түгел. Көненә өчәр мәртәбә савып тормасаң, җиленне шешәргә мөмкин. Ул шулай ди. Шундук хәтерендә калган кайбер вакыйгаларны да исенә төшереп ала.

– Бервакыт сыерның бозавы дөрес килмәде. Бозауны аягыннан тартып чыгарганчы, бик озак вакыт үтте. Әнисе дә, бозавы да исән калды, дип и-и куаныштык аннары.

Фермага иртәнге сәгать 4 тән торып чыгып китеп, өйгә төн уртасында гына кайткан хатынын Хәмәтнәкыйф: «Ник соң кайттың?» – дип битәрләми инде хәзер. Хезмәтенең ни дәрәҗәдә җаваплы булуын аңладымы, эшне беренче итеп куйган Рәйсәсе белән килешә инде ул.

– Баштарак әйтә идем. Хәзер юк, – ди Хәмәтнәкыйф. Әңгәмәбез Әхсәновларның таштан салынган зур йортларында дәвам итә.

– Ничек өлгерә соң, алай булгач? – дим өйдәге чисталыкка ишарә ясап.

– Малайлар, – дип сүзгә кушыла хуҗабикә. – Кызлар юк ич безнең.

Олы уллары Рамил инде үзе күзле-башлы, гаиләсе белән Чаллыда яши. КамАЗда эшли икән. «Тәгәрмәчләргә көпчәкләр ясый», – дип төзәтә әниләре. Уртанчы уллары Риназ төпчеге Ришат белән вахтага чыгып йөриләр. Берсе дә эшсез утырмый. Өйгә яңа техника кайтып утыруын да сизми кала әле кайчак әниләре. Кер юу машинасын да егетләр алып кайтып куйган.

– Ял иткәнегез бармы, җиңел сулап куярдай чакларыгыз буламы?

Башта ул соравымны аңламыйча тора. Аңлап алгач, кул гына селти.

– Кая ул ял, маллар синең арка кыздырып ятканыңны көтеп ач утырсынмы?! Булмаганны, – ди ул, мине хәтәр эштә тоткандай. Безгә елның язы-көзе дә, җәе-кышы да юк. Дөрес, җәйләрен терлекләр җәйләүдә була. Әмма бу әле эш җиңеләйде, дигән сүз түгел. Җиңел сулыш алам, дип әйтә алмыйм.

«Ирләр – сансыз, эшкә җавапсыз карый. Ә Рәйсә белән эшләргә була», – ди Нияз Шәмсетдинов.

Авылның киләчәге турында сөйләшү күңелдән китми. Туган ягы – Мамадыш районының Еники-Чишмә авылында мәчет салдырган, бөтен дөньяга гөрләтеп, инде җырларга күчкән зур чишмә ясаткан, Мәшләк авылына юллар күтәрткән, иңгә-иң эшләүче хезмәттәшен «Рәйсә генә булдыра ала», – дип күкләргә чөйдергән, халыкка бары игелек кылу турында гына уйлаган шундый җитәкчеләр, һәм әлбәттә инде, Рәйсә ханым шикелле эштән башканы белмәгән дә, күрмәгән дә кешеләр булганда, авыл бетмәс, яшәр ул! Кемгә ничектер, ә безнең менә Мәшләктән күтәренке күңел белән китеп барыш...



■ «Өч малайның өчесе дә өй эшләрен белә: җыештыралар, ашарга пешерәләр, керләремә кадәр үтүкләп куялар. Миңа эш калмый да», – ди Рәйсә.

ҖӘМГЫЯТЬ



Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты Илһам Шакировны 80 яшьлек юбилее белән котлап, аңа республиканың «Фидакарь хезмәт өчен» медален һәм «Форд Мондео» автомобиле ачкычын тапшырды. Бөек җырчының юбилей кичәсе Г. Камал театрында узды.

ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова Казандагы Бөек Ватан сугышы музее каршында эшләп килүче «Сугыш чоры балалары» клубы әгъзалары белән очрашты. Анда татар телендә яңа гына чыккан «Сугыш чоры балалары» дигән китап парламентка бүләк итеп тапшырылды. Әлеге китап халык инициативасы белән туган, аны сугыш чорында үскән һәм бүген шул исемдәге клубның әгъзалары булып торган кешеләр язган.

Татарстанда «Гаиләм шәмаиле» дигән акция игълан ителде. Ул дүрт номинациядә үткәрелә: «Профессиональ каллиграфия», «Үзешчән каллиграфия», «Балалар иҗаты», «Гаилә ядкаре». Иң яхшы эшләргә конкурс 15 майдан 15 июльгә кадәр Колшәриф мәчете залларында узачак. Җиңүчеләр Идел буе Болгарында ислам кабул ителүгә багышланган бәйрәмдә игълан ителәчәк.

МӘДӘНИЯТ



«Казан Кремле» музей-тыюлыгының «Манеж» күргәзмә залында «Борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге: үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән экспозиция ачылды. Анда XVI йөз әйберләре, 2010–2012 елларда Болгар шәһәре территориясендә табылган алка, беләзек, йөзек, асма бизәк, каптырма һәм башка бизәнү әйберләре урын алган. Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге Зөя шәһәрчеге белән бәйле рәссамнарның эшләре экспозициягә баетып җибәргән.

Татар классигы Нәкый Исәнбәт һәм Сирия драматургы Саадалла Ваннус әсәрләре буенча куелган атаклы «Хуҗа Насретдин» яңадан Камал театры сәхнәсенә әйләнеп кайтты. Яңа премьерада Фәнис Җиһанша, Миләүшә Шәйхетдинова, Зөлфирә Зарипова, Ринат Таҗетдинов, Илдар һәм Искәндәр Хәйруллиннар уйный. Спектакльне баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштергән, рәссамы – Сергей Скоморохов, композиторы – Эльмир Низамов.

Режиссер Рөстәм Рәшитовның «Айсылу» кыска метражлы фильмының премьерасы мәдәният тормышында зур вакыйга булды. Сюжет буенча, Айсылу авылда – пенсиядәге әнисе белән яши, беркайда да эшләми. Авариягә эләккәннән соң, гарип калып, култык таягында гына йөри. Әмма ул – талант: искиткеч җырлый. Балачак дусты Йосыф музыка продюсеры икән. Ул кайтып төшә, һәм вакыйгалар көтелмәгән борылыш ала...
Фильмда Г. Камал һәм Г. Кариев исемендәге театр артистлары уйный. Айсылу ролендә – Г. Кариев исемендәге татар яшьләр театры артисты Гөлназ Галиуллина.

КОТЛЫЙБЫЗ



**«Ярдәм» тернәкләндерү үзәге директоры Мәликә Гыйльметдинова Россия кеше хокукларын яклау буенча вәкиле Элла Панфилованың Рәхмәт хатына ия булды.
Хат Татарстанда 2014–2018 елга Кеше хокуклары стратегиясен тикшерү барышында тапшырылды.**

МӘГАРИФ

Эшче һөнәрләрнең дәрәҗәсен күтәрү максатыннан «Казан ярминкәсе»ндә «Мәгариф. Карьера» күргәзмәсе ачылды. Ул урта һөнәри уку йортлары мәктәп укучыларын, абитуриентларны квалификацияле эшчеләр әзерләү программасы белән таныштырды, тормышта дөрес юл сайлауның мөһимлеген җиткерде.

СПОРТ



Кайбыч районында «Салават күпере» дип исемләнгән бассейнлы спорт комплексы ачылды. Аны ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре катнашты. Универсаль спорт залында мини-футбол, волейбол, баскетбол, бадминтон мәйданчыклары, өлкәннәр һәм балалар өчен бассейннар бар. Халыкара класслы спорт мастеры, 37 тапкыр Россия чемпионы Яна Мартынова һәм Россия чемпионаты финалисты Элина Максумова йөзү буенча мастер-класс күрсәттеләр.

Казанда су төрләре спорты буенча FINA Дөнья чемпионатына билетлар сату башланды. Халыкара турнирга билетларны бүләк сертификатлары рәвешендә дә алып була. Ярышлар вакытында тамашачылар җәмәгать транспортында бушлай йөриячәк.



УЛ – МАММОЛОГИЯ ҮЗӘГЕ ҖИТӘКЧЕСЕ, ТАНЫЛГАН МАММОЛОГ-ХИРУРГ. ХАТЫНЫ, БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН ӨЗГӘЛӘНЕП, ЧИКСЕЗ МӘХӘББӘТЕ БЕЛӘН ҖИЛ-ДАВЫЛЛАРДАН САКЛАП ТОРУЧЫ КАЙГЫРТУЧАН ИР ҺӘМ ӘТИ...

СИН БУЛГАНДА...

Мәдинә КАШАПОВА

Безгә аларның барысын бергә җыеп сөйләшү насыйп булмады. Гаилә башлыгы – һәр минуты исәптә булган күренекле маммолог-хирург. Кызлары – Лондонда. Улларының көне мәктәп белән Спорт сарае арасында уза.

Бу гаилә белән танышуны хуҗабикәдән башлыйк дигән идек тә, ә ул әнә: «Башта ирем белән сөйләшегез», – дип, юлыбызны иселе ил чикләрен үтеп, дөньяга тарала башлаган Республика онкология клиник хастаханәсенә борды.

...Дивар буйлап тезелгән урындыкларда – табибның соңгы сүзен көтеп, тын калган хатын-кызлар. Коридорда алма төшәрлек тә урын юк. «Сез кем янына?» – дип кызыксынам.

– Хәсән Маратовичка, – ди озын чиратның ахырында утыручы яшь кенә ханым. – Минем арттан булырсыз. Иртәрәк килеп җитә алмадым, – ди ул, уфтанып. – Ерактан килдем. Марий Иленнән үк. Танышым биредә дәваланды. Безнекеләр: «Соң инде», – дип Казанга җибәргәннәр. Шушы Маммология үзәгенә килеп табиб Гобәйдуллинга күренгән. Ул карап тикшергәннән соң, операция көнен билгеләгән. Менә бер ел инде кайгы-хәсрәтсез яши, күкрәген дә саклап калган. Их-х, миңа да булыша алса икән... «Булышыр, – дим, – һичшиксез булышыр». Ул, чиратсыз алга үтүемә кәефе кырылыпмы, мине канәгатьсез карашы белән озатып кала.

Аның кул астында – авыруларны үлемнән алып калу өчен медицинаның иң алдынгы ысулларын файдаланучы гаҗәеп кешеләр.

– Көтәләр анда Сезне, – дим, маммолог-хирург Хәсән Марат улы Гобәйдуллин янына керүгә.

– Көн саен шундый хәл, – ди ул. Сүз үзеннән-үзе хатын-кызны ут йотарга мәҗбүр иткән күкрәктәге яман шеш авыруларына барып тоташа. Хәер, гомерен шушы чиргә каршы көрәшкә багышлаган табиб тагын ни хакта сөйләсен инде?! Менә хәзер дә ул үзе минем белән сөйләшә, ә уйлары һаман аны зарыгып көтеп утыручыларда... Һәркайсын тыңлап, карап чыгасы бар, дәвалауның иң дөрес юлын табасы. Үзебезнекеләрне генә түгел, ераклардан да килгән авыруларны кабул иткәннән соң, ул операциягә кереп китәр. Аларның һәркайсы – катлаулы, һәркайсы үзенә күрә кабатланмас. Елына 250 шәр операция ясаган хирург, уңышлы чыгасына иманы камил булмаса, операция өстәле янына килеп тә басмый.

– Иң авыры нәрсә, операциямe? – дим.

– Иң авыры – хатын-кызны операциягә күндерү, – ди ул. – Бу аларны куркыта. Сөйләшә-аңлата башлагач кына ризалашалар. Медицинага бит көннән-көн алдынгы ысуллар керә бара. Инде операция вакытында да берьюлы ике эш башкара алабыз: шешне алуга, шундук имплант куябыз. Мондый ысул белән операцияне илдә беренчеләрдән булып без ясадык.

Белем артыннан – Европа илләренә

– Сезгә бирелгән бүләкләрме? – дибез, дивардагы дистәләгән дипломнарны күздән кичереп.

Ул өстәл тартмасыннан тагын бер дистә сертификат-дипломнар чыгара. «Монысы Италиядән, монысы Испаниядән, монысы Германиядән кайтканы...» – дип санап китә. Кайларда гына, нинди генә илләрдә булмаган, нинди генә дәрәҗәле мөнбәрләрдән чыгыш ясамаган икән ул! Укыган да, белемен дә күтәргән, тәҗрибә дә туплаган. Һәм боларның барысына эшне ахырынача һәм бары сыйфатлы итеп башкару нәтиҗәсендә ирешелгән. Һәр операция аның йөрәге аша узган. Операцияләрнең һәркайсы уңышлы үтсен өчен никадәр көч, белем, тәҗрибә, сабырлык кирәклеге аңлашыладыр инде, минемчә... Дөрес, гадәттән тыш хәлләр дә булгалыйдыр. Тик табиб бу хакта сөйләргә яратмый.

Ул Маммология үзәгенә институттан соң – интернатура, аннан ординатура тәмамлап, Яшел Үзән районы үзәк хастаханәсенең онкология бүлегендә эшләп килә. 1999 елдан бирле шушында. Үзәкне җитәкләргә алынуына да азмы-күпме тупланган эш тәҗрибәсе булышкандыр. Ә менә 2011 елдан – түләүлегә әйләнгән Маммология үзәге җитәкчесе.

– Бездә белгечләргә эләгүе кыен түгел, – ди җитәкче. – Гадәттә, табибка кереп җиткәнче бик күп анализ тапшырырга кушалар. Ул яктан бездә уңайлы – барысы да үзебездә башкарыла, хәтта иминият полисын да сорамыйбыз. Шунлыктан читтән килүчеләр дә шактый.

> *Ул ясый торган операцияләр – уникаль. Хирург хатын-кызны яман шештән коткарып, үлемнән генә саклап калмый, имплант ярдәмендә яңадан тормышка кайтара.*

Ул кечкенәдән үк табиб булырга хыялланган. Башка уй башына да кереп карамаган. Әңгәмәдәшем шулай ди. Бәлки, Яшел Үзән районының үзәк хастаханәсендә озак еллар гинеколог булып эшләп, шуннан лаеклы ялга чыккан әнисе Нәҗия апаның да йогынтысы булгандыр. Шәфкатьлелек һәм шуның белән бергә ирләргә хас тәвәккәллек тә, кырыслык та бар аңарда.

Ачлык елларында бабаларының Үзбәкстан якларына күчеп китүе, аннары тормышлары рәтләнә башлагач, әнисе туып-үскән Яшел Үзән районына кайтып урнашуы хакында бик еракта калган якты-кадерле истәлек итеп сөйли ул. Кечкенә Хәсәнгә әле ул чагында нибары алты яшь була. Аннан соң... уку еллары, урта мәктәпне көмеш медальгә тәмамлап, Казан дәүләт медицина институтына укырга кергән бәхетле көннәр... барысы да матур бер хатирә булып артта кала бара. Әмма берсе дә онытылмый.

Әнә ул, 3 нче курста укучы студент егет, Яшел Үзәннән Казанга барырга электричка көтә. Платформа тулы аның кебек яшьләр. «Шунда бер кызга күзем төште, – дип елмаеп искә ала ул. – Чибәр, зифа буйлы... Бик ошаттым. Танышып киттек. «Үзем дә төшеп калганнардан түгел, – ди дә көлеп җибәрә. – Ике еллап йөргәннән соң, өйләнештек. Бергә яши башлавыбызга тиздән чирек гасыр була. Мин аны һаман яратам, бик яратам», – ди ул хисләренә бирелеп.

– Мәхәббәтнең мәңгелек булуына ышанасыз алайса?

– Ышанам...

Хатыны Лилия Миңнехан кызы турында ул сәгатьләр буе сөйләргә дә әзер.



Лилия дә – үзенчә табиб. Ул чәчәк кибетеннән үлеп баручы орхидеяларны сатып ала да терелтә. Бу – аның күңел юанычы.

– Озак еллар банк өлкәсендә эшләде. Хәзер өйдә, – дип дәвам итә гаилә башлыгы. – Ул өйдә булганда, күңелем тыныч. Чыгып китәм, ул – өйдә, кайтып керәм – ул өйдә! Миңа аның белән җиңел, рәхәт. Күпме яшәп сүзгә килешкәнебезне дә хәтерләмим. Ул әйбәт хуҗабикә, аш-суга оста. Бер эшкә тотынса, туктатам димә. Өчпочмагын да пешерә, бәлешен дә сала. Кыяр-помидор тозлый башласа, бөтен дөнья банкалар белән тула. Эшкә алып китеп өләшәм аннары. Ашап бетерерлек кенә түгел.

Лилия, рәхәтләнеп, дөньяларын онытып, ире, балалары турында сөйли...

Бөтен мәхәббәтен, яратуын бер сүзгә салып, хатынына «Матурым» дип эндәшә. Өйнең һәр почмагы саен мәхәббәт җылысы бөркелеп торган җитеш-тату гаиләдә ике бала үсә. Хәер, кызлары Дания инде күптән әти-әни оясыннан очып киткән. Аңа хәзер 22 яшь. Ул – мөстәкыйль, тәвәккәл һәм кулы нәрсәгә тисә, шуны булдыра торган. Заманында – моннан ун еллар чамасы элек «Яшел Үзән шәһәренең нәни гүзәле-2004», «Европаның нәни гүзәле-2004», «Дөньяның нәни вице-принцессасы», «2004 елның иң атаклы туташы»... Әйе, әйе, Лилия һәм Хәсән Гобәйдуллиннарның кызы Дания Гобәйдуллинаны без әле үзебезнең журнал тышлыгында да биргән идек. «12 яшьлек кыз балага таң калырлык мондый биеклекләргә ирешү өчен, әйткәнебезгә өстәп, һичшиксез, тырышлык, сабырлык һәм ихтыяр көче дә кирәк», – дип тә язганбыз әле.

– Хәзер ул Лондонда, магистратурада укый. Финансист-аналитик булачак. Һәм КФУның юридик факультетында читтән торып белем ала, – ди әтисе горурланып. – Ул Казанда төрек лицеенда укыды. Бүген төрек, испан, инглиз һәм татар телендә сөйләшә.

Уллары Данис 9 нчы сыйныфта укый. Сәләте торган саен ачыла бара. Егет җиңел атлетика белән шөгыльләнә. Озын дистанцияләргә йөгерә икән. Димәк, анда көч тә, сабырлык та җитәрлек. Былтыр яшүсмерләр арасында илкүләм уздырылган ярышта ул 14 нче урынны яулаган.


Сәнгать мәктәбен тәмамлаган Данис табигать күренешләренең гаҗәеп мизгелләрен мәңгеләштерә.

– Ял көннәрендә өйдә утыру эләкми безгә, – ди Хәсән Марат улы. – Ул безне йә табигатькә алып чыгып китә, йә шәһәргә. Чаңгы шуабыз, ул сноубордта чаба, фотога төшерә. Аннары аларны интернетка урнаштыра. Калганын Лилия үзе сөйләр, – ди табиб, сөйләшүнең тәмам булуына ишарәләп. Сизелеп тора: күңеле белән ул инде ут йотып утырган авырулары янында.

«Ул – безнең гаиләнең җаны»

Кызлар шикелле җыйнак гәүдәле ханым үзе дә бала сыман гына. «Хәсәннең дә эштән кайтып бусагадан атлап керүгә беренче әйткән сүзе шул», – дип елмая Лилия. – Сылуым, кошчыгым дигән була. О-о-о, өйдә нинди хуш исләр... – ди. Күтәрә белә ул күңелне. Ул кайтып керүгә өйдә бөтен нәрсә хәрәкәткә килә. Җор телле, шаян. Күңел төшенкелегенә бирелеп, җебеп утырырга юл куймый безгә».

Без аңа сорау да бирмибез. Лилия дә Яшел Үзәннән. Финанс-икътисад институтын тәмамлап, шактый еллар банк системасында эшләгән. Кассирдан банк идарәсе башлыгы дәрәҗәсенә күтәрелгән ханым, уңышның сере бары үзеңнән тора ди. Һәм дөрес әйтә. Аңа берәү дә булышмаган, ул барысына да үзе ирешкән.



Алга таба да тыныч кына эшлисе дә, эшлисе иде дә бит... Лилия ханым кинәт тукталып кала. ...Аннан сүзен янә иренә күчерә. Ничек танышканнар, ничек табышканнар... Бер-берсен ничек ярата алар!..

25 ел гомер иткән кешеңә карата мәхәббәтне бүген гашыйк булгандай сакларга кирәк бит, ә?!.

Без гәпләшкән арада телефон шалтырый. «Ирем, – ди телефонын куйгач Лилия. – Даруыңны эчтеңме дип сорый. Сине тормыштан да ныграк яратам ди. Көн саен шалтыратып шулай ди», – ул моңсуланып китә.

Лилия моннан берничә ел элек, каты авырып, 20 көн комада ята. Яраткан эшеннән китүенең сәбәбе дә шул. «Хәсән эшләргә кушмый, – дип аңлата хуҗабикә. – Бөтен игътибарым иремә, балаларыма хәзер. Балаларым өчен борчылам: үз юлларын табарлармы? Бәхетле булырлармы? Илләр генә тыныч-имин булсын».

Әни кеше юкка хафалана. Бары ярату телендә генә аңлашкан гаиләдә тәрбияләнгән балаларга киләчәккә ишекләр инде күптән киң итеп ачылгандыр.

– Дания кечкенәдән биюгә йөрде, Европа бәйгеләрендә катнашты, – ди Лилия. – Бүген ул Лондонда, иң шәп дип йөртелгән биш уку йортының берсендә белем ала. Телләр белә, миннән шәбрәк итеп татарча сөйләшә. Юк дип әйтә белми. Ул – әтисе кызы. Данис белән алар бик дуслар. Көн саен скайп аша аралашалар. Бер-берсе өчен үлеп торалар.

Теләсә кайсы хуҗабикә кызыгырлык болындай зур кухняда – түргә менеп кунаклаган суыткычның ишегендә дә кәгазьгә язып эленгән «яратам» сүзләре... Шулай инде. Ярату ташып торган гаиләдә ничек инде бала бәхетсез булсын?! Баланың алдагы көне әтиәнинең мөнәсәбәтенә нык бәйле. Бу хакта азга гына да истән чыгарырга ярамый.

– Данис та әтисе шикелле табиб булам ди. Авырый башласам, янымнан китми. Сораштырган була, кай җирең авырта, ничек авырта. Аннары дару китерә, массаж ясый башлый. Укуын әйбәт укый, спорт белән шөгыльләнә. Шөкер, балалар бер проблема да тудырмый, – ди ул аларның уңышлары өчен ихлас куанып. – Даниянең йөргән егете дә бик әйбәт. Бер кайтуында шалтырата шулай: «Тәрәзәгә кара әле», – ди. Инде төн уртасы җитеп килә иде. Дания белән икәүләшеп йокы бүлмәсендәге тәрәзәгә капландык. Карасак, җиргә утлы шәмнәрдән «Мин сине яратам!» дип язып куелган. Яшьләр мәхәббәтләрен матур итеп аңлата белә шул. Без өйләнешкәндә барысы да күпкә гадирәк иде. Танышуыбызга ук әниемә роза чәчәкләре күтәреп килде Хәсән. Әниемне бик хөрмәт итә ул. Очрашсалар, сөйләшеп сүзләре бетми. Кайчак шаяртып: «Аерылыша калсак, әнине – минем әнине – сиңа бирмим», – дип шаярта. Әни дә аны үз баласыдай күрә. Икең дә яхшы булганда гына бит ул! Безнең беркайчан ачуланышкан юк. Миллионга бер ул минем Хәсән! Ирем янәшәдә булганда миңа берни дә куркыныч түгел, мин аның белән бәхетле! Чын мәгънәсендә ир кеше ул. Бер генә нәрсәгә үкенәм: ике генә бала тапканмын. Дүртне, бишне табасы калган...

Аңа ниндидер бер карарга килү өчен дүрт секунд вакыт җитә.

Бер-берсен яратышып гомер кичкән, бер-берсен ярты сүздән аңлаган, бер-берсе турында сокланып сөйләгән парлар, Лилия әйтмешли – миллионга бер! Андыйлар хакында: «Никахлары күктә язылган...» – диләр. Лилия белән Хәсән Гобәйдуллиннар да шулар исәбендә...

P. S. 2005 елдан башлап 4 февраль Бөтендөнья онкологик авыруларга каршы көрәш көне дип игълан ителде. Быел ул «Яман шеш ерак йөрми...» дигән девиз астында узды.

■ Дөрес яшәү рәвеше алып барганда, күбрәк яшелчә, җиләк-җимеш ашаганда (мәсәлән, петрушка составында яман шеш күзәнәкләре үсешен тоткарлый торган матдә бар) чир азмый калырга мөмкин. Әмма бу дәвалауны алыштырмый. Елга бер тапкыр маммологка күренергә кирәк!

■ Күкрәк формасы бозыла дип, баласын имезүдән баш тарткан хатыннарга да киңәшем бар: баланы тилмертмәгез, күкрәктәге үзгәрешләр балага узгач ук башлана. Имезү күкрәккә тәэсир итми.

■ Соңгы вакытта күкрәк формасын үзгәртергә теләүчеләр дә бик күп. Кайсы кечерәйтүне, кайсы зурайтуны сорый. Зыянлымы бу? Профессиональ клиникада эшләнгәндә мондый «төзәтмә» зыян китерми. Бездә андый операцияләр алдыннан пациент җитди тикшерү уза. Шик бар икән – ясамыйбыз гына.





БАР УЛ СИН ЭЗЛӘГӘН КЕШЕ...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

TATARLOVE. БЕЗНЕҢЧӘ «ТАТАРЧА МӘХӘББӘТ» БУЛА ИНДЕ.

Татар егет-кызлары очраша, аралаша торган танышу сайтын башкача ничек атыйсын?! Кыска да, җиңел дә, аңлаешлы да. «DuslarMedia Group» җитәкчесе Алсу ВӘЛИЕВА шулай ди.

Алсу үзе дә мәхәббәтләрен танышу сайтларында тапкан. Беренчесен дә, икенчесен дә. Башта Әнвәрне... «Әнвәр» исеме чыгу белән аның күзләренә шунда ук мөлдерәп яшь тула... «Гафу итегез, мин аның хакында күптән инде берәү белән дә сөйләшкәнем юк. Әнвәр турында сүз кузгатуның минем өчен никадәр авыр икәнлеген якыннарым белә...»

Алар икесе дә Мәскәүдә туып-үскән. Мәскәүдәге татарларның күбесенеке кебек, нәселләре Сергач якларыннан. Алсуның балачакта бөтен җәйләре Түбән Новгород өлкәсендә – Симочки, Кадем авылларында уза. Мишәр әбиләр Мәскәүдән кайткан оныклар белән татарча гына сөйләшә! Хәер, бу мәсьәләдә әти-әнисе дә

үзләрен шактый кырыс тота: өйдә сөйләшү туган телдә генә булырга тиеш! «Ирем башка милләт кешесе булырга мөмкин дигән уй башыма да кермәде!» – Алсу шулай ди дә, күз яшьләрен сөртергә дә онытып, төп сүзгә күчә:

– Түбән Новгород татарларына Мәскәүдә җиңелрәк, алар гел үзара аралашып яши. Шуңа күрә үземне беркайчан да ялгыз тойганым булмады. Әмма кем беләндер якыннан танышу теләге бар иде. 2006 ел, интернетның безнең тормышка яңа кереп кенә килгән чагы. Татарча сайтлар эзли башладым, унлапны таптым. Гади генә булса да, арада танышу сайты да бар иде. Теркәлеп, ике-өч көн узуга миңа хатлар килә башлады.

Әнвәр Хөсәенов дигән егетнең җавабына нигә игътибар иттем икән, белмим... Хаты бик озын иде аның. Күренеп тора – язганчы озак уйлаган. Әмма хатны миңа гына җибәрмәгәнен укуга аңладым. Үзенә шулай дидем дә: «Меңнән берәү буласым килми», – дидем. «Сәлам, хәлләр ничек?» – дип язу гына кирәкмени? Кайсы мөһимрәк соң сиңа?» – дип ул үпкәләде дә әле. Акыллы, уйлый белә торган кеше икәненә бик тиз төшендем. Ә ул мине башта... җилбәзәгрәк дип кабул иткән. Ул чакта фото кую гадәте юк иде әле. Берәр атна аралашкач, югалуы шуңа булган икән. Соңрак аңлаштык... Февраль ае иде ул. Аннан ул миңа шалтырата башлады. Төннәр буена сөйләшүләр башланды... Март ахырында, Коломна паркында очраштык. Дүрт елдан соң нәкъ шул көнне өйләнештек. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты...

Танышканда ук Әнвәр Алсуны: «Миңа үземнән соң эз калдырырга кирәк. Күпме яшәдем, ә бит әле бернәрсә эшләргә өлгермәдем...» – дип шаккаттыра. Аңа бу вакытта 21 яшь. Институтның соңгы курсында, программист булырга укый. Ел ахырында ул: «Без синең белән заманча танышулар сайты эшләргә тиеш! – дип, Алсуын икенче кат шаккаттыра. – Синең белән мин танышкан Юлдаш сайты инде замана таләпләренә җавап бирми».

Хыялын тормышка ашырмаса Әнвәр буламы?! Яңа ел бәйрәменнән соң ул ун көн буе компьютер каршында утыра... Сайт февраль урталарына әзер була. «Әлбәттә, ул башта шактый гади иде, – ди Алсу. – Теркәлү, анкета тутыру һәм аралашу мөмкинлеге генә бар иде. Дөрес, фото да куя алалар иде». Февраль уртасында алар Татарлендның доменын рәсмиләштерәләр. Татарленд – «Татар дөньясы» баштан ук танышу сайты гына булмаячак дип уйланыла. Инде аны таныту кирәк бит. Ә моның өчен ресурслар әле юк дәрәҗәсендә. ВКонтакте, Одноклассники социаль челтәрләрендә дә эшли генә башлаган мәле. Беренче баннерны Әнвәр белән Алсу үзләре танышкан Юлдаш сайтында урнаштыралар. (Юлдашның хуҗасы Илсур аларга эшләрен җайга салырга бик нык булыша.) Бер айга. «Халык агылып керер дип хыялланмадык, – ди Алсу. – Әмма бер ай эчендә без 4 мең кулланучы җыйдык!»

Алсуның аудитор фирмасында, Әнвәрнең сайтлар әзерләүче компаниядә эшләп йөргән чагы әле. Ә кичләрен үз сайтлары көтә: берсе аны камилләштерү, икенчесе таныту белән шөгыльләнә. «Яшьләр безнең сайтта беренче адымны ясады – танышты, инде аларга хәрәкәт кирәк иде, – дип сөйли Алсу. – Һәм шул вакыт, аудиториябез барлыгын белеп: «Без Мәскәүдә татар кичәләре үткәрәбез, әйдәгез, бергәләп оештырыйк», – дип яныбызга килделәр. «Әйдәгез!» – дидек. «Фреш» клубында үткәргән беренче кичәгә 500 гә якын кеше килде! Ишек төбенә зур чиратлар тезелде. Клуб 350 урынга гына исәпләнгән иде. Бер яктан, әйе, аншлаг иде бу, икенче яктан... Казаннан татар диджеен – Шәкертне чакырдык. Ул башыннан ахыргача татарча гына уйнады: Мәскәү яшьләре моны да кабул итеп бетермәде. Ялгышларны төзәтә-төзәтә кичәләрне дәвам иттек...»

2007 елның июнендә Татарленд сайтында ун меңенче кеше теркәлә. Дүрт ай эчендә! Баш әйләнерлек уңыш! Әле бит рекламасыз, «чыбыксыз телефон» аша таралган хәбәр буенча гына. Шулкадәр көтелгән, кирәкле проект булып чыга ул. Әнвәр белән Алсу уртак карарга киләләр: «Икебез дә эштән китәбез».

Бездән алган сувенирлар һәркемгә татар икәнлеген хәтерләтеп тора. Шуңа күрә бу бизнес кына түгел дип саныйм.

2008 елның язында алар Дуслар сайтының доменын сатып алалар. Ә июль аенда Татарленд базасын Дусларга күчерәләр. Шактый җитди, тәвәккәл адым була бу: ул көнне Татарлендка керүчеләр Дусларга эләгә. Ә моны ошатмыйча алардан баш тартсалар? Утыз җиде мең кулланучыны югалту уен эш түгел...

Тормыш эшкә үзгәрешләрне, яңалыкларны үзе кертә бара. Бераздан аерым танышу сайты кирәклеге дә ачыклана. 2009 елның көзендә Tatarlove.ruны эшләтеп җибәрәләр.

Дусларның ярты кулланучысы мәскәүлеләр була. Бу аңлашыла да, интернетның регионнарга әле барып җитмәгән чагы. Ә Татарлав эшли башлаган беренче айда ук кулланучыларның 50 проценты Татарстаннан икәне ачыклана! (Татарлавта бүген 350 меңнән артык куллану-

Татарские подарки родным и близким
tatarmarket.ru
интернет-магазин татарских товаров
тюбетейки футболки посуда товары детям открытки книги мусульманские товары музыка
www.tatarmarket.ru +7(495)7493032 г. Москва, М.Татарский пер., 8
РЕКЛАМА



■ Ярты ел эчендә алар шуны аңлый: танышу сайты үз чикләреннән чыгып бара. Әйе, яшьләр таныштı, әмма сайттан китәргә теләмиләр. Әнвәр чат ясый, аннан форумны эшләтеп җибәрә. Ул чакта аралашуның иң популяр юлы була бу. Яшьләр аны бик тиз кабул итә. Ә Әнвәр белән Алсу яңа уй белән яна башлыйлар: «Татарча социаль челтәр оештырабыз!»

чы теркәлгән. Бер көнгә бу сайтка 20 меңгә якын кеше керә. Шуларның 30 проценты – Татарстаннан, өчтән бере – Мәскәүдән, калганы – башка төбәкләрдән).

Дусларның бүгенге көндә кулланучылары – 110 мең.

Инде TatarMarket интернет кибетләренең барлыкка килү тарихы турында. Татарленд аша Алсу һәм Әнвәр белән танышып: «Әйдәгез, менә моны эшләп карыйк әле!» – дип яннарына килүчеләр бик күп була. Алар һәркемгә: «Әйдәгез!» – дип җавап бирәләр. Рөстәм Мингалиев татар язулы футболкалар эшләү идеясе белән килә. «Без тотынып карадык, күпләргә ошый, әмма аны таратырлык публикабыз юк», – ди ул. Хәтта әзер макетлар да калдыра. 200 ләп футболка әзерлиләр һәм сайтта интернет-кибет ачып җибәрәләр – җәй эчендә футболкалар таралып бетә. 2009 елны татар язулы футболкаларны Люберцы шәһәрендә узган Сабантуйга алып чыгалар: күз ачып йомганчы халык аларны алып та бетерә. «Офлайн проекттан мондый уңыш көтмәгән идек, – ди Алсу. – Без бу өлкәдә новаторлар булдык. Рөстәм әлеге идеясен әйтмәсә, TatarMarket интернет-кибете ачылмас та иде, мөгаен. Хәзер безнең заказлар бөтен Россия буйлап китә – алар буенча татарлар кайда яшәгәнен өйрәнергә була. Моңарчы заказ бирүдә Төмән шәһәре лидер иде. Мәскәүләр үзләре күп ала, әлбәттә. Ассортимент инде бик күпкә киңәйде. Нинди татар сувенирлары кирәк, һәммәсе бар бездә: түбәтәйләр, курчаклар, китаплар, савыт-саба... Ә барысы да шул «Мин сине яратам» дигән футболкалардан башланды...»

2010 елны Алсу белән Әнвәр өйләнешәләр һәм... Казанга күченәләр. Офислары – Болак буенда, торулары – Кекин йорты янында... «Татар мәдәнияте, сәнгате эчендә кайныйсыбыз килде», – ди ул.

«Бәхетләр генә кыска гомерле булды...» Күзләргә тагын мөлдерәп яшь тула...

Шул ук елны, җәй көне Әнвәр авырып китә. Аларга Мәскәүгә әйләнеп кайтмый чара калмый – Казан табиблары авыруының сәбәбен таба алмый. Башкалада исә: «Яман шеш», – диләр... «Сентябрьдә Әнвәр Россия Фәннәр Академиясенең гематология үзәгенә ятты. Ярты ел мин дә аның белән бергә палатада – кушеткада яшәдем. «Дәвалап булмый...» – дигән сүзне табиблар миңа Мәскәүгә килүгә әйтте. Әмма өметемне соңгы көнгәчә өзмәдем. Башта, чыннан да, алга китеш булды. Аннан яман шеш күзәнәкләре тагын да эчкәрәк үрмәләде. 1 февраль көнне миңа инде әзерләнергә куштылар... Хәтта шул хәлемдә дә аңа бер тамчы күз яшемне дә күрсәтмәдем. Кайлардан килгәндер миңа ул сабырлык, белмим. Бер атнадан без аны югалттык... Хастаханәдә ярты ел буе киләчәк турында сөйләштек, планнар кордык. Ул бер тапкыр гына: «Ахыры нәрсә белән бетәсен белмибез бит...» – диде. Бер ел да бергә яшәргә өлгермәдек... Юк, бу хәсрәт онытылмый. Аны оныту мөмкин түгел. Шуңа якыннарым белән Әнвәр хакында сөйләшмим дәдер. Төшләремә ул сирәк керә...»

Әнвәр авырый башлагач, сайт өчен бөтен җаваплылык Алсуга күчә: эшне ташлап булмый, даруларга акча кирәк. Ә иң авыр вакытта, үзе генә калган көннәрдә, аңа Марат ярдәм кулы суза. Программистлыкка укучы бу егет берара аларда курьер булып эшли (студентларны – шактый татар егетләрен эш белән тәэмин итә ул). Кызыксынуын, җаваплы икәнен күреп, Әнвәр аны эшкә өйрәтә. Ул чакта Марат, нәкъ ярты елдан, югары хезмәт хаклы эш урыны таба. Алсу, Әнвәрен җирләп, сайт белән бәйле проблемаларны ничек хәл итәргә белмәгәндә, шул Марат аның таянычына әйләнә. Әйе, яхшылык беркайчан җирдә ятмый, барыбер бер әйләнеп кайта.

Бүген сайтның техник ягы өчен Владимир җаваплы. Игътибарны күбрәк Татарлавка бирәләр – Алсу бу сайтның киләчәге өметле дип саный. Дуслар, әлбәттә, аксый төшә. (Нишләтәсең, Әнвәрнең юклыгы үзен адым саен сиздерә...) Әмма бу проектны да Алсуның бик яшәтәсе килә. Тормышка ашырырга өметләнгән идеяләре дә шактый.

«Без сезнең сайт аша таныштык...» «Шулай дип башланган хатларны укырга яратам», – ди Алсу. Ә андый хәбәрләрне көн дә ала ул. Үз туганнары арасында да Татарлав аша парлы булганнар шактый. Хәер, Рөстәм белән дә аларны сайт таныштыра.

«Мин бик күп вакытымны сайтта үткәрәм, – дип сөйли Алсу. – Кайчак аны төнгә дә сүндермичә калдырам. Гел онлайн булгач, әлбәттә, миңа хәбәр юллаучылар моңарчы да бар иде. Андыйларга җайлап кына: «Юк, мин танышмыйм», – дип җавап бирә килдем.

Ел ахыры, бик арган чагым иде. Шуңадырмы, төнлә килгән хатларның бу юлы кемнәрдән икәнен беләсем килде. Аларның берсе Рөстәмнән булып чыкты. «Әйдә, очрашабыз, киного барабыз», – дип язды ул. Мин... кинәт ризалаштым, әмма: «Асадуллаев йорты тирәсендә булса гына, офисым шунда», – дидем. Шактый катлаулы көнем иде ул: эшемнең очы-кырые юк... Без Рөстәм белән метрода очраштык. «Гафу ит, эшләремне төгәлли алмадым, бер җиргә керәсем

бар», – дим. «Ярар, мин сине көтәрмен», – диде. Метрода миңа шундый рәхәт иде: телефон тотмый – офиста гел нидер хәл итәргә, шалтыратуларга җавап бирергә кирәк... «Монда ял итәм», – диюемә ул дәшмәде, гаҗәпләнеп карады гына... Берничә көннән тагын шалтырата: «Әйдә, очрашабыз», – ди. «Мин тугызларсыз бушамыйм», – дим. «Ярый, шул вакытка килермен», – ди Рөстәм. Бу хәл бик озак дәвам итте... Мин тормышны ничек бар, шулай кабул итәргә өйрәнгән. Димәк, Аллаһы Тәгалә шулай тели, дип уйладым. «Мә, тот һәм башка беркайчан яныңнан җибәрмә», – дип биргәндер ул миңа Рөстәмне. Бик сабыр кеше ул. Алдагы сынауларым өчен – ирем миңа язмыш бүләгедер... Ул миңа бик тиз тәкъдим ясады. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды. Танышуыбызга ярты ел гына иде әле. «Мин моңа әле әзер түгел», – дидем. Үпкәләсә дә, сиздермәде. Ә аннан уртак танышларыбыз Рөстәмгә фатир сатып алырга тәкъдим иттеләр. Аның акчасы җитмәде, мин үземнекен куштым... Мин икеләнә башлагач, шундый хәл килеп чыкты менә. Ноябрьдә туебыз булды. Без бер елдан артык бергә...»

«Парларын табарга теләүчеләр бик күп», – ди Алсу. Көн саен, әйткәнемчә, Татарлавка 20 меңгә якын кеше керә икән. Әмма Алсуны иң сөендергәне – яшьләр үз милләтендәге егет яки кыз белән танышырга тели. Ә инде кавышып табышканнарның хатлары гел бер җөмлә белән башлана: «Гомерлеккә диган ярыңны интернет аша табып буладыр дип, ул да, мин дә уйламаганбыз...» Бәхетлеләрдән килгән ул хатларның азагы да гел бертөсле тәмамлана: «Бар ул син эзләгән кеше...»





Раиль-Альбина: Мине Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә өч айга командировкага җибәргәннәр иде. Кичләрен интернетта утырганда Tatarlove сайтына тап булдым. Екатеринбург шәһәреннән бер татар кызы белән аралашып киттек. Альбина тиздән безгә, Уфага туйга барырга җыена икән. Тик мин ул Уфада кунакта булган көннәрдә кайтып җитә алмадым. «Мин сезгә барсам?» — дигән соравыма ул: «Кил!» — дип җавап бирде. Бер күрүдән гашыйк булдым! Тик мине кабат Әмирлекләргә чакырып алдылар, аннан ике ай ярымга Парижга командировкага китәргә кирәк иде. Гашыйк җаннар өчен моннан да зур сынау була аламы?! Альбинаны үзем белән Франциягә барырга чакырдым. Икеләнеп булса да, килде ул. Париж ресторанларының берсендә, туган көнендә аңа: «Миңа кияүгә чык!» — дидем.



Руслан-Айсылу: Мәхәббәтне интернет киңлекләрендә очратып буладыр дигән уй башыма да кергәне юк иде! Мин Башкорстанда — Янаул шәһәрендә яши идем, Руслан — Волгоградта. Икебез арасында 1500 чакрым юл ята! Сайтта таныштык та, аралаша башладык. Могҗиза кебек булды ул! Без хәзер бергә. Кызыбыз Алсу үсә...



Рамил-Эльвира (Чиләбе өлкәсе): Миңа 26 яшь — өйләнергә вакыт җиткән иде инде. Кайдан гына эзләмәдем мин аны! Очратмадым... Булачак хәләл җефетемнең үзем белән бер милләттән, бер диннән булырга тиешлеген белә идем. Сезнең сайтка килеп эләктем. Һәм беренче көнне үк аның исемен белдем. Эльвира! Нәкъ бер елдан, август аенда без инде гөрләтеп туй иттек...



Наил-Әлфия (Санкт-Петербург): Без сезнең сайтта таныштык. Башта хатлар гына языштык, аннан, җәй ахырында, очрашырга тәвәккәлләдек. Бер күрешү барысын да хәл итте... Никахны Санкт-Петербург мәчетенең имамы Җафәр Пончаев укыды. Иң якыннарыбызны гына чакырдык: аның — улларын, минем — кызларны. Никахтан соң Петропавел кирмәне янындагы бакчага чыктык: шунда, яшел чирәм өстендә безнең «туй» булды. Көн искиткеч матур иде. Ә тагын берничә көннән миңа илле тулды, Наилгә аз гына күбрәк — 54. Әмма без яшебез турында уйламыйбыз!



Илдар-Люция (Красноярск): Яңа гына никах укыттык... Ул да, мин дә сезнең танышу сайтына кызык өчен генә теркәлгән булганбыз. Ә язмыш безгә анда шундый зур бүләк әзерләп торган! Бер-беребезне табуыбызда сезнең өлеш тә зур...


Иске парклар, бакчалар арасында Казанның Эрмитаж бакчасы игътибарыбызны җәлеп итәрлек, берничә буын шәһәр халкына билгеле һәм кадерле булган бакчаларның берсе. Аның Износковский, Александровский, Эрмитаж, Николаи бакчасы дигән исемнәре булган. 1917 елга кадәр дә, аннан соң да аны Эрмитаж бакчасы дип йөртәләр. Ул хәзерге Маяковский, Щапов, Некрасов урамнары кисешкән чатта урнашкан.
XIX гасырның икенче яртысында Казанда җиде шәһәр бакчасы, ике хосусый бакча исәпләнгән. Безнең көннәргә кадәр сакланып калган ике хосусый бакчаның берсе булган Эрмитаж бакчасы бүгенге көндә дә гел чистартылып, төзекләндерелеп торсын, киләчәктә дә шәһәребез халкын шатландырсын иде.
Сәхифәне ТР Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре Ленар НӘГЫЙМОВ алып бара.
(Язма Н. Агафоновның 1906 елда чыккан «Казань и казанцы» исемле китабындагы мәгълүматларга, музей архивындагы материалларга нигезләнеп язылды.)





Бакча 4 гектарга якын мәйданны били һәм өстән карaганда кеше йөрәгенә охшап тора.
Башта бу агач-куаклыклар белән капланган урында тау инженеры, дворян Ворожцовның йорты урнашкан була. Куе куаклыклар, юан-юан агачлар үскән, тирән ермак белән кискәләнгән бакчаның кешеләрне өркетә, шикләндерә торган урын буларак дан алуы да Ворожцов белән бәйле. Ул үзенең крепостнойларын үлгәнче суктыра, аннан соң аларны өй янындагы бакчада гына күмдерә торган булган. 1857 елда Ворожцов үлә, шуннан соң бакчага төрле елларда төрле кешеләр хуҗа булып тора. Кемдер бакчаны карап, тәрбияләп тора, кемдер аңа тиешле игътибар бирми. XIX гасырның 60 нчы елларында бакчаның яңа хуҗасы – Аверино фамилияле эшмәкәр аны казанлылар яратып йөри торган күңел ачу урынына әверелдерә. Монда җәйге цирк ачыла, анда халык өчен төрле тамашалар күрсәтелә.
Ике елдан соң бакчаның хуҗасы кабат алышына. Казанлыларга яхшы таныш булган эшмәкәр Ожегов беренче көннән үк бакчаны төзекләндерергә керешә: керү капкасы өстенә «Александровский сад» дигән язу элене. Бакча чистартыла, беседкалар, галереялар төзелә. Ул тиз арада казанлыларның яраткан урынына әверелә.







ЭРМИТАЖ БАКЧАСЫ



Бакча урнашкан калкулыктан Болак, Идел ягына таба гаҗәеп матур шәһәр күренеше ачыла. Ә еракта ага торган Идел үзе, сихерләгәндәй, карашларны үзенә тартып тора. Кичке алтыга кадәр бакчага керү бушлай, ә аннан соң керү «биш алтын» бәясе була. Иртәнге сәгатьләрдә бакчага күбрәк балалар, студентлар, олы яшьтәгеләр йөрсә, төштән соң бирегә купшы публика җыела. Затлы киемле ханымнар, аларны озата йөрүче кавалерлар үзара французча гына сөйләшәләр... Караңгы төшү белән, төп аллеяда төрле төстәге фонарьлар кабына.

Бакчада һәрвакыт ике оркестр уйный. (Оркестр белән Салих Сәйдәшев дирижерлык иткән вакытлар да булган.) Музыка тыңлап, шәһәр байлары рәхәтләнеп ял итә, уңайлы өстәлләр янында ашый-эчә, яннарында официантлар «биеп» тора. Махсус формадан киенгән кырыс йөзле сакчылар ял итүчеләрнең тынычлыгын саклый. Төнге өчкә кадәр музыка уйный. Күңел ачулар оркестр, цирк, павильоннар белән генә чикләнми; монда күккә фейерверклар чөелә, лотерея уйнатыла, театраль тамашалар уздырыла. Эрмитажда Сур ханымның гаиләсе атка атланып йөрү, фехтование, гимнастика дәресләре уздыра. Монда шулай ук көрәш ярышлары, могҗизалар төне уздырыла. Бу төндә аллеяларга утлы аждаһалар чыга, иң кыю кешеләр һава шарларында күккә күтәрелә. Бакчаның хуҗасы – шәһәр башлыгы Рудольф Николаи булганда, биредә велодром төзелә, велоспорт буенча ярышлар уздырыла.



Тирән ермак аша салынган киң күпер тамашачыларны агачлар арасында урнашкан җәйге театрга алып килә. Әмма ул тамашачылар өчен артык уңайлы итеп төзелмәгән: партердагы урындыклар тыгыз куелган, рәтләр арасы керү-чыгу өчен бик уңайсыз, арткы рәтләрдән сәхнәнең яртысы өлеше генә күренә. Сәхнәнең оркестр чокырыннан түбәнрәк урнашуы да тамашачылар өчен уңайсызлыклар тудыра. Декорацияләр ярлы, җитешсез, аз санлы булу өстенә, күп вакыт спектакль күренешләренә туры килмиләр. Шулай булуга да карамастан, ул тамашачыларның яраткан ял урыны була, моның шулай булуын залларның халык белән шыгрымлыгы да раслый. Талантлы актер һәм режиссер Петр Медведев Казандагы карьерасын җәйге театрдан башлый. Монда ул труппасы белән «Горькая судьбина», «Беда от нежного сердца» спектакльләрен, «Орфей в саду» опереткасын куя.

1913 нче елда «Камско-Волжская речь» газетасында шундый белдерү бастырыла: «...Бакча кишәрлекләргә бүленеп сатылачак, бер сажины – 30 сум». Шәһәр идарәсе шул рәвешле шәһәр казнасын баетырга ниятли. Бакчаны юкка чыгудан 1917 елгы революция коткарып кала. Эрмитаж кабат җанлана. Узган гасырның 20 нче, 30 нчы елларында ул Казанда бердәнбер ял бакчасы булып санала. Өлкән буын казанлылар мондагы павильоннарны, фил рәвешендәге су фонтанын да яхшы хәтерли әле.

Фотолар: ТР Милли музей фондыннан.



Тәүфикъ
КАМАЛИЕВ

Әгәр исән булса, аңа 75 яшь тулган булыр иде. Ул иртә китте – шигъри хисләр чишмәсе ачылып, иҗат ялкыны белән рухланып яши башлаганда – кырык яшендә бакыйга күчте. Узган сугыш канатларын каерган, әтисез, ятим үскән балачак йөрәкләрдә яра булып калган буын бу... Буа районы Ташкичү авылында туган, һөнәр училищесыннан соң заводта эшче, аннан матбугатта журналист булып эшләгән Тәүфикъ Камалиев ил-көн өчен борчылуларын, сагыну-сагышларын милләт гаме белән сугарылган шигъри юлларга салды. «Төпсез ялган диңгезендә / Хаклык утравын эзлим», / «Сабый җанлы сизгер ирләр булып / Без карыйбыз хәзер үткәнгә»... дип язган шагыйрь... Кеше китә – җыры кала дими, ни дисең?!

СОЛДАТ ДАНЫ – ИҢ ЗУР МИРАС

Яна бугай әле

Сугыш чыккан тәүге көнне үк
Алдым да мин яктым хатларың.
Үзебез генә белгән вәгъдәләрне
Таптавы бар җиде ятларның.

Үткәннәргә, артка күз салсам,
Искә төшә кабат ул чаклар.
Күрәм: һаман зәңгәр төтен чыга.
Яна бугай әле шул хатлар...

Мирас

Нишләсә дә солдат – солдат булыр,
Бер мылтык та шинель – байлыгы!
Котелогы белән эчә солдат,
Төбенә кадәр эчә кайгыны.

Аңлыйм, әти, җиңел булмаганын,
Ә җиңәргә кирәк, җиңәргә!
Аягүрә торган солдатлар сез,
Гранатаны яшереп җиңнәргә!

Ул яралар... сугыш яралары,
Җиңү яулап алган яралар.
Хәтерләмим генә сыкранганың,
Шунысы гына истә: «Балалар!..»

И кайгырдың, күңелең сизгән, ахры.
Ни калдырыйм, диеп, мин сезгә?
Соңгы сәфәр, ерак, чиксез сәфәр...
Мең тугыз йөз кырык сигездә.

Түздек, әти, бер кат күлмәк белән
Үткәрсәк тә карын, яңгырын,
Солдат даны иң зур мирас икән,
Син шундый зур мирас калдырдың!

Хәзер инде кемнән сорасаң да,
Илдә бәхет, хөрлек диярләр.
Кыңгыраулы атта син кайткандай,
Тик медальләр чыңлый, медальләр...

Сагыну сагышы

Без яшибез, әти, синнән башка,
Синең язмыш – солдат язмышы.
Язмыш гадел, туры дисәләр дә,
Ул бу юлы тагын ялгышты...
Истәлеккә иске шинелең дә,
Хатларың да килеп калмаган.
Дога итеп көн дә ятлар идек,
Шул шинельгә сыенып яңадан.
Әтиләр нурда коенган күк,
Яшь ага да ага нигәдер:
«Әти!» – дигәч,
шундый рәхәт икән,
Әйтеп карыйм сиңа мин дә бер...
Әти кирәк, әти булгачтын да.
Синнән безгә күчте яралар.
Яралардан җылы кулы белән
Үзеңнән соң кемнәр аралар?!
Без яшибез, әти, синнән башка,
Синең сүзгә сусап яшибез.
Кырык бердә туган балалар без...
Кырыкта да шуңа ятим без...

Хат

Агач көрәк арган кулларда,
Ир заты юк, бар да апайлар,
Иртә таңнан ашлык җилгәрәләр...
Ындыр буйлап чаба ак тайлар.

Шул тайлар күк, бергә ду килеп,
Без кызыллар булып уйныйбыз.
Безгә кызык, сугыш – уен безгә!
Кургаш солдат хәтле – буебыз.

Фронтлардан... туры ындырга
Килеп төшә солдат хатлары.
– Зәет, Зәет! Бүген хат бар сезгә!
Көнләшмәгән малай калмады.

Әнисенә сузды ул хатны:
– Укы тизрәк, әткәй ни язган?
Ә конвертта кара пичәт эзе...
Кайтавазлар кайтты: «И балам!..»

Төште кулдан агач кылычлар,
Малайлыктан чыкты малайлар.
Ындыр буйлап, берни булмагандай,
Тайлар гына чаба, ак тайлар...

* * *

Ят җирләрдә дуслар табу,
Белеп әйткән кемнәрдер,
Көн дә диңгез төпләреннән
Энҗе эзләү белән бер.

Ят җирләрдә дустан язу,
Белеп әйткән кемнәрдер,
Энҗеләрне суга ялгыш
Кире ташлау белән бер.

Укытучы, журналист, шагыйрә, язучы... Рафига Усманова турында сүз чыкса, әнә шулай тезеп китәләр. Аның Борай районы Бустанай авылы кызы икәнен дә искәртәләр. Нефтекамскида, Краснокама районында эшләгән елларын, «Кызыл таң»ның махсус хәбәрчесе чакларын искә төшерәләр. Һәм тагын иҗатына күчәләр... Шигырьләренә яз, көз, җәй, кышлар сыйган. Ихласлык, гадилек, авылча матурлык иңгән. Үз илендә – Башкортстанда аның инде үз укучысы бар. (Дистәгә якын китап авторы!) Бүген ул шигъри хисләрен, уй-фикерләрен Казан, Татарстан тарафларына юллый, бар татар дөньясына җиткерергә тели.



Рафига
УСМАНОВА

МОҢ-ШИГЫРЬ ЯРАЛГАН МӘЛ...

Авыл кызына

Тумыштан ук, Такташ Алсуыдай,
Шаян була авыл кызлары.
«Елмаям», – дип тора иреннәре,
«Оялам», – дип карый күзләре.

Судан кайта!
Аккош йөзәмени?
Күз тимәсен, исең китәрлек.
Бер тутырып сынап караулары
Бар дөньяны гашыйк итәрлек.

Уңган, сылу – авылым зиннәте ул,
Йөзек каштай балкый, күрәмсең?
Алардагы ялкын!
О егеткәй,
Якын килмә, пешеп үләрсең.

Тирә-юньне телсез калдырырлык
Сафлык бөркеп карый күзләре.
Керфек, кашлар,
нурлы толым чәчләр –
Табигатьтән бүләк үзләре.

Бу гүзәллек мине таң калдыра,
Горурлыгы бөек – илаһи.
Егет булсам әгәр, авыл кызы,
Гашыйк булыр идем, билләһи.

* * *

Дөнья булгач, шатлык-кайгысы бар –
Ни халәтне генә кичмисең.
Мин әнигә ак кәфенлек алдым,
Үзе кушкач, алмый нишлисең?

Әллә ничек кыен булып китте,
Күз яшемне сизә күрмәсен.
Салып куйдым сандык төпләренә
Әнкәемнең соңгы бирнәсен.

Күңелем мизгелләре

Күңелем яз сыман нечкә,
Йә моңсу көзләр кебек.
Җәйге чәчәктәй нур сөям,
Мин гашыйк кызлар кебек.

Яздай яшь буласы килә,
Җәйдәй гүзәллек хистә.
Уйчан көзмен...
Пакьлек көтәм
Ап-ак буранлы кыштан.

Күңелемнең мизгелләре
Табигатьнеке сыман.
Мин – хатын-кыз, йөрәгемә
Яз, кояш, җәй, кыш сыйган.

Кабатлана барчасы

Хуҗабикә,
Назлы хатын,
Нәнкә дә буласы бар.
Моңлы бишек җырын җырлар
Әнкәй дә буласы бар.

Коймагын да бар коясы,
Бәлешен саласы бар.
Диванда яткан ярымның
Көен дә табасы бар.

Бар керләрне уасы да,
Савыт-саба юасы.
Каз-үрдәкләрне ашатып,
Су буена куасы.

Эшкә барып көн буена
Тырышлык саласы бар.
Ир-егет тарталмас йөкне
Иңнәргә саласы бар.

Туган-тумача, дусларга
Булышып аласы бар.
Дәва булыйм, шифа булыйм –
Кемнәрнең ярасы бар?

Кибетенә чабасы бар.
Тузанны кагасы бар.
Дөньяның бар матурлыгын
Күңелгә ягасы бар.

Гүзәллекне хискә кушып,
Илһамга туласы бар.
Бөтен кеше йоклап беткәч,
Шагыйрә буласым бар.

Газиз әни...
Назлы хатын –
Кабатлана барчасы.
Эшләп табар акчасы,
Шигъриятем сакчысы
Һәм бәрәңге бакчасы...
Эх...



Фәнис ЯРУЛЛИН

ЧИГҮЛЕ КҮЛМӘК

(Хикәя)

Ишек кактылар. Җәүһәр барып ачты.

– Җәүһәр җаныем, үзең генәме? – дип сөйләнә-сөйләнә Илсөяр килеп керде.

– Үзем генә булмый, кем белән булыйм тагы? Дамир көндез эшли, мин төнлә. Өйдә безнең икәү чагыбыз бик сирәк.

– Шулай шул, җаныем. Эшлим дип, гомер буе ялгыз яшисез инде.

– Болай, ичмасам, сагынышып торабыз. Өч ел бергә гомер итеп «эһ» итешкәнебез дә юк.

– Синең хатын-кыз горурлыгың юк, Җәүһәр, – дип элеп алып китте Илсөяр. – Әзрәк горурлыгың булса Дамирыңа шулхәтле вуле бирмәсиең. Берүзе кинога йөри, берүзе...

– Йә, җитәр, Илсөяр, йөрсә соң. Гомер буе өйдә бикләнеп яшәмәс бит, – диде Җәүһәр ирен яклап. Кеше алдында якласа да, Дамирның соңгы вакытларда эштән соңарып кайтуына эче поша иде аның. Ә беркөнне өч көнлек туристик путевка белән каядыр Мәскәү ягына китеп баргач, бигрәк тә көяләнеп калды. Дөрес, ул чакта Дамир: «Минем Мәскәүдә бик зур йомышым бар, турист буларак кына бармыйм мин анда», – дип акланып маташты, ләкин үзе ни өчен баруын аңлатмады.

– Ә беләсеңме, Җәүһәр җаныем, – диде Илсөяр күршесенә, – мин сиңа начар хәбәр әйтергә кердем бит. Әйтмәм дип уйлаган идем дә, күрше хакы – Тәңре хакы дип, яшермәскә булдым.

– Нинди хәбәр ул, Илсөяр?

– Әйтергә телем дә бармый, җаныем. Беркөн синең Дамирың... Әй, калсын ла.

– Әйтә башлагач әйт.

– Шулай беркөн кибеткә керсәм, күзем шакмактай булды. Синең Дамирың бер хатынга күлмәк алып бирде. Чигүле күлмәк. «Таман булырмы, таман булырмы», – дигән сүзләрен үз колакларым белән ишеттем.

– Юкны сөйләмә, Илсөяр. Әллә кемнәргә күлмәк алып бирергә Дамирның акчасы кычытып тормыйдыр.

– Акчасы кычытамы-юкмы, анысын мин белмим. Әмма күлмәк сайлаганнарын үз күзләрем белән күрдем. Әгәр ялганласам, баскан урынымда тәгәрәп үлим менә.

Җәүһәр бу сүзләрдән исе китеп, ни уйларга белмичә, катып калды. Шикләнү корты гаҗәп үткен тешле бит ул. Чак кына йөрәгенә үтеп керергә ирек бирдең исә, ачыттырып-ачыттырып кимерергә тотына. Әһәмиятсез булып тоелган вак-төяк аңлашмаулар кинәт, һава өреп тутырган куыктай, кабара, үсә. Әмма Җәүһәр үзенең шикләнү кортына ирек бирмәде.

– Булмас, юкны бар итеп йөрмә, – диде дә, Илсөярне, куып чыгаргандай, чыгарып җибәрде. Ә үзе күңелендәге ямьсез уйларны куарга теләп, хатирәләр сандыгын, Дамирның армиядә чакта язган хатлары саклана торган сандыкны ачты.

Дамиры аның лирикага гаҗәп бай кеше. Хатларны искиткеч матур яза. Аның һәрбер хатын, самими сөюнең бер билгесе итеп, төзәтүсез-нисез матбугатка чыгарырлык. Дамирдан хат килгән көннәрне Җәүһәр мәхәббәт шәрабын коштабаклап эчкәндәй тилереп, шашып йөри иде. Армиядән кайтып өйләнешкәч, Дамирда ниндидер җылылык кимегән кебек сизде Җәүһәр. Чөнки егетнең мәхәббәт сүзләрен шулай матур итеп бары тик хатка гына яза алганын белми иде ул. Шул югала башлаган җылылыкны эзләгәндәй, ялгыз калып боеккан чакларда Җәүһәр шул хатларны актара. Шулардан ләззәт таба иде. Әмма бүген аңа хатлар укырга туры килмәде. Сандыкны ачып җибәрү белән ят бер хатын-кыз сумкасы аның күзенә ташланды. Ә сумка эченнән чигүле хатын-кыз күлмәге килеп чыкты. Өстенә түшәм җимерелеп төшсә дә, Җәүһәргә бу кадәр кыен булмаган булыр иде.

– Ни өчен бу әйберләр безнең сандыкка кергән? Әллә юкса... Әллә юкса теге Илсөяр әйткән хатын мин югында өйгә үк килеп йөриме? Ах, оятсызлар, ах, оятсызлар. Дамир мондый булыр дип кем уйлаган...

Җәүһәр ачудан сумканы алды да, шунда гына яткан балта белән тураклап та ташлады. Чигүле күлмәк һәм күн сумкадан бары тик кисәкләр генә калды. Бу шулхәтле тиз арада булды, хәтта шакылдаудан куркынган мәче дә кроватьтан сикереп төшәргә өлгермәде. Җәүһәр кулындагы балтаны һәм идәндә аунап ятучы кисәкләрне күргәч кенә айнып киткәндәй итте. Үзенең ни эшләгәнен төшенгәч, исе китеп идәнгә чүгәләде.

Ул еларга да, көләргә дә белмичә озак утырды. Әйтерсең, күлмәк түгел, аның йөрәген тураклаганнар да, шуның кисәкләре идәндә аунап ята. Әйтерсең, аның бөтен тәнен өзгәләгәннәр дә аяк астына ташлаганнар. Ләкин никадәр генә кыен булса да җиңәргә, бер карарга килергә кирәк. Әмма акыл бернәрсә турында да уйларга теләми. Бөтен мие таш кебек каткан.

Озак, бик озак утырганнан соң, Җәүһәр сумка һәм күлмәк калдыкларын җыеп кире сандыкка тутырды да диванга сузылып ятты. Бер генә кешене дә күрәсе, бер генә авыз сүз дә сөйләшәсе килми иде аның. Ләкин, үч иткәндәй, ире Дамир кайтып керде.

– Нәрсә булган минем төн сандугачыма? – дип сөйләнә башлады ул. Җәүһәр балалар бакчасында һәрвакыт төнлә генә эшләгәнлектән, Дамир аны «төн сандугачы» дип атый иде. – Нишләп вакытсыз кайттың дип тә сорамый, бик үпкәләткәннәр ахрысы моны. Ә мин артык горур кеше түгел, сорамасалар да, әйтәм: мин өч көнгә ял алдым. «Бәйрәмдә әнкәйләргә кайтып килик», – дип йөдәтә идең, менә кайтып килербез.


Җәүһәр һаман шулай берсүзсез ята бирде.

– Нәрсә әллә сиңа ял бирмиләрме? Бәйрәм көннәрне яслегез эшләми түгелме соң?

Җәүһәр җавап бирмәде. Дамир да аптырап калды. Юләр шикелле ялгызы сөйләнеп йөрүенә үзе үк оялып куйды. Өйдә ниндидер күңелсез тынлык урнашты. Бу хәлдән котылу өчен Дамир төрлечә кыланып карады: Җәүһәрнең табанын килеп кытыклады, маңгаена төшеп торган бөдрәләре буйлап мендәр мамыгы йөртте, тик берсе дә Җәүһәрне көлдерә алмады.

– Ә мин сиңа бер нәрсә алдым. 8 Март җитмичә бирмәм дигән идем, болай булгач бирим инде. Башкача сине юатып булмады. Мин аны беләсеңме ничек алдым? Буе-сыны белән нәкъ синең кебек кешене эзли-эзли җаным чыкты. Алгач-алгач, әйбернең таманы булсын, дидем. Бусы да күңелеңне күтәрмәсә, нишләргә дә белмим инде...


Дамир барып сандыкны ачты да телсез булып, шаккатып калды. Аның хатынына бүләккә дип алган чигүле күлмәге һәм Мәскәүләргә бара-бара алган күн сумкасы урынына эт теле хәтле кисәкләр генә аунап ята иде. Шунда гына Җәүһәр үзенең ни эшләгәнен белеп, ачынып елап җибәрде.



Рәсем: Наталья Васильева



2015 ел Россидә Әдәбият елы дип игълан ителде. Ил буенча матур чаралар уза башлады. «Әдәби Евразия» Халыкара Язучылар форумы, «Россиянең әдәби картасы», «Библиотөн-2015», «Китаплы җәй» проектлары, «Халыкара Китап көне» бәйрәмнәре... Хәтерләсәгез, 10 февраль – А. С. Пушкинны искә алу көне. 21 февральдә Халыкара туган тел көнен билгеләп үтәчәкбез. Татарстанда да үз әдәби бәйрәмнәребез бар безнең. 15 февральдә Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салырбыз, 14 февральдә бөек Каюм Насыйриның 190 еллыгын, Х. Хөснуллин, Ф. Яруллин юбилейларын билгеләп үтәрбез... «Сөембикә» ел дәвамында Әдәбият елы яңалыклары белән таныштырып торыр, язучыларыбызның яңа әсәрләре белән беррәттән, дөнья һәм рус классикасы үрнәкләрен дә биреп барырбыз. Бу санда хикәя остасы буларак танылган Америка язучысы О'Генри (1862–1910) хикәясен беркадәр кыскартып тәкъдим итәбез.


О'ГЕНРИ

ГАШЫЙКЛАР БҮЛӘГЕ

(Хикәя)

Бер доллар да сиксән җиде цент. Бар булган байлыгы – шушы. Акчаның алтмыш центы берәр центлыклар белән. Һәр цент өчен кибетче, яшелчәче, ит сатучы белән – аның кысмырлыгын өнәмичә, әмма дәшми-тынмый күзәтүчеләр алдында бит әле – колаклары кызарып чыкканчы сатулашырга туры килде аңа. Делла өч тапкыр санады акчасын. Бер доллар сиксән җиде цент. Иртәгәсен бәйрәм.

Чарасызлыктан иске кушеткага тәгәрәп, туйганчы бер еласаң гына инде. Делла шулай итте дә. Тормыш күз яшьләреннән, аһылдаулардан, елмаюлардан гыйбарәт бер нәрсә икән инде ул. Алай да аһылдаулар күбрәк.

Хатын яшәүнең шушы күчешләрен узгалаган арада ул яшәгән фатирга күз салыйк. Атнасына сигез доллар фатир хакы түләнә торган, вак-төяк җиһазлар гына куелган бүлмә бу. Бүлмәнең җиһазланышына, байлыктан бигрәк фәкыйрьлек төшенчәсе тәңгәл килә торган. Фатирга алып менә торган ишек янында, беренче катта, хатлар салу өчен тартма бар. Ул тартманың ярыгына иң юка хат та сыймас иде югыйсә. Ишек янәгына беркетелгән кыңгырауның төймәсенә басып та, ниндидер аваз яңгырату мөмкин хәл түгел. Шунда ук «М-р Джеймс Диллингхем Юнг» дигән язулы такта беркетелгән. «Диллингхем» дигән язу әлеге фамилия иясе атнасына утыз доллар керемле булган заманга лаеклы рәвештә киң, иркен итеп язылган. Хәзер керем егерме долларга калгач, «Диллингхем» сүзендәге хәрефләр тоныкланып, әллә тыйнак һәм дәгъвасыз «Д» хәрефенә генә калырга микән дигән сыман уйчан күренәләр иде. Әмма мистер Диллингхем өенә кайтып җитеп, икенче катка алып менә торган басмалардан күтәрелүгә аны һәр көнне: «Джим!» дип куанып эндәшү һәм миссис Джеймс Диллингхем Юнгның без сезгә Делла дип таныштырган хатынының назлы кочагы каршы ала иде. Бу кемнең дә күңелен күтәрә торган хәл бит инде.

Делла елавыннан туктап, каз мамыгы белән яңакларын сыпырып алды. Хәзер ул тәрәзәдән урамга карап, соры ишегалдының соры коймасы буйлап баручы соры мәчене күзәтә иде инде. Иртәгә Раштуа, ә хатынның кесәсендә нибары бер доллар да сиксән җиде цент кына акча бар. Менә шул акчага Джимга бүләк алырга кирәк! Ничә айлар тилмереп җыйган акчасы нибары шулкадәр генә. Атнага егерме доллар керем белән бик сикереп булмый шул. Чыгымнар хатын уйлаганнан күбрәк килеп чыкты. Чыгым шундый нәрсә инде ул. Джимына бүләк алырга ниба-

ры бер доллар да сиксән җиде генә цент акчасы бар! Аның Джимы бит ул! Раштуага иренә бирәчәк бүләк хакында хыялланып, никадәрле татлы минутлар кичерде ул. Ни дә булса сирәк, затлы, Джимны ярату кебек олы дәрәҗәгә аз гына булса да лаек булырдай бүләк инде ул.

Ике тәрәзә арасындагы диварда трюмо тора. Сезнең сигез долларлык фатирда торган трюмога бер дә караганыгыз юкмы? Бик тә арык, бик тә җитез кеше көзгенең тар канатларында чиратлап кайтарылган чагылышын күзәтеп, тышкы кыяфәте хакында беркадәр төгәл мәгълүмат туплый ала үзе. Юка гәүдәле Делла бу эштә шактый остарган иде.

Ул атылып тәрәзә яныннан көзге каршына килде. Күзләре кинәт нурланып китте, әмма мизгел эчендә йөзе качты. Җитез хәрәкәтләр белән ул башына өйгән чәчләрен ишеп төшерде. Әйтергә кирәк ки, Джеймс Диллингхем Юнглар гаиләсендә ике кадерле хәзинә булып, аның берсе Джимга ата-бабасыннан калган алтын сәгать, икенчесе – Делланың чәчләре. Әгәр дә мәгәр мәшһүр патшабикә Савская каршыдагы йортта яшәсә, Делла юган чәчләрен, һичшиксез, тәрәзә каршына килеп киптерер, шул рәвешле патшабикәнең бөтен затлы киемнәрен, зиннәтләрен күләгәләр иде. Әгәр дә мәгәр Сөләйман патша шул ук йортта ишек сакчысы – сагавыл булып хезмәт итсә һәм бөтен байлыкларын шул өйнең базында сакласа, Джим һәрвакыт узышлый гына кесә сәгатен чыгарыр да патшаның көнләшүдән сакалын йолкуын күреп үтәр иде.

Делланың елык-елык уйнап, коңгырт шарлавык булып таралган чәчләре, иңнәреннән тез астына кадәр агып төште дә, хатынның гәүдәсен төреп алды. Ләкин ул кинәт гасабиланып, каударланып чәчләрен кабат җыярга кереште. Аннары, икеләнгән сыман, беркавым хәрәкәтсез торды, күзләреннән идәндәге иске келәмгә ике тамчы күз яше тамып төште.

Хатын, иңнәренә көрән җиләнен элде, башына иске көрән эшләпәсен киде дә, итәкләрен дуылдатып, күзендәге кибеп өлгермәгән яшьләрен елтыратып, баскычтан түбәнгә, аннан урамга томырылды.

«Мадам Софрония. Чәчтән ясалган әйберләр» дигән язу эленгән ишек каршында бер мизгел тукталып торды әле ул. Аннары Делла, йөгерә-атлый, икенче катка омтылды. Сулышы кабып менеп җитүгә ул мадамнан: «Сез минем чәчемне сатып алмассызмы?» – дип сорады.

– Чәч сатып алам мин. Эшләпәңне сал әле, товарны күреп багыйк.

Янәдән көрән шарлама балкып агып китте.

– Егерме доллар, – диде мадам, күнегелгән хәрәкәтләр белән куе чәч ташкынын учында үлчәп.

– Бирегез тизрәк, – диде Делла.

Тагын ике сәгатьне Делла алсу канатларда очып үткәрде. Ул кибеттән кибеткә Джимга бүләк эзләп йөгерде.

Ниһаять, эзләгәнен тапты! Бу, бер шөбһәсез, Джим өчен, фәкать аның өчен ясалган әйбер иде. Бүтән бер кибеттә дә моның ише яхшы мал очрамаган иде әле. Делла бөтен кибетләрне гизеп чыкты лабаса. Яхшы мал агалтыннан ясалган сәгать чылбыры иде. Чылбыр зәвыклы, әмма гади бизәкле, чын заты белән күңелне яулап ала торган әйбер иде. Бөтен яхшы әйберләр шундый сыйфатка ия булырга тиеш тә. Бу чылбырны Джимның сәгатенә лаек дип әйтсәң дә ярый, ичмасам. Делла, чылбырны күреп алуга ук, аның Джимныкы булырга тиешлеген аңлап алды. Ул Джимның үзе кебек иде. Тыйнаклык һәм абруйлылык – менә шушы сыйфатлар хас аларның икесенә дә. Кассага егерме бер доллар түләргә кирәк булды. Калган сиксән җиде центын кесәсенә салып, Делла өенә ашыкты. Мондый чылбыры булгач, Джимга теләсә кемнәр янында, сәгатен чыгарып, вакытны белешеп алу һич тә оят булмас. Сәгате ничек кенә шәп булмасын, ул аңа кешегә күрсәтмичә генә карап алгалый иде, чөнки ул искереп беткән каеш бауда гына эленеп тора иде.

Өйгә кайткач, Делланың ашкынуы басыла төште, хәзер инде аны башка уйлар биләп алды. Ул газ утында чәч бөдрәләтә торган кыскыч кыздырып, мәхәббәт хакына кылынган каза эзләрен яшерергә кереште. Ә мондый эш, ышаныгыз миңа, һәрвакыт иң авыры.

Кырык минутлап вакыт узганнан соң, Делланың башы аны дәрестән качкан малайга охшатып калдырган вак-вак бөдрәләр белән капланды. Ул көзгедәге чагылышына бик озаклап, бик дикъкатьләп карап торды.

«Йә, – диде ул үз-үзенә, – әгәр Джим мине ишектән атлап керүгә үк бәреп үтермәсә, ул миңа: «Син Кони-Айлендтагы хорда җырлаучы бер хатынга охшап калгансың», – дип әйтер инде. Бар акчам бер доллар да сиксән җиде цент кына булгач, нишли ала идем соң мин?»

Сәгать җидегә кофе әзер булды. Газ плитәсендәге кызган таба да үзенә котлетлар тезгәнне көтеп тора.

Джим беркайчан да соңармый. Делла агалтын чылбырны учында кыскан килеш өстәлнең ишеккә якын торган ягына килеп утырды. Тиздән ул баскычтан менеп килүче адымнар ишетте. Агарынып китте. Аның теләсә нинди вак-төяк үтенечләр белән кыска-кыска догалар ярдәмендә Аллаһка ялвару гадәте бар иде. Ул ашыгып пышылдарга кереште:

– И Раббым, берүк аның күзенә мәхәббәтле күрендер.

Ишек ачылды. Джим кайтып кереп, ишекне япты. Аның арык чырае борчулы иде. Егерме ике яшендә гаилә башлыгы булу уен-муен түгел ул! Аңа инде күптәннән яңа бишмәт кирәк. Ялан куллары да һаман туңып йөри.

Джим, бүдәнә барын сизгән ау эте сыман, ишек янында катып калды. Аның күзләре Делла аңламаган бер караш белән хатынына текәлде. Делла коелып төште. Бу ачу да, гаҗәпләнү дә, кинә дә, курку да – булуы ихтимал хисләрнең берсе дә түгел иде. Ул фәкать хатынына текәлеп катып калган, ә карашы сәердән-сәер иде.

Делла сикереп торып, аңа килеп сарылды.

– Джим, сөеклем, карама миңа алай, – дип ачыргаланды ул. – Мин чәчемне кистердем дә саттым. Чөнки Раштуа белән котлап сиңа бирергә бүләгем булмаса, мин үләр идем. Чәч тагын үсә бит ул! Син мине ачуланмыйсың бит, әйеме? Бүтән чарам булмады.

Минем чәчем бик тиз үсә. Йә, мине Раштуа белән тәбриклә инде. Джим, әйдә бәйрәмгә шатланыйк. Минем сиңа нинди шәп бүләк алганымны белсәң!

– Син чәчеңне кистердеңмени? – дип сорады Джим, күпме генә тырышса да, бу хакыйкатьне аңлый алмаган кеше сыман.

– Әйе, кистердем дә саттым, – диде Делла. – Син бит мине барыбер яратасың? Чәчем кыска килеш тә мин шул ук Делла бит, әйеме?

Джим аптыраган кыяфәт белән бүлмәне күздән кичерде.

– Димәк, хәзер синең толымнарың юк инде? – диде ул тәмам гаҗизләнеп.

– Эзләп тә торма, таба алмассың, – диде Делла. – Әйттем бит инде, чәчемне саттым. Кистердем дә саттым! Мин моны синең хакка эшләдем. Минем белән назлырак булсаң да ярар иде. Башымдагы чәч бөртекләрен, бәлки, берәмтекләп санарга да мөмкиндер, тик белеп тор, – аның назлы тавышы кинәт җитдиләнеп китте. – Минем сине яратуымны бернинди мизаннарга салып та үлчәп булмас! Джим, котлетларны кыздыра башласам ярыйдыр бит?

Ниһаять, Джимга җан керде. Ул Делласын кысып кочаклап алды.

Без дә, әдәп белик, берара бүлмәне күзәткән булыйк. Атнага сигез доллар күбрәкме, әллә елына миллионмы? Математик яисә акыл иясе сезгә ялгыш җавап бирер. Булачак пәйгамбәрне котларга килгән тылсым ияләре дөнья бәясе бүләкләр төяп килгән булсалар да, алар арасында иң кыйммәтлесе булмаган, диләр. Хәер, күзгә төтен җибәрми торыйк әле. Тиздән барысы да аңлашылыр.

Джим, бишмәт кесәсеннән бер төргәк чыгарып, өстәлгә куйды.

– Делла, мине дөрес аңла, – диде ул. – Мин сине, кадерле кызчыгым, чәчсез дә яратам. Мине синнән биздерә алырлык чәчтараш юк. Тик син менә бу төргәкне сүткәч, минем нигә бер мизгелгә һушсыз калганымны төшенерсең.

Җитез ак куллар, бауны чишеп, төргәкне тиз генә сүтеп атты. Беренче мизгелдә сөенечле аһ авазы ишетелде дә икенче мизгелдә аны ике күздән аккан күз яшьләре ташкыны күмеп китте. Джимга хатынын юату өчен өйдәге бөтен тынычландыру чараларын эзләп кабаланырга туры килде.

Чөнки өстәл өстендә тараклар – бер зур, ике кечерәк тарак ята иде. Делла Бродвейдагы кибетләрнең витриналарында күреп йөргән, үлепләр кызыга торган тараклар иде болар. Гаҗәеп матур, ташбака кабыгыннан ясалган, асылташлар белән бизәлгән, аның көрән чәчләренә килешеп торырдай тараклар! Алар бик кыйбатлы иде. Делла таракның кыйбат торганын белә. Аларга карагандa чынга ашмас хыялдан үзәге өзелеп куя торган иде. Менә шул тараклар хәзер аныкы, тик менә таракны кадап куярга толымнары гына юк.

Шулай да ул тараклары күкрәгенә кысып, үзендә Джимга яшь аралаш елмаеп карарлык көч тапкач әйтте:

– Минем чәчем бик тиз үсә, Джим!

Шулчак ул мәче баласыдай җитез генә сикереп торды да кычкырып җибәрде:

– Ай Аллам!

Джим аның искиткеч бүләген күрмәде бит әле. Ул каударланып учындагы сәгать чылбырын иренә сузды. Затлы металл аның күзләреннән агылган шатлык нурында тонык кына ялтырый иде.

– Искиткеч бит, әйеме, Джим? Моңа юлыкканчы бөтен шәһәр кибетләрен урап чыктым. Хәзер вакытны белү өчен көненә йөз тапкыр сәгатеңә карый аласың. Бир әле сәгатеңне. Икесе бергә ничек күренә икән, карыйк әле!

Ләкин Джим, хатынын тыңлыйсы урынга кушеткага барып ятты. Ике кулын баш астына куйды да киң итеп елмаеп җибәрде.

– Делла, – диде ул. – Безнең икебезгә дә бүләкләребезне яшереп куярга туры килер. Торып торсыннар әле. Безнең өчен артык әйбәт алар. Сиңа тарак алу өчен сәгатемне саттым мин. Менә хәзер котлетларыңны кыздыра башласаң да ярый.

Асия ЮНЫСОВА тәрҗемәсе



Рәсем: Наталья Васильева

КҮП ОЧРАКТА КАЙДАДЫР БУЛГАН ХӘЛЛӘРНЕ ИШЕТЕП ТЕТРӘНӘБЕЗ, БЕР БЕЛМӘГӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ КЫЛГАН ГАМӘЛЛӘРЕ БЕЗНЕ ЙӘ СОКЛАНДЫРА, ЙӘ НӘФРӘТЛӘНДЕРӘ. ЮГЫЙСӘ ГЫЙБРӘТНЕ ЕРАКТАН ЭЗЛИСЕ ДӘ ЮК.

Асия ГАЛИУЛЛИНА

ГЫЙБРӘТЛӘР АЛАСЫ БАР

Джоджо Мойеснын «Синең белән очрашканга кадәр» дигән бәяны тетрәндерде әле мине. Мине генә дә түгел. Китапны кулдан-кулга йөртеп укыдык. Әсәрнең каһарманы Луи атлы сәламәтлеге кеше көнләшерлек егет гомеренең иң уңышлы, иң гайрәтле, киләчәккә ниятләрнең иң кыюларын корган бер чагында автомобиль һәлакәтенә юлыга. Үз гаебе белән дә түгел. Яңгырлы төндә мотоциклда җилдерүче берәү аны абайламый бәрдереп китә. Луиның кара көннәре әнә шул каһәр суккан төннән башлана.

Әсәрне укучы кеше һәр туган көнне Луи белән бергә «яши». Аның газапларын күңеле аша үткәрә, ахыр килеп, егетне соңгы юлга озата. Китапны төн чыкканчы укып бетереп, ябып куйдым да уйга калдым. Йә, ярый, бу Луи шулай яшәгән, дөресрәге көннәрен берәмтекләп санап, рөхсәт ителгән (эвтаназия турында сүз бара) үлем сәгатен көткән. Аны карау өчен ялланган кызыкай егеттә яшәү дәртен уяту өчен алты ай дәвамында башын ташка гына бәрми инде. Әмма... җиңелә. Дөнья белән элемтәдә яшәү өчен компьютеры, матди байлыгы, аның һәр ымына сизгер хезмәтчеләре, аның өчен үлеп торган ата-анасы исән һәм ...инде аны шул хәлендә дә үлеп ярата башлаган Катрина була торып үлемне сайлый. Имеш, бәдән саусызлыгы аңа сайлау мөмкинлеген калдырмый. Күп мәртәбәләр үз-үзенә кул салу омтылышыннан соң алты ай яшәп торырга ризалашуы да әнисе хакына гына.



Алты ай сыналу! Безнең Фәнис абый! Фәнис Яруллин 53 ел чыдады. Һәм ул бу гомерне чыдау дип түгел, ЯШӘҮ дип раслады. Үзен һәм хатыны Нурсөяне лаеклы яшәтү өчен акчаны үзе эшләп тапты. Аның мирасы булып татар мәдәниятендә киштә-киштә китаплары калды. Язу машинкасына тиенгәнче, компьютеры гына түгел, җайлы телефоны да юк заманада ике куш йодрык арасына каләм кыстырып язылган китаплар бит ул. Китаплар гынамы? Фәнис Яруллиннан ничә буын яшьләрне тәрбияләү өчен батырлык, чыдамлык үрнәге, ягъни олы гыйбрәт калды.

Луины Фәнис Яруллин белән чагыштырам да, тагын бер мәртәбә үзебезнең ваемсызлыкка хәйран калып куям. Аның яшәешен җиңеләйтү өчен ни эшләдек соң без? Фәнис абыйның һәр көнен мәгънәле итү мәшәкатен фидакарь Нурсөягә йөкләдек тә тынычландык. Нурсөя Фәнис абыйның каршы диварга эленгән көзгедә генә чагылган мохитен киңәйтү өчен, аны очкычларга күтәреп менгерә-төшерә, Урта Азия калаларына кадәр алып барды. Кологы сандугач җырын ишетсен өчен, сазлыклы урында кишәрлек алып, бакча булдырды. Фәнис абыйны шул бакчага йөртү өчен машина руленә тотынды. Бу икәүнең битарафлык чытырманын ера-ера ничекләр итеп яшәргә тырышуын һичьюгы ишетә белсә, теге Луи тормыштан алай тиз генә туймас иде. Үзен караучылар аны «онытып торган» һәр мизгелне Луи үлемне якынайта торган берәр әмәл эзләүгә сарыф итә. Ә бит гомереңне өзелүгә сәбәпләр, эзләмәсәң дә, табылып кына тора.

Шулай бер вакытны Фәнис Яруллин өйдә ялгыз гына калган чагында плитәдә янып калган уттан янгын чыга. Фәнис абый мең дә бер газап белән караватыннан тәгәрәп төшеп, ишек янына шуышып килә: ишек дөбердәтеп, дөньяга сөрән сала. Ә юлда авариягә тарулары? Әгәр яшәү дәртең булмаса, үл дә куй гына бит. Юк, Фәнис абый көрәшә. Башкаларны да бердәнбер гомер өчен көрәшергә кирәклегенә ышандыра. Исбатлый да. Нәтиҗә: татар дөньясында мәгърур исем калды. Ул безнең кавемнән! Ул минем авылдашым!

Февраль аенда Фәнис Яруллинның туган көне. Аңа 77 яшь тулган булыр иде.




Сагыш

***Мин сиңа йомшак таң җиле
юллаган идем,
чәчләреңнән иркәләр дип
уйлаган идем.***

***Мин сине сагынып бер җыр
чыгарган идем.
Җан дуслар яратып аны
тыңлаган иде.***

***Җыр сиңа ошар дип йөрдем,
ваемсыз булып.
...Ә ул сиңа барып җиткән
авыр сүз булып.***

***Хәзер җилләр дә юлламыйм,
чыгармыйм җыр да.
Теләсәң, үзең җанымны
кил дә бер тыңла.***


Равил
ФӘЙЗУЛЛИН

САГЫШЛАНУ

Узган гасырның 60–70 нче еллары татар җыр сәнгатенең алтын чорлары булгандыр. Чөнки ул җырларны югары дәрәҗәдәге профессионаллар – талантлы композиторлар, шагыйрьләр, җырчы-башкаручылар иҗат итте. Яңа җырларны үз вакытында радио-телевидение ишеттереп-күрсәтеп, халыкка даими җиткереп торды. Үз һөнәрләренең осталары иҗат иткәч, ул җырлар, көйләре һәм сүзләре ягыннан камил булып, һич кенә дә тел-теш тидерерлек булмыйлар иде. Өстәвенә, яңа язылган әсәрләр әдәбият-сәнгатьнең күренекле вәкилләреннән торган комиссия – худсовет «иләге» аша да үттеләр. Җырны иҗат итүчеләр үзләре дә гаҗәеп талантлы шәхесләр иде шул.

Кайберләрен генә искә алып үтәм: композиторлар Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Нәҗип Җиһанов, Александр Ключарев, Сара Садыйкова, Рөстәм Яхин, Алмаз Монасыйпов, Фасил Әхмәтов, Ренат Еникеев...; шагыйрьләр – Сибгат Хәким, Әхмәт Ерикәй, Нури Арсланов, Мостафа Ногман, Мәхмүт Хөсәен, Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов...; җырчылар – Мөнирә Булатова, Фәхри Насретдинов, Мәрьям Рахманкулова, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Венера Шәрипова, Эмиль Җәләлетдинов... Минем сүзләргә Җәүдәт ага Фәйзи язган «Сагыш» исемле җыр да әнә шул сагындырып искә төшә торган елларның бер ядкаре.

Җәүдәт ага белән мине шагыйрь Мәхмүт Хөсәен 60 нчы еллар ахырында таныштырды. «Менә бу яшь шагыйрь – Равил Фәйзуллин. Безнеңчә әйтсәк, Равил Фәйзи!» – ди. Җәүдәт ага дәртсенеп сорап куйды: «Кайсы яктан?» Сораша торгач, аның нәсел тамырлары – Чистайдан, минеке Балык Бистәсеннән икәнлеге ачыклангач, без фамилиядәшләр генә, бер шәҗәрә агачыннан түгеллегебезне аңладык. Шулай да, Җәүдәт ага мине юаткандай: «Безне Кама елгасы гына аерып тора икән! Бергә җыр язгач, дуслашу, туганлашу була инде!» – диде. Ә фамилия димәктән, мин чыннан да ул чакта «лин»не алып ташлап, шигырьләрем астына «Равил Фәйзи» дип куйыйм микән дип уйлаштыргалап йөри идем. Ә Фәйзиләр бездә берничә: Мирхәйдәр Фәйзи, Әхмәт Фәйзи, Җәүдәт Фәйзи... Әле тагын үзбәктә дә Рәхмәт Фәйзи дигән язучы бар. Һәммәсе күренекле кешеләр... Паспорттагыча Фәйзуллин булып калырга булдым. Күрәсең, Фәйзиле олы шәхесләр арасында «эреп» югалырмын дип тә шүрләгәнмендер...

Мин күп җырлар язган кеше түгел. Җыр өчен дип махсус текст язганым да юк. Мәҗбүри нәрсә түгел. Тукай, Такташ, Туфан, Җәлил сүзләренә язылган җырлар да берничә генә. Кешеләр азмыкүпме белә торган биш-алты җырым (соавтор буларак) бар шикелле. Әйтик, «Аккошлар» (Ф. Әхмәтов), «Мин сине ничек яраттым» (С. Садыйкова), «Тимим күңелемә» (Р. Яхин, Ф. Әхмәтов), «Менә без дә үсеп життек, әни» (Л. Хәйретдинова), «Иясез шатлык» (Ш. Шәрифуллин), «Ашкыну» (Ш. Тимербулатов), «Хәтер» (Р. Абдуллин)... Шул исәптән, «Сагыш» җыры. Кайчак берәр көйче яки шигырьче: «Минем ике йөзләп, өч йөзләп җырым бар!» – дигәч, аптырап калам. Халык күңелендә сакланырлык ул кадәр җыр бөтен уртак хәзинәбездә бар микән әле!

Кайчак шигырь (бу очракта җыр тексты) ничек туды, тарихы нидән гыйбарәт дип тә сораштыргалыйлар. Андый төпченүнең, бәлки, кирәге дә юктыр. Мин ул вакытта күңелдә йөргән хисләремне кәгазьгә төшердем, композитор аны нотага салып көй чыгарды. Фәкать шул. Сүзләрне дикъкать белән укысаң яки тыңласаң, барысы да аңлашыла шикелле. Мәңгелек мәхәббәт дөньясында, йөрәкләрне яралап, кемнәр арасына кемнәр генә кермәгән дә, яшьлек ялгышлары өчен кемнәр генә нинди генә үкенечле, сагышлы хисләр кичермәгән! Әмма ул шәхси-интим тойгыларның күңелең сандыгында саклануы хәерлерәк.

Җәүдәт ага минем ике шигыремә көй язды. Берсе – «Бу дөньяда» (ул сирәк яңгырый, аны күпләр белмиләрдер), икенчесе – әлеге «Сагыш». Монысы билгелерәк җыр. Аны беренче мәртәбә Флера Сөләйманова башкарды. Ул вакытта яшь җырчы саналган Флера туташ Җәүдәт агалар фатирында яши иде. Янәшәдә моңлы тавышлы җырчы булгач, композиторның яңа язылган кайбер җырларны аның аша сынап каравы табигый. 70 нче еллар башында бу җырны Таһир Якупов та җырлап йөрде. Соңрак башкаручылар күп булды: профессионал җырчылар да, үзешчәннәр дә... Заманында ул шактый популяр иде. Хәзер дә ара-тирә ишетергә туры килә. Үземә ошый ул җыр. Сүз белән көй бер-берсен тулыландыра шикелле. Ихласлык һәм самимилек тә бар кебек. Бу урында шуны да әйтеп үтәсе килә: Җәүдәт ага Сүзне бик нечкәләп тоя, Мәгънәнең табигый һәм төгәл яңгырашына ирешергә омтыла торган зат иде. Заманында үзе дә әдәби иҗат белән шөгыльләнгән, китаплар чыгарган кеше шул! Төгәллекнең никадәр мөһим икәнлеген ул, бәлки, университетта укып йөргәндә дә җанына сеңдергәндер. Белеме ягыннан ул юрист иде бит. Сүзгә бөртекчәнлеге әлеге «Сагыш» җырын язганда да яхшы сизелде. Текстның өченче строфасында «ә ул сиңа барып җиткән хаин сүз булып» дип язылган иде. Ул «хаин» сүзен «авыр» дигән сүзгә алыштыруымны сорады. Һәм ул хаклы иде.

«Сагыш» – олуг композитор, җәмәгать эшлеклесе, чын мәгънәсендә зыялы интеллигент Җәүдәт Фәйзинең соңгы җырларының берсе иде. Иң соңгысы түгел микән әле? Җәүдәт ага 1973 елны 63 яшендә Казанда вафат булды.

Хәзер яши торган фатирым элек Җәүдәт ага Фәйзи яшәгән йортның каршында урнашкан. Кайчандыр без бергә җырлар иҗат иткән бүлмә диварларына минем тәрәзәләр карап тора. Аралар бик якын, тәрәз ачып сөйләшерлек. Көнен ә әллә ничә мәртәбә күз салам мин ул якка. Еш кына, сагышланып, озаклап карап торам. Хәзер анда бүтән кешеләр яши. Замана бүтән, холыкзәвыклар бүтән, җырлар бүтән...

Кайчак, теләсәң-теләмәсәң дә, залларда, телевизор экраннарында, машина салоннарында, тагын әллә нинди урыннарда мәгънәсез, азгын яки әрсез «җыр»лар тыңларга туры килә. Аларны күп, бик күп «йолдызлар» җырлый. Күп очракта сүзләрен дә, көен дә үзләре яза һәм... үзләре башкара да. Шундый «универсаль талантлар» күбәйде хәзер. Шул «йолдызлар» астында мәгърур тау-кыя кебек кайбер затлар – чын талантлы кешеләр үз иҗатларының кирәксезлегенә кимсенеп гомер кичерергә мәҗбүрләр...

Әгәр Җәүдәт ага исән булып, берәр җыр чыгарсак, ул, мөгаен, «Әрнү» дигән исемдә булыр иде...

Иртәнге сәгать алты. Төнлә ипи пешерүчеләр яңа кайтып киткән, иртәнге смена әле килеп җитмәгән. «ГАЗель» машинасына ипине Ринат абый үзе төйи. Егерме лоток – арыш ипие, шуның кадәр үк – күмәч, батон – өч лоток... Һәр лотокта 14 ипи. Әйе, монысына ир-ат кулы кирәк... Рузалия апа Камалиеваның Кайбыч икмәк пешерү комбинатында ипи сата башлаганына алты ел. Яңгырмы, кармы, буранмы – ул гел юлда: авыллар ипи көтә. Күктәге фәрештәләр генә икмәк ашамый... Яңа елдан соң озын ялда булган, бүген эштә беренче көне. Ул юкта бәяләр күтәрелгән: күмәч – 3 сумга, арыш ипие – 1 сум 50 тиенгә.



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

АВЫЛЛАР ИПИ КӨТӘ





Кузгалабыз. Без бүген Газинур белән... ипи сатачакбыз. Дөресрәге, ипи алырга килүчеләрнең хәлен сорашмакчыбыз. Урамдагы ачы җилдән соң машина кабинасында җылы, рәхәт. Бүлдермичә генә Рузалия апаны тыңлыйм:

– Бушанчада кибет бөтенләй юк, Урсак урман хуҗалыгында да... Әмма безне анда иртәгә көтәләр, бүген – бүтән маршрут. Кышын көнгә 7-8 меңлек сатам. Әле халыкка пай җирләре өчен он бирделәр, ипине үзләре салалар. Май аеннан сату күбәя. Кыш чыгарга шәһәргә китүчеләр кайта, каникулга бала-чага, оныклар җыела...

Аларның һәрберсе минем өй телефонын белә. Нидер кирәк булса, шалтыратталар. Үсемлек мае, кер юу порошогы, ярма, консервалар, колбаса, балык сорыйлар. Сөт ризыклары. Алып барсаң, җиләк-җимешен дә алалар. Ир-атка тәмәке кирәк инде...

Кече Мәме

Ипи сатуны иң ерактагы торактан башлыйбыз. Районның чигеннән. Кече Мәме – Кайбыч районындагы бердәнбер чуаш авылы. 1773–1775 елларда рус отрядларыннан качкан чуашлар нигез салган аңа. «Бик тырыш халык яши Мәмедә. Күрерсең әле, капка төбе саен трактор. Терлек-туар күп асрыйлар», – дип сөйләп бара Рузалия апа. Без авылга җиткәндәрәк каршыбызга бер машина чыкты. «Бортасның сөт җыючысы Альберт абый. Инде китеп бара».

Тирә-юнь әле дөм караңгы. Авыл урамына кергәч, Ринат абый сигнал бирә башлады. Янәсе: «Без килдек!» Халыкны иртә таңнан яңгыраган бу тавыш сискәндерми бугай, күнеккәннәр. Шул арада чыгып та җиттеләр.

– Дүрт күмәч!

Таня Ворожейкина авыл советында эшли икән. «Гаилә зур безнең, – ди ул. – Өч балам бар. Олы кызым Казанда, институтта укый, бүген ул да кайтырга тиеш. Ипине китереп сатулары бик җайлы! Эш тирәсендә алсам, кайдан кадәр күтәреп кайтасы булыр иде. Ирем көлә, сезне бөтенләй иркәләп бетерделәр ди. Гафу, эшкә ашыгам...»

Рузалия апаның фонаре сүнгән: акча бирәсе булганда, Ринат абый кесә телефонының утын кабыза.

Биленә билбау буган әбинең кем икәнен сорамасам да беләм – Маня түтәй. Кулындагы фонареннан таныдым. Рузалия апа: «Маня ападан гел: «Веча шурамы?» – дип сорыйм. Ул һәрвакыт өч күмәч ала. Аның ире укытучы булган, үзе фермада сыер сауган. Балаларының бишесе дә читтә. Мин сатып бетергәнче фонаре белән яктыртып тора ул», – дип сөйләгән иде.

Алдагы тукталыштагы яңа танышларым укытучылар булып чыкты. «Мәктәптә инде утыз бер ел эшлим, – ди Татьяна Яковлевна Ворожейкина. – Мәктәбебез тугызъеллык, 53 укучыбыз бар. Күрше Бортаслар да безгә килә. Әйе, алар да чуашча белә. Нәрсәсе бар аның? Менә безне дә беркем татарчага өйрәтмәгән... Дәреслекләрне Чуашстаннан да җибәрәләр, Казан да бирә. «Сөембикә» таныш, мәктәптә алдырабыз».

Нина Федоровна Чернова, элеккеге укытучы: «Башлангыч классларда 18 бала хәзер. Дүрт класска нинди күп булсын? Мин укыта башлаган елларда балалар безгә Аккуҗадан, Берләш, Поляна, Мүшки, Бортас, Красный Бор, Малала авылларыннан килә иде. Параллель класслар әллә ничә булыр иде. Бетте бала-чага авылда. Улым ялга кайткач, өй каршында тау ясаган иде, шуучы юк...»

«Здравствуйте?» – дип эндәшәм дә, шунда ук татарчага күчәм: «Исәннәрмесез?» Монда һәркемнең өч телдә иркен сөйләшүен аңладым инде...

Сүзне шул урында өзеп, алар икесе дә өйләренә ашыга: салкын. Үзләре әйтмешли, «собрание ясап утырыр чак түгел». Безгә ярый, Рузалия апа әнә яланкул сата – бияләй кигән килеш сдача бирә алмыйсың. Кулларына күз иярми аның. «Калькулятор кулланганым юк, – ди. – Мондый суыкта эшләми дә әле ул. Ияләшкән инде, хәтердән генә саныйм».

Кече Мәмедә соңгы тукталыш.

Анна түти: «Йомшакны бирегез. Карт кеше йомшакны ярата», – дип, күп итеп батон ала. «Малаладан адашым Анна да сораган иде», – ди. Малала – Кече Мәмедән ике чакрым.



■ Ипигә чиратка басучылар белән танышам. «Югары Осланнан килен булып төшкән идем, – ди Роза Токсарова. – Гомер буе китапханәдә эшләдем. Журналыгызны гел алдырдык. Өйдә утырганым юк – «Палан» фольклор ансамбленә йөрим. Үзем кебек өлкәннәр җырлый анда. Клубыбыз бик әйбәт, костюмнарыбыз да бер дигән. Һәр йортка газ, су кергән. Яшьләр генә калмый... Унбишләп кеше Югары Ослан районының Коргуза авылына барып эшләп йөри».



Фото: Газинур Хафизов

Егерме генә йортлык ул авылда кибет юк.

Яктырып бетте диярлек. Без авылдан чыгабыз, «Дети» дип язылган автобус урамга таба борыла. Ринат абый: «Бортастан мәктәп укучыларын алып киләләр», – ди.

Сабыр итәргә өйрәнгән бугай инде алар...

Колаңгы

1943 елны салынган «Колаңгы» тимер юл станциясе урнашкан авыл бу. Станция дип... Вокзалның бинасына кадәр сүтелгән икән инде. Еракка йөрүче поездлар монда хәзер бөтенләй туктамый. Каядыр китәсе булса, халык йә Буага, йә «Свияжск» станциясенә бара. Колаңгыда ипине урамда сатмыйбыз, шәхси кибетләргә генә кертәбез.

«Казаньзернопродукт» кибетендә озаккарак тукталабыз. Сатучының казаннардан ипи кабул иткән вакытына туры килдек. Халыкның сыйфатка да, бәягә дә карап сайлап алу мөмкинлеге бар. Казан ипие – 25 сум, Кайбычта пешкән «Дарницкий» 18 сум 50 тиен тора. Кибетче Рузалия апа Хәйруллина үзебезнең кеше булып чыкты. Аның авызыннан: «Сөембикә» журналын «Азат хатын» чагыннан бирле алдырдым», – дигән сүз чыгуга, без күптәнге танышлар кебек сөйләшеп киттек. Редакция үткәргән аш-су рецептлары конкурсында катнашып, бүләк тә алганы булган икән.

– Ялга чыккач, бер көн эшләмәм дигән идем, ике ел була менә. 1977 елдан бирле сатам. Апас районы Коштаулы кызы мин. Техникум тәмамлагач, бу якка эшкә җибәргәннәр иде. Борындык егете Равилгә кияүгә чыгып, бөтенләйгә калдым.

Бер малай, бер кыз үстердек. Шөкер, икесе дә урнашты, башлыкүзле инде. Әни әйтмешли: «Җирләрендә җимеш кенә булсыннар». Кайтсыннар – китсеннәр. Ишетмибез, күрмибез – рәхәт. Биш онык бар. Әле каникулда кайтып киттеләр. Аларны озаткач, Равил белән газны сүндереп, ике көн кабызмадык – без җылыга иялэшмәгән. Ә алар, кайтып керүгә, туңабыз, диләр...

Борындык

Сәгать тугызынчы. Көн инде яктырып бетте. Үзәкне өзеп ачы җил дә исмәсә... Урамның кайсы төшенә кереп җиткәч кычкырта башлыйсы, кайда туктыйсы – Ринат абый Әхмәдуллинны өйрәтәсе юк: барысын да үзе белә. Ул, гомумән, гади шофер гына түгел, Рузалия апа әйтмешли «йөк төяүче дә, кассир да». Сатучыдан алда сикереп төшеп, ишекләрне ача, бушаган ипи әрҗәләрен арткарак алып куя, сатып алучылар беткәч, ишекне яба – кабинага иң соңыннан утыра.

Туктарга өлгермибез, капкалар берәм-берәм ачыла да башлады. «Ай-яй, Рузалия! Озак күренмәдең! Сагындырдың!» – барысының да телендә шул сүз. Ул арада әбиләр минем сорауларга да җавап бирергә өлгерәләр: «Бик җайлы! Тәрәзәдән генә карап торабыз килгәннәрен. Кибет тә алай ерак түгел, әмма салкында йөрисе килми».

Кешеләр ипи алган, Рузалия апаның хәл-әхвәлен белешкән арада Резеда апа Җиһангировадан язмышын сөйләтергә өлгерәм:

– Бабаем белән икәү яшибез, кызым. Балаларым... Өчәү иде, өчесе дә мәрхүмнәр. Икесе Әфганстанда хезмәт итте. Почта ящигын көнгә икешәр чыгып карый идем. Хатлары юкмы икән, дип. Көнгә ике тапкыр почта киләме соң инде? Шулай көтеп алдым. Гомерләре барыбер булмаган икән... Берсе кайтуга – 24 яшендә үлде, аннан – икенчесе... Соңгысын җирләгәнгә әле бер генә ел. Анысы авырды, өченче операциядән соң терелмәде инде. Өч онгыгыбыз бар. Кайтып йөриләр, Аллага шөкер. Телефоннан һәр көнне хәлне беләләр. Бабай да инсульттан соң бит әле. Өйдә әкрен генә таяк белән йөри үзе, өченче ел китте инде. И-и, мин күргәннәр!..

Ишеткәннәремне йөрәгем аша үткәргән арада икенче тукталышка килеп җитәбез. Без туктаган капка төбендә гел ир-атлар гына.

– Кайда карчыкларыгыз? Әллә аларга пенсияне ышанып тапшырмыйсызмы? – дим, уенын-чынын бергә кушып.

– Сеңлем, бу тирәләр шундый, – дип барысы өчен дә Даниял абый Хәсәнҗанов җавап бирә. – Сыер асраган чакларда хатыннардан көтү дә кудыртмадык. Үзебез сава идек тә, җыелышып алып китә идек. Кайсыбыз ялгыз инде хәзер. Икәү булганнарның карчыклары өйдә чәй куеп көтә...

Чираттагы тукталышыбыз Каратунның сөт җыючылары белән янәшә туры килде. Каршыдагы йорттан ике чиләк белән чыккан хатын, аларга сөтен тапшыргач, безнең янга



■ «Оныклар, – ди Тамара Майданова йортларының тәрәзәсенә ымлап. – Дүртәү. Игезәкләр быел көзгә укырга керә. Төпчегенә өченче яшь китте. Зурысы алтынчы класста укый, анысын әтисе киендерә, боларын пенсия акчасына – үзебез. Кызның һаман да эше юк...» Биш бала үстереп, берсен инде җир куенына салырга өлгергән ана бу сүзләрне артык зарланмыйча гына әйтә.

■ Рузалия апа: «Борындыкта бер урында ипигә гел ирләр генә чыга», – дигән иде. Димәк, шушы урам очы...



ипи алырга килде. Танышабыз. Гөлсинә Әхмәтҗанова икән.

– Дүрт сыерыбыз бар, – ди ул. – Өчесен савам, дүртенчесе әле бозауламаган. Кышын сөт аз инде, 15–20 литр гына чыгарам. Быелтыр җәй өч сыерга көн саен 40 литр тапшырдым. Хәзер литрын 17 сум 50 тиеннән алалар, җәйгә 14 кә төшә. Сөт акчасын безнекеләр унбиш көнгә бер бирә. Юк, җәен көтү көтеп тилмермибез, ике елдан бирле көтүче бар әле.

Үгез дә, кечкенә бозаулар да бар... Кош-кортыбыз күп. Ирем Камбәл кызыксына алар белән, кыр тавыгына кадәр үстерә. Әйе, иремнең исеме ятрак. Кайнанам яшь чакта Казакъстанда торган, шунда ишеткән булган... Өч кыз, бер ул үстердек, бөтенесе читтә. Бер оныклы да булдык инде...

Урамда озак та тормыйбыз шикелле, әмма шул ун-егерме минут эчендә дә эчкә салкын үрмәли. Җылынырга да өлгермибез, икенче тукталыш җитә. Рузалия апаның хәлен белүгә, Зәйтүнә апа Гарәфиева белән Тәнзилә апа Зарифуллиналар элек ипигә тилмергән чакларын искә төшерүгә күчтеләр. Авыл тимер юлдан ерак түгел бит. Борындык халкы «Казан–Куйбышев» поездына, вагон-ресторанга ипигә йөргән.

– Колаңгыда кичке җиделәрдә була иде ул. Поезд туктагач, тиз генә вагонга сикереп менәбез – халык Сабантуй кебек. Ипине ящик-ящик әзерләп куйган булалар. Акчаны бирәбез, капчыкка тутыра барабыз... Унсигез ипи булырга тиеш, тик икесен алып калалар иде. Башта капчыкны ыргытабыз, аннары үзебез сикерәбез. Ничек имгәнмәгәнбез? Искерсә, җылытып ашый идек инде...

Борындык авылындагы соңгы тукталыш. Ипигә өчәү генә чыктылар: Илсөяр, Сәкинә һәм Алсу апа. «Пенсияләр җитә, эшләгәндә дә аның кадәр акча алмадык. Яшьләргә читенрәк, – диләр. – Менә күршебез Зөлфия... Ике бала үстерә. Ире чыгып китеп югалды. Айга алты мең кредит түли. Пенсия ала торган әбисе дә үлеп китте. Ә колхозның ничә ай акча бирә алганы юк. Эше дә авыр бит Зөлфиянең. Йөздән артык яшь бозау карый ул. Өч көнлек килеш бирәләр аңа. Элек доярка кулында алты бозау булса, күп дия торган идек...» Соңгы җөмләне кырык ел сыер сауган Илсөяр апа әйтә.

Беляево

Бер генә урамлы урыс авылы. Ташландык нигезләр, сукмак төшмәгән капка төпләре шактый. Рузалия апа: «Җәен бик матур бу авылда, – ди. – Урамнары ямь-яшел чирәм аның, бакча артларында елга ага». Хәер, кышның үз матурлыгы анысы... Авылны икегә бүлеп тимер юл уза. Ипигә гел карт-карчыклар гына чыгуы аңлашыла шулай булгач: яшьләрне монда да кала йоткан – капка төбеннән поездга утырып китәргә мөмкин булганда, әлбәттә, киткәннәр... Әмма картадан Беляево авылы югалыр дип уйлыйсы килми әле. Колангы белән ике арада узган ел Президент программасы буенча күп функцияле үзәк салып куйдылар. Аннан алдарак кына мәктәп ачканнар иде. Янәшәләрендә – участковыйның яңа йорты. Моңарчы кыр булган җирдә төзи башлаган йортлар да байтак: арада кайчандыр шушы авылдан чыгып киткән егет-кызларның яңа нигезләре дә бардыр.

Без Катя түти Анисимованың капка төбенә туктаганбыз икән. Ул бер зур сумка ипи ала да минем белән сөйләшеп тора:

> *«Чират тормыйбыз, миңа калмый дип аптырамыйбыз. Кайбычлар пешергәне тәмлерәк шул...»*

– Килен шалтыратып, аларга да алырга кушкан иде, аның балалары кечкенә, машина килгәндә генә чыгып китә алмый. Мин Кайбыч ипиен генә яратам, гел аларныкын гына алам. Бездә кибет юк. Колаңгы ерак түгел анысы, әмма хәзер аякларыбыз йөрми бит инде – якын араны да җиңел генә уза алмыйсың. Аяк асты бүгенгедәй боз булганда, бигрәк тә. Бабаем белән икәү генә яшибез, ул өйдә генә инде. Урамга чыгып тарта да, тагын кереп китә... Мин үзем дә пенсиягә чыкканчы ипи пешерүче булып эшләдем. Колаңгыда да элек пекарня бар иде. Зарланмыйбыз, икәү булганда пенсияләр җитә әле. Өч көннән алтмыш сигезне тотырам менә. Балалар кунакка кайтыр дип көтәм инде. Бишәү алар минем. Наташам станциядә тора, кибеттә сата, бер улым, әйткәнемчә, монда, өчесе – Казанда. Ел да шулай җыелалар.



■ Кече Колаңгы тау битенә урнашкан. Ул ерактан бөтенләй кечкенә булып күренә – уч төбенә сыеп бетәр кебек. «Бу авылда кибет юк, – ди Рузалия апа. – Кешесе дә бик аз инде анда, ипигә дип бишәү-алтау гына чыга». Машина эзе бар – балаларны иртән мәктәпкә алып чыкканнар. Әмма шул арада юлга җәяүле буран салырга өлгергән. Ринат абый туктап кала. Киңәшләшкәч, алар бүген авылга кереп тормаска дип хәл итәләр – көрткә батып калсаң, нишләрсең?



■ Тамак тук безнең монда. Эчке киемнәргә кадәр бирәләр. Мунча бар, ун көнгә бер юындыралар. Пенсиям 11 мең минем, өч ел элек, сиксән тулгач артты. Шуның 3 меңнән артыгын үз кулыма тоттыралар.

Рузалия апаның юлда: «Татар авылларында күбрәк арыш ипие алалар, ә руслар – күмәч», – дип сөйләп килгәнен искә төшереп, читтән генә марҗа әбиләрне күзәтәм.

Сатучыга акча сузган һәрберсе: «Күмәч», – ди!

Федоровское

Сәгать ун тулып килә. Бу вакытта Рузалия апаны картлар йортында көтәләр. Юлда хәрәкәт күбәйде. «Альберт абыйлар әнә Подберезьедан кайтып килә инде, сөтне тапшырганнар», – ди юлдашларым. Иртән Кече Мәмегә кергәндә караңгыда очраган машинаны мин, әлбәттә, танырга өлгермим. Ә алар күз уңыннан берсе дә читтә калмый.

Рузалия апа: «Картлар йорты заявканы нигәдер күп биргән. Ипине бермә-бер артык сораганнар. Әллә яңа кешеләр шулай күп китерделәрме икән?» – дип аптыраган иде. Сәбәбен белдек. Юк, кешеләре артмаган, һаман шул егерме алты карт-карчык. Яңа елдан ипи нормасын арттырганнар икән. Башка ризыкка да норма арттымы икән соң?

Рузалия апалар авыл урамында ипи саткан арада, мин һава суларга чыккан Гариф абый Адиятов белән сөйләшәм.

– Мөрәледән мин, кызым. Бер кешем юк, гомерем буе үзем генә яшәдем. Картлар йортына килгәнгә өченче ел китте инде. Ияләштегезме дип, бәйләп куйган эт кебек инде... Урсак дигән авылда бер сеңлем бар, ул үзе дә гарип. Кызлары Казанда эшли, алар хәлемне белә. Бүлмәдә икәү торабыз. Чүтидән Харис исемле кеше белән. Ул үзенең телевизорын алып килгән, шуны карап ята. Минем дә өйдә телевизорлар икәү анысы. Яшьтиләрнең малайлары кергәләп йөри. Авылдашлар Гает бәйрәмнәрендә үземне дә алып кайтып кунак иттеләр. Авыл якын бит минем, гел кайтасы килә... Былтыр җәй агачлар арасыннан гына чыгып, үзем генә дә кайтып киттем әле шулай. Юлда машина туры килде. Әмма өйгә керергә өлгермәдем, артымнан килеп җиттеләр.



Альберт РӘХМӘТУЛЛИН, Кайбыч муниципаль районы башлыгы:

– Бер генә йорт тәрәзәсендә ут янса да, ул авыл яши дигән сүз... Андый кечкенә авыллар бездә тугызау. Кайсында ун йорт, кайсында биш. Җәен дүрт гаилә яшәп, кышка алты кешелек бер гаилә генә калучы авыл – Красный Бор да бар. Һәрберсе өчен йөрәк бик авырта, ярдәм итәсе килә. Әмма бөтенесе бездән дә тормый бит... Авыл хуҗалыгы министры Марат Готовичка рәхмәт, кибете, башка инфраструктурасы булмаган авылларыбыз бар дип (алар Татарстанда җиде йөзгә якын – *ред.)*, ул Президентка мөрәҗәгать итте һәм хөкүмәт районнарга йөз автокибет алырга ярдәм итте. Безнең районга шундый ике машина кайтачак. Аның суыткычына кадәр бар. Һәм алар теләсә нинди юлда да йөри ала торган машиналар. Әлеге тугыз авылны икегә бүлдек: районның бер ягына урнашканнарын – икмәк пешерү комбинаты, икенче ягындагысын – сельпо карый. Атнага өч тапкыр баруны таләп иткән идек инде. Халык канәгать шикелле. Бүген ул авылларда ут бар, иң мөһиме: барысына да газ кергән. Безнең бурыч, кыш көне аларны юлдан өзмәү. Һәр иртәне сүзебез шуннан башлана: кайсы авылда, нинди урамга юл юк, кайда юл ачарга кирәк. Икенчесе – ипи алып барып җиткерү.

Ул кечкенә авылларның һәрберсендә йөреп чыктым. Җәен аларда оҗмах инде... Күбесе рус авыллары һәм алар табигатьнең иң матур почмагына урнашкан. Малалада егермеләп гаилә яши. Яз көне су баса һәм авылга юл бөтенләй өзелә анда. Су агызмасын өчен дамбаны таштан салырга кирәк – быел шуны эшлибез дип торабыз.

Әйе, бу авылларда башлыча өлкән кешеләр яши. Район үзәгенә килеп җитү карт-карчыкларга авыр инде, димәк, табиблар алар янына үзләре барырга тиеш. Әгәр кеше, тормышына куркыныч янаганда ярдәмнең һичшиксез килеп җитәсен белсә, аның яшәве күпкә җиңелрәк була. Участок табиблары җәен һәр авылда булып чыктылар. Төнлә ике «ашыгыч ярдәм» машинасы кизү тора – авылларга юллар бар, чыгып китә алалар.

Бүген халыкны кабул итә торган көнем иде. Атна саен 25–30 кеше килә. Керә олы гына бер әби: «Улым, бераз акча булмасмы, капкам бетте, мунчам тузды, ишекләр ябылмый, тәрәзләр», – ди. Иң элек җайлап кына сорыйм: «Балаларыгыз бармы?» – дим. «Бар, барысы да урнашкан, читтә», – ди. «Биш бала җыелып төп йортның тәрәзәсен алыштыра алмыймы?» – дим. Ярдәм күрсәтәбез күрсәтүен, әмма хикмәт башкада бит... Статистика алып барабыз – татарлар мондый үтенеч белән килми. Кайбер авылларның бетә язу чигенә җитүе аларның үзләреннән дә тора.

Ә Кайбыч ипие, бигрәк тә арыш ипие, чынлап та, тәмле безнең. Читтән кайтучылар алып китә хәтта. Лизинг-грантка кертеп, икмәк пешерү комбинатына җиһазлар алып бирдек – хөкүмәт булышты. Элеккеге заман түгел: районда ипи пешмәсә дә, халык урамга чыкмый: казаннар килеп сата, Чуаштан карап кына тора, Каратуннар... Ә безгә үзебезнекен җайга салу кирәк.



Ләйсән САФИНА

Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультеты, татар журналистикасы бүлеге (2009).

Кияүдә.

Карьера:
«Идел» яшьләр үзәге директоры.

Кредо: «Кеше арбасына утырсаң да, үз җырыңны җырлап бар».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Сынауда сынатмыйбыз!

Марат белән кавышканыбызга бер ел. Гаилә өчен иң катлаулысы алдагы ике ел, диләр. Минем өчен яңа дөнья ачу елы булды бу. Җиңел түгел, әмма тырышабыз.
Ирем Тула өлкәсендә туып-үскән. Әтисе аны Казанга яшьләр слетына: «Килен алып кайт», – дип озаткан. Нәкъ ике атнадан ул яңадан әйләнеп килде, ә тагын биш айдан никах укыттык. Хатын ире ягына күчәргә тиеш, әлбәттә. «Китә алам, әмма ярты елдан кире Казанга әйләнеп кайтачакмын», – дигәч, ул үзе килде. Марат бүген өч университетта укыта, инде татарча сөйләшә башлады.


Барысы да үзебездән тора!

Кризис инде гаиләләргә үтеп керде дисәк тә була. Әмма башкалар белән чагыштырганда хәлләребез алай ук мөшкел түгел бугай. Чит төбәкләрдәге яшьләр белән еш аралашабыз бит. «Сезнең әле барысы да әйбәт! Сез Татарстанда яшисез!» – диләр алар. Ирем дә, Казанга күчеп килгәч: «Татарстанда эшләү рәвеше башка, монда барысы да бик тиз эшләнә», – диде. «Бездә ничек эшләргә икәнен өйрәтмиләр, алга бурыч кына куялар», – дидем мин аңа. Әйе, шулай тәрбиялиләр! Уңышның сере тырышлык аның.

Без дөньяга бәхетле булыр өчен киләбез



Мин китап укырга яратам. Хәтта аларның исемлеген язып барам. Күптән түгел кулыма Төркиядә яшәп иҗат итүче Элиф Шәфәкнең «Честь» дигән романы килеп эләкте. Игезәк кызлар язмышы турында ул. Аларның берсе кияүгә чыккач, ире белән Англиягә күченә, өч бала таба. Әмма ире гаиләсен ташлап чыгып китә. Һәм шул вакыт ялгыз хатынга бер ир күз сала... Яңа китап укыган саен, кабат инанам: кайда гына яшәсәк тә, нинди генә телдә сөйләшсәк тә безне бер үк нәрсә берләштерә: без, адәм балалары, җиргә бәхет, ярату өчен туабыз.

сөендерде



көендерде

сөендерде

көендерде

сөендерде


көендерде

Кайгы агач башларыннан йөрми...

Авыру балаларга ярдәм сораган игъланнар адым саен хәзер. Күнегеп тә киләбез бугай. Бу безгә кагылмас шикелле тоела, тик... Узган атнада иртүк әнием шалтырата: «Казанда дәваланучы бер балага кан кирәк». Самат минем туган шәһәремнән, Әлмәттән. Аңа 2 яшь. Диагнозы – яман шеш. Интернеттан әнисе белән элемтәгә кердем. Самат безнең тарих укытучысының оныгы булып чыкты! Һәм шул минуттан аларның хәсрәте минем хәсрәткә дә әйләнде...

Гаепләләр – күп, ә дөреслек бер генә...

Украинадагы вакыйгалар аркасында безнең халык хәзер ике лагерьга бүленде. Бу – үзе бер зур фаҗига. Күпләрне бер генә сорау борчый: кем хаклы, ә кем хаксыз? Без гаепләләрне эзләгән арада бүгенге көндә Луганскида, Донбасста яшь аналар, пуля яңгырларыннан качып, балалары белән подвалда утыралар. Суыкта, ач килеш... Бәлки, безгә ешрак гомумкешелек сыйфатлары турында уйларга кирәктер? Иртәгә кайсыбызны ни көткәнен беребез дә белми ләбаса.

Нигә соң бер-беребезне аңламыйбыз?!

Франциядә булган хәлләр, аннан соң мөселманнарга каршы башланган агрессия күпләрне борчыйдыр. Безнең яшьләр дә акцияләр үткәрә: Колшәриф мәчетендә җомгадан соң Пәйгамбәрне сурәтләгән карикатураларга ризасызлык белдерү максатыннан, «Мин пәйгамбәребезне яратам» дигән чара узды, күкрәктамгалар таратылды... Әйе, сүз иреге сатира жанрына урын куя. Әмма бу очрак максатчан рәвештә дини хисләрдән мыскыллап көлүгә юнәлтелгән провокация иде.



Фото интернеттан алынды

ЯЛГЫШЛАРЫМ – УРМАН...

Ләйсән КАМАЛИЕВА

ХӘРБИ КЕШЕГӘ КИЯҮГӘ ЧЫККАНДА НИ КӨТӘБЕЗ БЕЗ? ВАТАННЫ ДА, ҮЗ ЯЗМЫШЫҢНЫ ДА ЫШАНЫП ТАПШЫРЫРЛЫК ЧЫН ИР-ЕГЕТНЕҢ МӘХӘББӘТЕ ЫШЫГЫНДА НӘФИС ГӨЛ БУЛЫП ҮСЕП УТЫРАЧАГЫБЫЗНЫМЫ?

«Чын ир-егет» бит ул – аның сүзе нык, иңнәре чыдам, йөрәге тугры! Ул көчле, намуслы, гомерлеккә сайлап алган ярын ул, бар авырлыклардан аралап, кадерләп йөртә. Кулыңны аңа бир дә, күзеңне йомып, тормыш юлыннан курыкмыйча атла! Минем бу хыялга ихлас ышануым үз-үземне алдау гына булган икән бит...

Тормышыгызның ниндидер бер ялгыш сукмактан кереп киткәнен бөтен барлыгыгыз белән тоеп, чарасыз булып, нишләргә белмичә юл уртасында басып калганыгыз бармы сезнең? Һәм иң мөһиме – нәрсәнедер үзгәртергә көч тә, теләк тә, мөмкинлек тә юк килеш... Артка борылып карыйсың да, гаҗиз булып, аңларга азапланасың: кайда, кайсы тирәләрдә ялгыш җибәрдем соң? Әгәр бу халәт сезгә дә таныш икән, хәлемне күз алдына китерәсездер...

Парашюттан сикерәм! Башка вакыт булса икеләнер, уйлар идем әле, ә монда кинәт тәвәккәлләдем: ниндидер карарга килә алмыйм, сорауларыма җавап тапмыйм икән, бәлки, минем өчен барысын да күкләр хәл итәр?

Һәм менә ул көн килеп җитте... Курыктым, хәтта бик курыктым дип әйтү дә аз булыр... Әмма кире борылырга соң иде инде. Эчемдә нинди утлар янганын берәүгә дә сиздермичә, бик кыю күренергә тырышып, өстемә комбинезон, башыма шлем киеп, инструктор артыннан самолет трапына атладым. Нәрсә язса – шул булыр: сикерәм дигәч, сикерәм! Йөземә ясалма елмаю чыгарып, шашкан күз карашы белән упкынга таба атладым...

Юк, минем моңарчы болай беркайчан кычкырганым юк иде! Күкләрдә ачыргаланып яңгыраган кыргый бу тавышым тынлыкны бозып, җирнең дә тынычлыгын алгандыр. Менә шушылайлар итеп кычкыра аламдыр дип беркайчан уйлаганым булмады. Монысы – беренче ачышым иде.

Ниһаять, мин җирдә! Аяк-кулларым исән булуы, сулый, җиргә басып атлап китә алуым үзе үк миңа бу мизгелдә чиксез зур бәхет булып тоелды. Ачышының икенчесе – шушы иде.

Тирә-юньдә гаҗәеп бер тынлык иде бу минутта. Тансык тынлык. Әйтерсең, табигать тә минем уйларымны укый, әйтерсең, ул текәлеп күзләремә карап тора... Иң беренче тапкыр кайчан ялгышканымны кинәт шунда аңладым мин...

Өлкән сыйныфларда укыган елым иде ул. Мин тырышып тырышып дәресләргә әзерләнәм, бераз гына буш вакытым булса, спорт белән шөгыльләнәм. Ә дус кызларым барысы да диярлек инде беренче мәхәббәт утында яна, мин шәһәр буйлап яраткан велосипедымда җилдергәндә, алар күз төшкән егетләре белән очрашуга ашыга... «Ташла велосипедыңны, төш, безне оятка калдырма», – дип, мине ачуланырга да өлгерәләр. Төшүен төшәм дә, тик тагын чабып китәр өчен генә. Каядыр ашыккан кыяфәт ясыйм, тик үземнең бер кабаланыр җирем юк – миңа йөгерергә генә булсын. Тиздән кызлар мине үзләре белән чакырудан туктады, кул селтәделәр, әмма моңа минем әллә ни исем китмәде: волейбол белән мавыга башлаган чагым иде.

Юк, егетләр белән бөтенләй кызыксынмадым дип әйтә алмыйм. Мин дә үземчә хыяллана идем. Юлыма чыгачак ул егет үзе шаян, үзе эшчән, үзе бик игелекле булачак дип уйлый идем.

Беркөнне тренировкада кемдер миңа арттан туп белән бәрде. Шундый каты бәрде! Ачуым чыгып, артыма борылдым. Миңа карап елмаеп бер егет басып тора, кулында туп. Аның авыз еруы мине тагын да чыгырымнан чыгарды – үзе хакында нәрсә уйлаганымның бөтенесен әйттем дә салдым...

Без шулай таныштык. Ул миннән аз гына олырак иде, мәктәпне тәмамлагач хәрби училищега укырга керде. Шул көннән башлап мин... тоташ көтүгә әйләндем: хатларын, бик сирәк кенә булган шалтыратуларын көтәм. Каникулга кайтуларын. Бу вакытта дус кызларым кинога йөрде, кичке уеннарда күңел ачты, кемнәр белән генә танышмады алар... Ә мин һаман дүрт стена эчендә утырам! Минем шулай үз-үземне өйгә бикләп куюыма аптырам, әни берсендә ачыктан-ачык сөйләшергә ниятләде. «Кызым, синең бит аны кемдер белән чагыштырып карау мөмкинлегең дә булмаячак. Башкалар белән дә аралаш әле, кешеләрне танырга өйрән», – диде ул һәм кызлар белән бер кичәгә барырга тәкъдим итте. И-и үпкәләдем шулчак әнигә! «Син – минем иң якын кешем – ничек шундый сүзләр әйтә аласың?!» – дип еларга тотындым. Алга таба сөйләшүнең мәгънәсезлеген аңлап, әни миңа кул селтәде...

> *Яшел чирәмгә утырдым да үз-үземә сүз бирдем: моннан ары үз шәүләмне башкалар күзендә эзләүдән туктыйм!*

Дүрт ел шулай узды. Классташ кызлар ул арада бер-бер артлы кияүгә чыгып бетте дисәм дә була. Миннән башкалар...
Ә иремнең нигә нәкъ менә миңа тәкъдим ясаганын хәзер яхшы аңлыйм. (Башка вариантлары да булгандыр, булмый калмагандыр!) Укуын тәмамлагач, аны эшкә Себергә җибәрделәр. Очсыз-кырыйсыз тайга уртасы, элеккеге тоткыннар гаиләләре яшәгән кечкенә генә бистә... Үзе теләп мондый сөргенгә китәргә кем атлыгып торсын?! Ә мин, исәр, лотерея билеты откандай, сөендем!

Безнең бәхетле гаилә тормышы башланды. Дөресрәге, минеке. Бәхетемә бернәрсә дә күләгә төшерә алмады: иремнең өйдә сирәк булуы да (ул бит җаваплы эштә эшли!), әллә нигә бер булган елларын дуслары белән уздыруы да (аңа онытылып ял итү кирәк!)... Аннан улыбыз туды. Бала тудыру йортыннан канатланып кайттым. Иремнең кара коелып йөрүенә башта игътибар да итмәдем әле. Сабыем белән өйгә кайтуыбызның

дүртенче көнендә башлады ул бу сүзне: «Сәламәтлегем белән проблемалар бар. Һәм мин моңа син гаепле дип саныйм. Дөресен әйт, кем белән хыянәт иттең миңа?»

Теләсә кайсы хатын-кыз ире әйткән чирнең сәбәбе нидә булуын шунда ук аңлар иде... Тик мин түгел шул! Күз яшьләремне йотайота: «Кадерлем, син нәрсә инде! Мондый уй кайдан башыңа килде?» – дип аклана башладым. Иремнән аз гына булса да шикләндем дип уйласагыз, ялгышасыз. Юк! Кояшым бит ул минем!

Бу хәрби шәһәрчектә минекеннән дә азгын ир юклыгын шактый төшендереп аңлаттылар алар.

Әмма чирнең сәбәбе булырга тиеш иде бит! Уйлый торгач таптым мин аны! Мөгаен, бала тудыру йортында инструментлар стериль булмагандыр, шуңа бу хәл килеп чыккандыр. Әйе, шулайдыр! Икенче көнне иртүк табиб янына чаптым, шикләремне сөйләп бирдем. Гинекологның күзләрен күрсәгез икән!.. Шундый итеп карады, әйтерсең, мин чит планетадан килеп төшкәнмен... Тик ул акыллы хатын иде шул, саусәламәт икәнлегемә ышандырып, мине кабинетыннан җайлап кына озатты.

Шактый җайлы, гөнаһсыз сәбәп иде, нишләтәсең, барып чыкмады... Әмма өйгә канатланып очып кайтып кердем: иремне акларлык сәбәп барыбер тапкан идем. «Син бит мин бала табу йортында булганда дусларың белән саунага бардың. Мөгаен, шунда ияртkәнсеңдер», – дидем. Иремнең миңа чын күңелдән соклануы күренеп тора иде...

Тормышыбыз үз җае белән дәвам итте. Әмма нәкъ өч айдан соң, кичен эштән кайткач, гапгади нәрсә турында әйткәндәй, ирем кабат теге сүзләрне кабатлады һәм тагын шикләнеп миңа карады. «Син әле мине гаепләргә җөрьәт итәсеңме?! Оятың бармы синең?!» – минем урында башка берәү булса, шулай дөртләп кабынып иде. Тик мин түгел шул...

Баскан җиремнән сүзсез генә утырдым да, уйларымны эшкә җиктем – сәбәпне тагын эзләп таптым. Ирем өч ай элек тартуын ташлаган иде. Организмның моңа реакциясе шундый була аламы? Ала! Иремнең күз карашында җәлләү билгеләре чагылды кебек. Әллә миңа шулай тоелды гынамы? Әлбәттә, тоелган гынадыр.

Әмма җүләргә каласы көннәрем алда булган икән әле.

Берсендә офицер хатыннары очраклы гына мине кич утырырга чакырдылар. Хатын-кыз бергә җыелса нишләсен инде – ирләрен сүгә... Һәркайсы үзенекен сөйләде. Дәшмичә генә тыңлап утырырга да иде бит инде миңа... Юк, кысылырга кирәк бит, алар сөйләп бетергән саен: «И-и, кызлар, бигрәк җәллим сезне! Ә минем ирем менә андый түгел...» – диярґә... Эчемнән горурланып утырам бит әле – ирдән бер мин уңганмын! Гөнаһка керер хәлем юк, башта алар түзделәр, аннан соң гына: «Бик теләсәң, без синең күзеңне ачабыз!» – дип сөйләргә керештеләр...

Беренче никахым шулай төгәлләнде.

«Нигә болай булды соң?» – дип бик озак уйладым. Гаилә тормышым нилектән барып чыкмавының сәбәбен аңладым шикелле – чынбарлыкның күзенә туры карый алмыйм, үз алдыма максатлар куя белмим икән. Максат? Бу юлы төгәл билгеле ул: янымда мине өзелеп яраткан кеше булсын. Чын полковник! Һәм ул озак көттермәде...



БЕР

Айсылу НӘГЫЙМОВА,
психология фәннәре кандидаты,
социология фәннәре докторы.

Әлеге ханымның хатында шактый күңелсез хәлләр бәян ителсә дә, ул күңелдә якты эз калдыра, аның чиста күңеле, самимилеге сокландыра. Гомумән, ул бит ачу, рәнҗүдән кара коелып түгел, ә ниндидер моңсулык белән сөйли: шундый хәлләргә эләгеп тә күңел матурлыгын җуймавы куандырып куя.

Уйлап карыйк әле, ни өчен гаять дәрәҗәдә дөрес тәрбия алган кыз бала шундый сынауга дучар була соң? Ни сәбәпле аның күзләре шулкадәр озак вакытлар «сукыр» булып кала? Хәтта гаилә корып шактый яшәгәннән соң да, ул акны карадан аера алмый торган булып кала.

! Ә җавап бик гади – сәбәп аның инфантильлегендә.

Еш кына әти-әниләр баланы тәрбияләгәндә аны дөньяның борчумәшәкатеннән, ямьсез, килешсез якларыннан саклап үстерергә тырыша. «Үскәч тә күрергә өлгерер!» – янәсе. Бала тормышны берьяклы, идеаль итеп кабул итәргә өйрәнә: тирә-юньдәге кешеләр бар да яхшы: кызлар – дус, малайлар – тәртипле, ә конфликтлы очраклар килеп чыкканда аларга күз йомарга, күрмәмешкә салышырга яки, гомумән, читкә тайпылырга мөмкин! Хат авторы да дуслары читкә этәргәч, күңелен төшерми – аның яраткан спорты бар! Мәхәббәттә дә ул искиткеч эчкерсез: башка беркем белән очрашмый, танышмый, чиксез тугрылык белән сөйгәнен көтә!

ЯРДАН ИКЕНЧЕ ЯРГА

Монда иң аянычы шул, баласына дөрес тәрбия бирергә омтылган әти-әни аның бернинди әзерлексез, хәтта күзаллаусыз, яманы да яхшысы да тулып торган тормыш юлына басасын уйламаган... Дөрес, әни кеше берникадәр дәрәҗәдә тәрбия ялгышын төзәтергә омтылып караган – кызын башкалар белән дә очрашырга, кешеләрне чагыштырып карарга өндәгән. Ләкин инде шәхес формалашкан – әни кешенең сүзләре бушлыкка очкан...

! Гадәттә, мондый балалар искиткеч дәрәҗәдә эчкерсез, гадел булып үсә, аларга саранлык, үз ихтыяҗларын гына кайгырту хисе чит.

Хәтта әйтер идем – алар искиткеч дәрәҗәдә матур күңеллеләр – гүя тоташ бөллүрдән уеп ясалган! Яратса – онытылып ярата, ә инде дошманлашса – гафу итә белми торган шәхесләр. Юлларына үзләре шикелле үк яхшы күңелле кешеләр очраганда, алар бәхетле, матур гаилә корып, парларына алыштыргысыз дус, арка терәге булып яшәргә сәләтлеләр. Ә менә хыянәтне аңлый, кичерә белмиләр! Бәлки, шуңадыр да, ачыктан-ачык дәлилләр булуга да карамастан, безнең героинябыз иренең начар якларын «күрергә теләмәгән», чөнки гаиләсенең җимерелүе аның эчке дөньясының җимерелүенә, гомере буе формалашкан тормыш кыйммәтләренең юкка чыгуына китерер иде. «Күз ачылу»ның ахыры төрлечә бетәргә мөмкин: еш кына мондый шәхесләр шундый «ачышлардан» соң тирән кризиска эләгәләр, депрессиягә, хәтта үз-үзләренә кул салуга кадәр барып җитәләр. Бәхеткә каршы, бу очракта героинябызга чыгу юлы табыла – моңа аның спорт белән дуслыгы да берникадәр ярдәм иткәндер дип уйлыйм. Нәкъ менә көчле экстремаль кичерешләр, адреналин аңа үз тормышына икенче күзлектән карарга, ә бәлки күзен ачарга да булышкандыр!

! Шулай да мин аңа яңа максатлар белән берникадәр сабыр итәргә киңәш бирер идем.

Әле кичерешләр шактый яңа, аларны кат-кат уйлап, тагын йөрәк аша уздырасы бар. Үзеңне аңлыйсы, тормыштан ни теләгәнеңне ачыклыйсы... Бәлки, «чын полковник» – ул әле тормыш максаты түгелдер, ә хисләр уртак булганда гына кадерле бит. Бер ярдан икенче ярга ташлану кирәкме икән?!

Бу уңайдан әти-әниләргә берничә киңәш бирер идем. Бала ул – безгә тәрбия өчен вакытлыча ышанып тапшырылган җан. Аның үсеп, кеше буласы, катлаулы тормыш юлыннан ялгышмыйча, матур итеп атлап китәсе бар. Ә сезнең бурыч – аны менә шул җаваплы сәяхәткә мөмкин кадәр яхшы итеп әзерләү. Барасы юл турында берни белмәгән, анда ниләр очраячагын күз алдына да китермәгән юлчының юлны уңышлы узачагында шик бар... Бала чынбарлыктан ерак тормасын, тормышыгыздагы вакыйгалар, авырлыклар, проблемалар белән бүлешегез, аның белән киңәшләшеп яшәгез! Бу сезгә балагыз йөзендә яхшы дус, ышанычлы иптәш тәрбияләргә ярдәм итеп кенә калмас, ә бәлки аны киләчәккә әзерләүнең практик мәктәбе дә булып торыр.

Бөтенләе белән гаилә проблемаларына уралып, бары тик ире мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәгән ханымнарга да әйтер сүзем бар. Гаиләдә һәркем бәхетле булырга омтыла. Әмма гаиләдә хатын-кыз өчен иң мөһиме – җылы мөнәсәбәтләр, сөйгән яры белән аңлашып, яратышып яшәү. Шулай булса да, үзегез турында да онытмагыз әле. Шәхес буларак үз урынын тапкан, гаиләдә генә түгел, профессиональ өлкәдә дә уңышларга ирешкән, төрле юнәлешләрдә үсеп, үрләр яулаган хатын-кыз гына иренә дә, балаларына да һәрвакыт кызыклы булып кала.

! Ә инде читлеккә бикләнгәндәй өй, бала мәшәкатьләренә күмелеп, хәтта үз-үзен карарга да вакыты калмаган хатын-кыздан ир бик тиз туя, тиздән аның белән сөйләшер темалар да калмаган булып чыга.


Мондый әни үсеп килүче балалар өчен дә үрнәк булудан туктый, аңа өйдәге тормышны җайга салучы хезмәтчегә караган шикелле карый башлыйлар... Һичшиксез, зур дәрәҗәләргә ирешкән ирләр күп очракта гомерләрен гаиләгә багышлаган хатыннарына бурычлы. Тик әлеге ханымнар ирләренең коллары түгел, ә бәлки һәрнәрсәдән хәбәрдар дуслары, киңәшчеләре булып кала беләләр. Ә моның өчен хатын-кызга киң карашлы шәхес, белемле, кызыксынучан кеше булып калу зарур:

- Белем алырга омтылыгыз, китаплар укыгыз – чын мәгънәсендә укымышлы кеше генә партнеры өчен кызыклы.
- Тышкы кыяфәтегезне, сәламәтлегегезне һәрдаим кайгыртып торыгыз.
- Атнаның берничә сәгатен генә булса да үзегезгә багышлагыз, бу вакытны кызыклы итеп үткәрегез, дусларыгыз белән очрашыгыз, кинотеатрларга барыгыз.
- Спорт белән шөгыльләнегез, бу – сәламәтлекне ныгыту чарасы гына түгел, ә бәлки буй-сынны зифа саклау да, шул ук вакытта яхшы кәеф чыганагы да.
- Үзегезгә кием сайлаганда, бизәнгәндә белгеч киңәшенә колак салыгыз, кеше арасында гына түгел, өйдә дә килешле һәм матур киенеп йөрегез.
- Ә иң әһәмиятлесе – дөньяга позитив күзлектән карарга омтылыгыз!

16+

АКЫЛЛЫ ХАТЫН — ХӘЗИНӘ

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.



Марат КӘБИРОВ, язучы; өйләнгән; гаилә стажы — 25 ел; ике малай атасы.

1 **Иң элек син хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсең: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

Җавап бертөрле генә була алмый. Әйтик, урамда синең алдыңнан гына уйнаклап китеп барган гүзәлнең күзләренә берничек тә игътибар итеп булмый, шулай бит. Һәрберсенең үз өстенлеге инде, кем нәрсәсе белән җәлеп итә ала – шуны «уйната».

2 **Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?**

Хатын-кыз – кеше. Ә кеше камил зат түгел, аңа кирәгеннән артык зур өметләр багларга да, тулысынча ышанырга да ярамый. Аннан соң, начар сыйфат үзеннән-үзе генә булмый бит ул. Нәкъ кирәк чагында явызлык кайчагында изгелеккә тиң. Шуңа күрә монда бертөрле генә бәя була алмый. Барысы да конкрет вазгыятькә, вакытка, кешенең күңел халәтенә һәм тагын әллә нәрсәләргә бәйле. Ә гомумән алганда... Бу дөньяда аңлап булмаслык кеше, аклап булмаслык кабахәтлек юк бугай инде ул.

3 **Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идең?**

Алдан әйтә торган хәл түгел бу. Без якыннарга тизрәк тә, ныграк та рәнҗибез, аларны авыррак гафу итәбез. Кайчагында гафу итә дә алмыйбыз. Ә шул ук гамәлне чит-ятлар эшләсә, без аны бик җиңел гафу иткән булыр идек.

4 **Хатын-кызлар икегә бүленә: җыештыручылар һәм пешерүчеләргә. Сиңа аның кайсы якынрак?**

Белмим. Мондый бүленеш минем өчен көтелмәгән хәл. Безнең гаиләдә бер генә хатын-кыз, һәм ул барысы да – җыештыручы да, пешерүче дә, хуплаучы да, хурлаучы да...

5 **Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?**

Була ала. Хатын ул вакыты белән дус та, дошман да була ала. Бу мәсьәләдә аңа тиңнәр юк.

6 **Хатыныңа ничек тәкъдим ясаганыңны хәтерлисеңме?**

Бик романтик төстә булмады бугай ул. «Фәләненче числода сорарга киләм, өйдәгеләреңә әйтеп куй» – дидем шикелле. Аның янында шулай текә кылансам да, үзем бер-ике көн буена әнигә әйтергә кыенсынып йөрдем. Әйткәч, ул: «Баш кода булып җизнәң барыр инде. Сарык та юк бит әле, шулардан сорап торырмын», – дип, җизниләр авылына чыгып чапты. Мин дә сарык белән берәр яшник аракы сорарга, дип, колхоз председателенә киттем. Шулайрак башланды инде.

7 **Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр...**

Белмим, мин алай-болай уйланып тормадым инде. Күрдем, гашыйк булдым, өйләндем. Әни белән охшаш яклары да, капма-каршы яклары да бар бугай. Ә миңа икесе дә кадерле.

8 **Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар...**

Ир кеше бу очракта сөенергә тиештер инде. Әйтә алмыйм. Ир кеше мал табарга, гаиләсен карарга тиеш дигән караш өстенлек итә бит. Мин дә шул караштa. Ләкин хатын күбрәк таба, һәм бу ике якны да канәгатьләндерә икән – ни зыяны? Аннан соң, гаиләдә кемдер зуррак уңышка ирешә, югарырак баскычка күтәрелә икән, бу аның үз уңышы гына түгел бит инде. Гаиләндә иминлек, теләктәшлек булмаса, нинди дер уңышка ирешә алмыйсың. Аннан соң... Мал табу, матди байлык бер нәрсә

әле ул. Матди байлык белән беркемне дә рәнҗетмичә идарә итә алыр өчен рухи байлык та кирәк. Бу ир-атка да, хатын-кызга да кагыла.

Бай хатын яки ир эзләүчеләр дә күп хәзер. Шулай җиңел генә байлыкка хуҗа булам дип уйлыйдыр инде алар. Мин балаларыма андый язмыш теләмәс идем. Бу кәрт уены сыманрак нәрсә. Син байлыкка хуҗа буласыңмы, әллә байлык сиңа хуҗа буламы – белеп булмый әле.

9 Гашыйк булуын башлап хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсың?

Заманында бу мәсьәләнең психологик ягын беркадәр өйрәнергә туры килгән иде. Мин шулайрак аңладым. Гадәттә, ирләрне хатын-кыз сайлый. Беренче күргән ир-атка ул утыз секунд эчендә бәя бирә: бу адәм туачак баламның әтисе булырга лаекмы-юкмы. Һәм үзе гашыйк була алырлык кешенең игътибарын җәлеп итә. Бу бөтен сөтимәрләргә дә табигатьтән салынган нәрсә, аңасты дәрәҗәсендә башкарыла. Соңрак, аралашу нәтиҗәсендә, аны үз таләпләренә ярарлык дип таба икән, бу ир-егетне ул инде ычкындырмаска тырыша. Димәк... Мәхәббәтнең ачкычы хатын-кыз кулында. Ә инде яратуы турында иң беренче булып үзе әйтәме, әллә моны егетеннән әйттерәме – барысы да аның үзеннән тора.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?

Моны беркем дә белми, хәтта гүзәл затлар үзләре дә. «Шундый искиткеч кыз иде бит, минем нәрсәмә кызыкты икән бу?» – дип, гомер буе гаҗәпләндем инде. Хәзер үзе дә аптырый бугай...

11 Хатын-кызлардан үзең игътибар көтәсеңме?

Әсәрләремә игътибар итүләрен көтәм.

12 Ир-ат артык чибәр һәм көчле хатын-кыздан курка.

Табигатьтә «артык» дигән төшенчә юк. Әгәр ниндидер гүзәл артык чибәр, артык акыллы яки артык көчле булып тоела икән, бу бары тик ир-егетнең планкасы түбән булуын гына күрсәтә. Андый кеше, әлбәттә, «артык чибәр» ханымга якын килә алмый. Һәм ул үзенең буе җитәрлекне эзләп китә, теге гүзәлгә тиң булырлык ир-атлар өчен мәйданны бушата. Табигый сайланыш кануны.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзең аңламаган берәр очракны искә төшер әле.

Хәзер күз алдына китереп карыйбыз. Менә шундый күренеш. Чыгып сөт алып керергә кирәк булса, ир-ат чыга да алып керә. Ә хатын-кызның гамәлен җентеклерәк аңлатырга кирәк. Өй янындагы кибеттә сөт 35 сум тора, ә бер квартал арырак – 25 сум. Һәм хатын-кыз шул кибеткә китә. Мин моны аңлыйм, чөнки анда сөт ун сумга арзанрак. Тик ни өчен анда 20 сум түләп автобус белән барганы аңлашылмый. Бу ирләр өчен логикага сыймый торган хәл, шулай бит. Ләкин ул үзенчә хаклы. Ни өченме? Чөнки ул бер түгел, ә ике сөт ала. Өстәвенә, тагын биш-ун сумга арзанрак икәнен күреп, бер кило колбаса, ике кило бәрәңге, кәбестә, ярма, май, икмәк, шикәр, тагы әллә нәрсәләр тутыра һәм ике пакет күтәреп җәяү кайта.

14 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.

Логиканы ирләр уйлап тапкан, хатын-кызның зирәклеген яшерү өчен. Монда шартлы рәвештә шундыйрак параллель үткәрергә мөмкин: ирләр логикасы ул – конституция, хатын-кыз логикасы – тормыш кануны, язылмаган закон. Тормышның кануннарын берничек тә конституциягә кертеп бетереп булмый.

15 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныңның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишләргә?

Монда ике очрак булырга мөмкин. Әгәр хаклы икәнеңне сүздә генә исбатларга кирәк икән, юл куясың. Әйтеп карадың, булмады – нигә аны дәвам итәргә. Сантый түгел, үзе аңлар. Ә ниндидер эшкә кагыла икән... Монда инде аны тыңлыйсың да үзеңчә эшлисең. Ләкин аны тыңларга кирәк. Бу мөһим, чөнки хатын-кыз мәсьәләгә бөтенләй икенче төрле карый һәм кайчагында син дөрес дип санаган нәрсәнең астын-өскә китерерлек дәлил дә әйтеп куюы мөмкин. Шуңа күрә һәр сүзеңне җөпләп торучыга караганда, синең белән тиң бәхәскә керә алырлык хатын – хәзинә ул. Син аның кадерен белергә, ул үзенең урынын белергә тиеш.

16 Ир кеше ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатын, мин ардым дип, диванда кырын ятып тора...

Мин мондый нәрсәне күз алдына китерә алмыйм. Ул хәтта авырган чагында да ашарга әзерләп куя. Әгәр шундый хәлгә калсаң инде... Белмим... Нәрсә эшләп арыган бит әле... Шуңа карап йә үзең әзерлисең, йә кырын яткан хатыныңны чалкан яткырып куясың инде. Тик кафега чыгып китмәс идем, яратмыйм.

17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

Алай түгел ул. Хатын-кыз башта ирен әзерли. Баласын бакчага алып барган сыман. Шуннан үзе җыена башлый. Җитешә алмаса, ашык-пошык әзерләнә дә, өенә кайткан-чы теге җирем болай түгелме, бу җирем тегеләй түгелме дип куркып йөри.

18 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

Хатын-кызга шулай тоела гынадыр ул. Бер ир кеше дә нәрсә бүләк итте икән дип тикшеренеп утырмый инде. Ул үзенә кирәкле нәрсәне үзе ала, шулай бит. Ә сиңа кемдер бүләк бирә икән, бу – үзе үк зур нәрсә. Ярату, ихтирам билгесе.

ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ БОЗ ЧҮЛЕ, АЙСБЕРГЛАР, ПИНГВИННАР ИЛЕ, САКАЛЛЫ ПОЛЯРНИКЛАРНЫҢ ИКЕНЧЕ ВАТАНЫ. БУ – АНТАРКТИДА.

Җир шарының Көньяк ярымшарына урнашкан иң салкын урын. Котып диләр аны. Коточкыч җилләр, зәмһәрир суыклар, сүнгән вулканнар, вакыт исәбе югалган көннәр, поляр станцияләр...

АНТОН РАЙХШТАТ: «АНТАРКТИДАНЫ АЧТЫМ!»

Күптән түгел Рус география җәмгыятенең су астын тикшереп өйрәнү отряды, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы белән берлектә, «Антарктида-100» экспедициясен оештырган иде. Антарктиканың су системасын өйрәнү, кеше организмындагы үзгәрешләрне тикшерү, экстремаль хәлләрдә һәм агрессив тирәлектә кешенең психологик халәтен күзәтү, 80–100 метр тирәнлеккә су төбенә төшү кебек максатлар куеп (менә ни өчен бу проект «Антарктида-100» дип атала!), Казан дайверлары Антарктиданы өр-яңадан «ачып» кайтты. Экспедиция җитәкчесе Дмитрий Шиллер, Десепшн утравы янында 97 метр тирәнлеккә су астына чумып, дөнья рекорды куйды! Моңарчы әле анда 20 метрдан да тирәнгәрәк берәүнең дә төшкәне булмаган.

Боз кыйтгасын беренчеләрдән булып өйрәнгән рус диңгезчеләре Фаддей Беллинсгаузен һәм Михаил Лазаревлар эшен дәвам итеп, экспедиция тарихи белемнәрне киңәйтү миссиясенә дә алынган. Куелган максатларның барысын да үтәп, Казанга әйләнеп кайткач, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Антарктида-100» экспедициядә катнашучыларга дәүләт бүләкләре тапшырды: ике кешегә – «Фидакарь хезмәт өчен» медале, калган сигезенә – Татарстан Президентының Рәхмәте.

«Экспедицияләргә «Казан Кремле» озатып калу бездә матур йолага әйләнде, күп ачышлар музейларда башланып, шунда ук тәмамлана да. Хәзерге музейлар экспонатлар витринасы түгел, коммуникатив үзәк ул», – ди Казан дайверлары составында экспедициядә катнашкан журналист, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры урынбасары Антон Райхштат. Һәм фотолар, кызыклы хатирәләре аша Истанбулдан Аргентина башкаласы Буэнос-Айреска 17 сәгать ярым, аннары Ушуайяга – планетаның иң көньяк шәһәренә биш сәгатьтән артык очуларын (һавада гына да бер тәүлек!), океан төбенә чумуларын, дайверларның газ теориясен практикада өйрәнүләрен сөйләп (төрле тирәнлектә төрле газ катнашмалары сулыйлар, 90 метр тирәнлектә кислород агулый, озон исертә – бу организм өчен куркыныч), серле сәяхәт белән тагын да мавыктырып җибәрә. Ушуайя Утлы Җир утравына урнашкан, телгә дә «Җир чите» дип кереп киткән. Табигате дә шул исемгә туры килеп тора: сихерле торган кырыс таулар, искиткеч







матур Бигль бугазы. «Җир чите», әйтерсең, өр-яңа дөньяга – Антарктидага «капкаларын» ача... Ә пингвиннар махсус кара фрактан киенеп кунаклар каршылый сыман.

Шул сурәтне күз алдымнан югалтмыйча, Антонны сорауларга күмеп ташлыйм. Антарктидада шәһәрләр бармы? Ерак сәфәргә чыкканда үзе белән нинди талисман йөртә? Кайда торганнар? Ашарга кем әзерләгән? Антарктидага хатын-кызлар да барамы? Коточарлык кызык маҗараларга юлыкканнармы? Нинди ачышлар ясаганнар? Өйгә шалтырата алганнармы? Көньяк полюс суы бездәгедән аерыламы? Кайткач беренче эш итеп нәрсә эшлисегез килде?..

* * *

...Антарктидага тагын барыр идем. Бәлки әле бер генә дә түгел... Мыңа чын профессионаллар белән эшләргә туры килде – шуның белән горурланам. Командада бер мин генә дайвер түгел идем. Берничә ел элек команда җитәкчесе Дмитрий Шиллер «Полюс холода» проектында катнашырга чакырган иде. Якутиянең Оймякон районы янындагы Лабынкыр һәм Ворота күлләрендә дә күп тапкырлар чумып карап, 52 һәм 60 метрлы иң тирән нокталарны ачыклаган идек. Менә шуннан бирле без бергә. Экспедициядә без каты җиргә нибары ике генә мәртәбә баса алдык – Десепшн утравында һәм Беллинсгаузен поляр станциясендә. Табигать рәхимле булды дип әйтә алмыйм. Ушуайядан чыгып китеп континентка кире әйләнеп кайтканчы, без яхтада яшәдек. Тын океан белән Атлантик океан арасында бик хәвефле урын – Дрейк бугазы бар. Менә шуның аша узганда 16 метрлы җилкәнле көймәбез коточкыч чайкалып, безне як-якка ыргытты – яхтада йөрү түгел, гап-гади хәрәкәтләр ясау да кыенлашты. Анда гел штормнар булып тора икән! Таудай дулкыннар егып ташлардай итеп җилтерәтә, йолыккалый, яхта, әйтерсең, оча! Тизлек сәгатенә 9 диңгез миленә җитә! (1 диңгез миле 1852 метрга тигез – *авт.*) Юыну, теш чистарту ише юк кына эшләр дә үтәп булмастай тоела. Җилкән астында, авышлык үзгәргән саен, кисәк кенә әле бер, әле икенче якка янтаябыз. Берни эшләп булмый: йә килеп сыланасың, йә камбуз эчендә тәгәрәп йөрисең. Капитан исә Үрмәкүч кеше сыман: тигезлеген югалтмыйча, җай гына вазыйфаларын башкарып йөри. Голландияле Хэнк (шкиперның исеме шулай иде) яхтада җитез генә йөреп тора, җырлап та җибәрә, шторм вакытында нәрсәдер пешерде дә әле. Хәер, мин 4 көн буе азыкка карый да алмадым. Шулкадәр чайкалуга соң... Табигать безнең чыдамлыкны сынарга уйлады, ахрысы.

Антарктидада армия дә, хөкүмәт тә, дәүләт чикләре дә юк.

Билгеләнгән урынга килеп җиткәч, берничә көн тренировкалар уздырырга җыенган идек. Дүрт тәүлеккә сузылган авыр сәфәрдән соң дайверларга бераз ял да кирәк иде. Әмма табигать безгә әзерлек өчен нибары 8 сәгать вакыт калдырган булып чыкты. Бик көчле шторм якынлаша иде. Безнекеләр шундук тирәнлекне яуларга керештеләр. Бурычлар тагын да катлауланды. Аз гына ялгыш адым да һәлакәткә этәрәчәк. Максат – 100 метр тирәнлеккә төшү иде. Дайверлар Десепшн утравындагы диңгез култыгына чумдылар. Һәм 71 минут эчендә вулкан кратерының нәкъ 97 метр тирәнлектәге төбенә төртелеп, экстремаль рекорд куйдылар. Экспедициядән кайткач, Президент Рөстәм Миңнеханов безнең белән очрашканда, 100 метрга җиткерер өчен океан тө-







бен казырга иде тагын, дип шаярткан иде.

Антарктикада су төбенә төшә торган урынга барганда вахтада тордык – айсбергларга бәрелү хәвефеннән сакланырга кирәк иде. Гигант айсберглар куркыныч түгел әле, ерактан ук күренәләр. Ә менә өстәл, кер юу машинасы кадәр вакланганнарын котырынган океан эчендә абайламаска да мөмкин. Яхта 9 миль тизлек белән очканда килеп бәрелсәң – беттең! «Титаник» һәлакәткә очраганны, безнең 16 метрлы яхта йомычка кебек чәрдәкләнер иде! Беркайдан ярдәм өмет итеп булмый.

Дөньяда әле беркемнең беркайчан моңа ирешкәне – 97 метр тирәнлеккә төшкәне булмаган!

Кайтыр юлда табигать тагын көйсезләнә башлады: күз күреме 50 метр һәм аннан да азрак иде. Өчәрләп кизү тора башладык: икәү айсбергларны күзәтә, берәү – штурвал тота. Берсендә чак читкә тайпылып өлгердек – бозга бәрелергә метр ярым ара калган иде... Хәтерләмим, әллә дүрт, әллә биш көн кайттык. Чөнки анда төннәр юк, төнлә дә көндез сыман – яп-якты. Шуңа исәпне дә югалттык. Сәгать пояслары булмаган бердәнбер кыйтга ул, 24 сәгать поясын берничә секундта узарга мөмкин. Барыбыз да арыган, талчыккан... Җитмәсә, туктаусыз чайкалып бару аңны да томалый: һичнәрсә эшлисе килми. Элекке заман диңгезчеләре ничек түзгәндер?!

Су... бик салкын Антарктидада. Бездә минус 3 градуста су ката, ә анда – тагын да түбәнрәк температура кирәк. Яхта бортыннан егылсагыз, коткарып та маташмыйбыз дип, капитан алдан ук кисәтеп куйды. Чөнки су температурасы суда үткәргән вакытка туры пропорциядә икән. Су температурасы плюс 10 градус булганда, суда 10 минут тора аласың, 1 градуска төшсә – 1 минут... Тау кадәр дулкыннар арасында югаласыңны көт тә тор!

Мине океанның төсе таң калдырды! Бер градус салкында ул, нииндидер гомеремдә күргәнем булмаган караңгы шәмәхә төскә кереп, шомландырды, сагайтты. Тирә-якта чиксез шәмәхәлек, күз карашы тукталыр һични күренмәгәч, мөшкел бер халәттә каласың. Кызык та, куркыныч та.

Азык-төлекне үзебез белән алган идек. Яшелчә, җиләк-җимеш... Полярникларга да алып бардык. Суны Ушуайяда алдык. Советлар Союзында су асты көймәләрендә шундый норматив булган: шәхси гигиена ихтыяҗлары өчен һәркемгә көнгә ярты литр су каралган. Ә бездә менә аннан да азрак туры килә иде. Их, мин әйтәм, кайту белән мунчага йөгерер, рәхәтләнеп, чәчрәтә-чәчрәтә кайнар су белән юыныр идем, дим... Юк, иң элек каты җиргә басып йөрисе килә әле! Ирина (хатыны – *авт.)* пешергән ашларны ашыйсы, өйдәгеләр белән рәхәтләнеп аралашасы килә... Цивилизация җитми. Әле бит монда элемтәләр дә чикләнгән! Беллинсгаузен поляр станциясендә юри генә телефонымны кабызган булдым. Кем белә, бәлки... Шунда нииндидер фаза станциясе роуминг аша МТС элемтәсенә китереп чыгармасынмы! Могҗиза димә инде! Яхтада вакыт-вакыт 10 килобайтлык кыска электрон хәбәрләр җибәрерлек «тәрәзә» ачылып куя анысы. «Безнең хәлләр яхшы» дигән сүзләр китә өйгә. Мин инде җавап язып тормагыз, шактый акчалар чыгачак дип хәбәр салдым. Сувенир итеп алып кайтырга төрле ташлар җыйдым.







Фото: Антон Райхштат

Антарктидадагы сүнгән вулканнар «бүләге» алар. Су дигәннән... Бер кызык вакыйга. Ушуайяда отельгә урнашкач, душка кем беренче керә дип бәхәсләшә башлый безнекеләр. Мин оператор белән бер номерга туры килгән идем. Син беренче кер, минем фото, видеоларны яздырасым бар, дим. Аларның инде эше беткән, минеке башлана гына әле. Журналистларның шул инде... Поляр станциядә дә су запасын кайгырттык. Ә бер көнне, селкетүләр тынгач, Андрей Филиппов шундый тәмле кәбестә ашы пешерде! Моңарчы яхтада капитан гел үзе әзерли иде бит. Ул инде суны әрәм-шәрәм итмәс өчен үзе тотынгандыр. Басып та тора алмаган килеш бөтен суны түгеп бетерсәң!..

Россия поляр станцияләрендә хатын-кызлар юк иде. Бәлки, Чилиныкында булгандыр, башкаларныкында... Иң зур Мак-Мёрдо Америка поляр станциясендә фән белән шөгыльләнүче хатын-кызлар яши. Безнең арада хатын-кызлар булмады. Ә менә Буэнос-Айреска әйләнеп кайткач, декабрьдә кыска итәк, шортыдан йөргән кызларны күрү бик сәер тоелды. Анда 35 градуслы эссе, астрономик җәй башланган иде...

Поляр станция, полярникларның тормышы хәтергә уелып калган. Антарктидада беренче тапкыр азан яңгырау. Полярникларга изге Коръәнне, изге Мәрьям ана иконасын, Тәүратны бүләк итеп калдыруларыбыз... Төрле дин, конфессия, этнос кешеләре берсен-берсе баета гына икән – шуңа инандык. Аллаһы Тәгалә бер-беребезне ныграк өйрәнсен өчен шулай төрле итеп яраткан.

Тагын, беләсезме, нәрсә истә калган? Ватандашлар белән горурлану! Беренче рус антарктик экспедициясендә катнашып, Антарктиданы ачкан астроном Иван Симонов, Лобачевскийдан соң, Казан университетының икенче ректоры була! Кызганыч, күпләр белми шуны. Ә аның исеме шәһәребез бренды булырлык! Безнең проект аның 220 еллык юбилеена да багышланган иде...

Пингвиннарны бигрәк яраттык! Сөйкемлеләр! Тюленьнар, диңгез леопардлары – алары дайверлар өчен куркыныч, китлар, касаткалар, кошлар көтүе... Ак аюлар турында да сорый башласалар, бала-чага мәзәген искә төшерәм. «Ни өчен ак аюлар пингвиннарга һөҗүм итми? Чөнки берсе – Төньяк, икенчесе Көньяк полюста яши». Кар шулкадәр чиста, тирәнгәрәк төшкән саен, ул зәңгәрләнә бара. Бу кырыс континент беркем тарафыннан да буйсындырылмаган. Аның үз аурасы, үз кануннары! Антарктидага кабат барасы, аны яңадан ачасы да ачасы гына килеп тора. Ә беренче бару күз ачып йомганчы гына булды кебек...

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы «Антарктида-100» экспедициясенә старт бирде.

«Кайчандыр урамнан табып алган идем, аннан соң югалттым. Уйламаган-көтмәгән җирдә – аэропортта тагын таптым. Гел үзем белән йөри...» – дип, Антон, кесә телефонын ачып, сим-карта янында «яткан» кечкенә генә иконаны алып күрсәтә. Команданың аерылгысыз юлдашы булып җир читләрен урап кайткан, автографлары тозлы диңгез суында юылып беткән «Казан Кремле» флагын өстәлгә җәеп сала. Сәяхәтчеләргә көч, илһам биргән, ерак сәфәрләргә җилкендергән талисманнар да сихри көчкә ия, ахрысы...

Эльмира ЗАКИРОВА



Без, хатын-кызлар, шундый инде: алка, йөзек, муенсаларга битараф карый алмыйбыз. Зөлфия СӘЛИМҖАНОВАның үз куллары белән тудырган сәнгать әсәренә тиң бу бизәнгечләрен күреп тә «аh!» иттек. Җаның нindиен теләсә, шундыен ясый ул. Гаҗәпләнәсе юк, бабасы да көмешче булган аның. Зөлфия үзе Чирмешәндә туып, Бөгелмәдә буй җиткергән. Белеме буенча — укытучы. 17 ел мәктәптә эшләп, яраткан эшен калдырырга мәҗбүр булса да, кул кушырып утыручылардан түгел ул. Төп эшеннән бушаган арада, шушысына — җанына шифа биргәненә керешә. Алар өч дус — Юлия, Людмила һәм Зөлфия бергәләп эшли, төрле күргәзмәләрдә дә катнаша икән. Бүгенге мастер-классыбызда Зөлфия безне муенсага тагу өчен кулон ясарга өйрәтә.



АЛТЫН-КӨМЕШ КЕНӘ ДИМӘГӘН...

Кирәк:

• асты яссы таш (кабашон), ул булмаса, матур яссы сәдәф, хәтта бака кабырчыгы да ярый;
• 10 нчы номерлы 20 г сәйлән. Сәйләннең төсе таш төсенә ярашлы яки киресенчә, капма-каршы булырга мөмкин;
• 12 нче номерлы сәйлән энәләре (нәзек һәм озын);
• үтә күренмәле бик нык кыл;
• фетр яки берничә кат флизелин;
• күн кисәге;
• үтә күренмәле җилем;
• муен чылбыры.

Киңәш:

сәйлән сайлаганда кытайныкын алмаска тырышыгыз. Без чех сәйләне алдык. Чех сәйләннәренең төрлесе төрле зурлыкта булуы бу очракта кулай гына.





Эш барышы:

■ Ташны яссы ягы белән фетрга ябыштырабыз. Фетр таштан шактый чыгып калсын. Энәгә бер терсәк әйләнәсеннән аз гына мул кыл саплап, очын төенлибез. Сәйләннәрне караңгы төстәге (сәйләннәр үзләре караңгы төстә булса, ачык төстәге) тукыма өстенә таратып салабыз. Болай аларны араларга һәм энәгә эләктерергә уңай.

■ Энәне фетрның уң ягына чыгарып, ике сәйлән эләктерәбез. Энәне ташка терәп үк, сул якка чыгарабыз. Уң якка исә ике сәйлән уртасыннан чыгарып, икенче сәйләннең эченнән уздырабыз. Бу – беренче атлам булды. Икенчесе дә шулай ук башкарыла. Сәйләннәр барысы да бер үк зурлыкта булып, бер-берсенә терәлеп торсыннар. Ташны уратып алган сәйләннәр җөп санда булырга тиеш.







■ Икенче рәтне башлаганда энәгә өч сәйлән эләктерәбез. Аларның икесе зуррак, уртадагысы кечерәк булсын. Энәне җеп чыккан сәйләннең икенче ягыннан тыгып, рәттән өч сәйлән аша уздырабыз. Икенче атламда энәгә ике генә сәйлән (беренчесе кечерәк, икенчесе зуррак) эләктерәбез. Энәне бая гына тезгән теге өч сәйләннең иң кырыйда торган зуррагы аша тыгып, беренче рәттәге ике сәйлән аша уздырабыз. Сәйлән тезү схемасын рәсемнән карый аласыз. Рәтне энәгә бер кечкенә генә сәйлән эләктереп төгәллибез.

■ Сәйлән тезгән җепләрне эләктерми генә, таш тирәли фетрны кисәбез. Хәзер шуны күн кисәгенә ябыштырып, җилемнең кипкәнен көтәбез. Җилем кипкәч, күнне дә таш тирәли тигезләп кисәбез. Ташның аскы итәге буйлап сәйлән тезеп чыгабыз. Әлеге аскы рәт күн белән фетр читен капларга тиеш. Рәтне башлаганчы бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: бу рәтне төгәлләгән урынга элмәк ясаячакбыз, шуңа күрә рәтне башлаганда карагыз – элмәк кайда булса, отышлы.

■ Элмәкне 2 сәйлән өстенә ясарбыз. Иң элек энәгә сәйләннәр тезәбез. Аларның саны чылбырның калынлыгына бәйле. Чылбырны элмәккә кидерергә кирәк булачак бит. Энәне кабаттан җеп чыккан сәйлән аша уздырып, янәшә торганына кертәбез. Янә энәгә сәйләннәр тезеп, алдагы гамәлләрне башкарабыз. Энәне янәшәдәге сәйләннәр аша йөртеп, җеп очын төенлибез, яшерәбез. Әзер кулонны көмеш чылбырга элеп, дус кызларыбызны кызыктырырга йөгерәбез. Муенса күн бауда да бик матур күренәчәк.






■ Өченче рәтне башлыйбыз. Максатыбыз – икенче рәтне тезгәндә буш калган араларга сәйлән тезү. Кечерәк сәйлән эләктереп, энәне янәшә торган сәйлән аша уздырабыз. Шул рәвешле рәтне чыкканчы дәвам итәбез.

Сәйләннәрне тезеп бетергәч, энәне янәшәдәге сәйләннәр аша йөртеп, җеп очын төенләп яшерәбез.


Нык булсын, сәйләннәр таралып китәрлек булмасын.

■ Аскы рәтне башлаганда энәне күн белән фетр арасыннан кадап (төене күренмәсен!), уң якка тартып алабыз һәм бер үк зурлыктагы ике сәйлән эләктереп, энәне тартып алган эздән үк кире сул якка чыгарабыз. Сәйләннәр тигез ятмый әле, шуның өчен энәне аста торган сәйлән аша уздырып, кылны тарттырабыз. Икенче атламда бер генә сәйлән эләктереп, энәне сул яктан кадап алабыз һәм шул ук сәйлән аша уздырабыз. Энә эзе күн читеннән 2 мм эчтәрәк булсын.


Икенче рәтне тезү схемасы



беренче атлам



икенче атлам



ИТЛЕ «КАБАРТМА»ЛАР



Йолдызлы мастер-классыбызны дәвам итәбез. Бүген бездә — җырчы Айгөл БАРИЕВА. Ул безгә үзенең «фирменный» ризыгын әзерләргә өйрәтәчәк. Айгөл яшүсмер чагыннан ук пешеренергә яраткан. Кибетләрдә бүгенгедәй муллык булмаган заманнарны искә төшерәбез. «Хәтерлисезме, элек «персиклар» пешерә торган идек! — ди Айгөл. — Печенье камырыннан вак-вак йомыркалар ясый идек тә, аның эчен куышлап, куертылган сөт тутыра идек. Әле сөтне дә үзебез пешерәбез. Аннан йомыркаларны чөгендер белән кишер сутына манып, шикәр онында әвәли идек. Чын персик сыман була торган иде...» Үзе җитез, үзе үткен, үзе шаян җырчы кызыбыз бүген исә тиз әзерләнә торган итле карабодай кабартмалары пешерү серен ачачак.



Кирәк:

- 0,5 кг ит фаршы;
- 0,5 стакан карабодай ярмасы;
- 1 баш суган;
- 2 кишер;
- 3 тырнак сарымсак;
- 2 аш кашыгы томат пастасы;
- яшел тәмләткечләр;
- үсемлек мае;
- тоз-борыч;
- 0,5 стакан кайнаган су.

Эш барышы:



■ Карабодай ярмасын кайнап торган тозлы суда пешерәбез. Ул пешкән арада ит фаршына суган, тоз-борыч, бер йомырка кушып, яхшылап болгатабыз. Карабодайны да ит янына кушабыз, барысын бергә бутап, артык зур булмаган «кабартма»лар әвәлибез.



■ Суганны ваклап турап, кишерне эре угычтан уабыз. «Кабартма»лардан бушаган табага янә бераз май тамызып, яшелчәләрне кыздырабыз. Бераздан ваклап туралган сарымсак өстибез. Томат пастасын ярты стакан су белән сыеклап, кыздырма өстенә салабыз, тоз-борыч сибәбез.



■ Табаны кыздырып, бераз үсемлек мае салабыз һәм сыйган кадәр «кабартма»ларны тезәбез. Башта бер ягын, аннан, әйләндереп, икенче ягын да кызартып алабыз. Әзер «кабартма»ларны бер тәлинкәгә алып, читкә куеп торабыз.



■ «Кабартма»ларны кыздырма өстенә тезәбез һәм капкач белән каплап, сүрән генә ут өстендә парландырабыз. 15-20 минуттан туклыклы да тәмле дә «кабартма»ларыбыз әзер.



■ «Кабартма»ларны яшел тәмләткечләр белән бизәп, табынга чыгарабыз. Янына гарнир да бирергә була. Айгөл Бариева уздырган мастер-классның видеоязмасын «Сөембикә» журналының сайтыннан (www.syuyumbike.ru) карый аласыз.

БӘЙГЕДӘ КАТНАШ ТА, БҮЛӘК ОТ!

«Сөембикә»дә өр-яңа бәйге! Җиңүчеләр ике номинациядә бүләкләнәчәк. Беренче номинация — «Ә дигәнче» дип атала. Бу номинациядә тиз генә әзерләп табынга куя торган ризык рецептлары тәкъдим ителә. Икенче номинация — «Тавык итеннән» дип атала, һәм, исеменнән үк күренгәнчә, бу номинациядә тавык итеннән әзерләнгән ризыклар белән катнаша аласыз. Һәр номинациядә бишәр җиңүче билгеләнә. Конкурсның иганәчесе — «Пестречинка» ҖЧҖ.

Конкурсның шартлары:

■ сез җибәргән рецепт буенча әзерләнүче ризык, әлбәттә, тәмле һәм үзенчәлекле булырга тиеш;

■ бу ризыкны әзерләү өчен ниләр кирәклеге төгәл күрсәтелсен;

■ аны пешерү тәртибе эзлекле бирелсен;

■ әзер ризыкның фотосы булсын (jpg форматында, зурлыгы 5 мигабайттан ким булмасын);

■ исем-фамилиягезне, кайдан, кем булуыгызны языгыз (бу ризыкка бәйле берәр кызыклы тарих язсагыз да була);

■ үзегезнең фотогызны җибәрегез;

Конкурска килгән рецептлар «Сөембикә» журналында, рәсми сайтыбызда һәм социаль челтәрләрдәге сәхифәләрдә урын алачак. Конкурс өч этапта уза. Беренче ике этапта иң-иң тәмле, иң-иң оригиналь рецептлар лайклар һәм репостлар ярдәмендә ачыкланса, өченче этапта җиңүчеләрне редакция хезмәткәрләреннән торган жюри билгеләячәк. Җиңүчеләрне «Сөембикә» журналыннан матур бүләкләр һәм дипломнар көтә.

Бәйгедә катнашуның төп шарты — «Сөембикә»гә язылу. Икенче яртыеллыкка язылу инде башланды. Рецептыгыз белән бергә журналга язылу квитанциясенең күчермәсен җибәрергә онытмагыз!

Айның барча тереклеккә тәэсир көчен беркем дә инкарь итмәс. Ай тулган яки яңа Ай туган көннәр иң авыр көннәрдән санала. Шуңа да бу көннәрдә үсемлекләргә кагылмавың хәерле. Үсеп килүче Айда үсемлекләр югарыга үрелә. Ә инде Ай кимүгә барса, киресенчә, бөтен көч тамырларга күчә. Чәчү өчен иң кулай көннәр — Ай Чаян, Кысла һәм Балык йолдызлыгында булган көннәр. Без тәкъдим иткән таблицада үсемлекләрне чәчү, күчереп утырту көннәре бирелә.



АЙНЫҢ ЮМАРТ КӨННӘРЕ

ҮСЕМЛЕКЛӘР	ФЕВРАЛЬ (3-5 — тулы Ай; 18-19 — яңа Ай)	МАРТ (4-5 — тулы Ай; 20-21 — яңа Ай)	АПРЕЛЬ (3-4 — тулы Ай; 18-19 — яңа Ай)	МАЙ (4 — тулы Ай; 17-19 — яңа Ай)	ИЮНЬ (2-3 — тулы Ай; 15-17 — яңа Ай)
Борыч, баклажан, томат	1, 27, 28	1, 28	3, 30	3, 30, 31	1, 25-28
Бәрәңге	–	7-12	5-9	5-9	3-5
Бакча җиләге	10, 11	9-11	6, 7	–	8
Башлы суган, сарымсак	–	9-12	6-11	5-9	3-5
Борчак, фасоль	–	–	13, 30	1-3, 28-31	26-28
Кыяр, карбыз, кавын	1, 27, 28	1, 26, 28	23, 24	20-22	17, 18
Кабак, ташкабак	1, 27, 28	1, 28	3, 30	1-3, 28-31	25-28
Кәбестә	23, 24	22, 23, 26	19-20, 23, 24	20-22	17, 18
Кишер, чөгендер, тамыр сельдерей, тамыр петрушка	7-11	7-11, 18, 19	5-7, 15, 16	12, 13, 16, 17	8
Кыяк суган	21, 22	21	–	3, 30, 31	26-30
Порей суганы	1, 21, 22, 27, 28	1-21, 24-28	21-24	3, 19-22, 30, 31	26-28
Редис, шалкан, ачы торма	7-11	7-12	5-7, 10, 11	5-9	3-5, 8
Суганчалы чәчәкләр	10, 11	21-23, 25, 26	6-7, 10, 11	7-9	4, 5, 8
Орлыктан үсүче чәчәкләр	1, 27, 28	1, 4, 24-28, 31	1-3, 23, 24, 28-30	1, 2, 20-22, 25-29	17, 18, 21-25
Укроп	1, 25-28	1, 4, 24-28, 31	1, 2, 21-24, 28, 29	3, 19-22, 25-27, 30, 31	17, 18, 21-23, 26-28
Утырту өчен уңайсыз көннәр	17-19	16, 17, 20	12-14, 18	10, 11, 18	6, 7, 16


КУЧКАР. Иллюзияләрдән арыныгыз. Алар тормышны дөрес кабул итәргә комачаулый. Айның беренче чиреге мөһим вакыйгалар белән узар. Эшләрегез уңышлы бара. Шәхси мөнәсәбәтләргә игътибарлы булыгыз.


ҮГЕЗБОЗАУ. Романтик хисләр бөтереп алыр. Хыялыгызга якынаясыз. Барысы да тормышка ашмаса да, күңелегезгә канәгатьләнү иңәр. Иҗади күтәрелеш котелә, ул тормышыгызга мавыктыргыч төсмер бирер. Шәхси өлкәдә аңлашылмаучанлык булуы ихтимал.


ИГЕЗӘКЛӘР. Бөтен мәсьәләләр тиз генә хәл ителәчәк. Көчегез күп, барысына да өлгерерсез. Бу айда тормышыгыз гөрләп барыр, күңелле вакыйгалар көтелә. Яңа танышлар барлыкка килер.


КЫСЛА. Язмыш сезне төрлечә сынап карарга ниятли, ахрысы. Мөһим эшләрегез муеннан. Болар бар да көч һәм тәвәккәллек таләп итә. Авырлыклардан курыкмагыз, алар сезне чыныктыра гына. Булдыра алмастай эшләргә тотынып, көчегезне әрәм итмәгез.


АРЫСЛАН. Максатыгызга ирешү өчен бар булган көчегезне куячаксыз. Нәтиҗәсе дә куанырлык. Сездәге көч, сездәге тәвәккәллек! Абруегыз күтәреләчәк. Тормышыгыз уңай якка үзгәрер. Әмма ике эшкә берьюлы тотынмагыз, оттырырсыз.


СӨМБЕЛӘ. Ай башында мөһим карар кабул итәргә туры килүе бар. Алга таба язмышыгызны үзгәртердәй карар булачак. Мең кат уйлап эш итегез. Тормыштагы урыныгызны ныгытырдай мөмкинлек күренер, әмма аны кабул итәсез икән, сынауларга әзер торыгыз.


БИЗМӘН. Күңелле дә, файдалы да яңалык ишетерсез. Ай башында эшлекле очрашулар, яңа танышулар көтә. Күңелегез күтәренке. Ерак юлга чыгарга ниятләсәгез, моның өчен иң яхшы вакыт – ай башы. Ай уртасында четерекле эш башкарырга туры килер.


ЧАЯН. Тормышның һәр өлкәсендә уңыш елмаер. Айның икенче яртысы тормышка үзгәреш кертү өчен яхшы вакыт. Хезмәте иҗат белән бәйле кешеләрнең күңел кылларын илһам тибрәтер. Иң мөһиме – ялкауланмау.


УКЧЫ. Мәхәббәт өлкәсендә бераз давыллап алырсыз. Әмма юкка борчыласыз, сюрпризлар булса да, алар сезнең өчен бары куаныч кына китерәчәк. Финанс ягы да куандырыр. Артыгын ашыгып, каударланмасагыз, эшегез өчен югары бәя алырсыз.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Яңа мөмкинлекләр ачылачак, яңалыклар бәреп керәчәк. Тормышны үзгәртергәме яки искечә калсынмы дигән сайлау алдында калырсыз. Зурракка да ирешә ала идем бит дигән булсагыз, бу айда моңа ирешү өчен форсат чыгачак.


СУКОЯР. Мәгълүмат ташкыны астында калырсыз. Кайсысының ялган, кайсысының чын булуын аеру кыен. Якын кешегезнең кыңгыр эшкә тартып кертүеннән сакланыгыз. Мәхәббәт өлкәсендә бераз киеренкелек булса да, кайгырмагыз, бу вакытлыча гына.


БАЛЫК. Күңелегез күтәренке, үзегезгә ышанычыгыз зур. Тормышыгыз бер эздән генә баруын дәвам итә, зур үзгәрешләр көтелми. Күп кенә хыялларыгыз тормышка ашачак. Дәрәҗәгезне белеп, тирә-юньдәгеләрнең сүзенә бирешмәсәгез, бу иң уңышлы ай булырга охшаган.

Февральдә кабынган йолдызлар

Татарстан



Ания ФӘТТАХОВА (5.02.1940–10.03.2000) – **театр артисты.**
Минзәлә районының Аю авылында туа. 1960 елда Алабуга сәнгать училищесын тәмамлый. Минзәлә театрының баш режиссеры Сабир Өметбаев студент кызның җырлавына таң калып, үзләренә эшкә чакыра. Беренче роле – Хәят (Ф. Әмирхан «Хәят»), икенчесе – Мәйсәрә (К. Тинчурин «Зәңгәр шәл»). Матур тавышына күрә, аңа күбрәк җырлы рольләрне тапшыралар. Авыруы сәбәпле, берара сәхнәдән китеп тә тора – театрда постановка бүлеге мөдире булып эшли. Әмма аз гына хәл алуга, янә сәхнәгә ыргыла. 1996 елда ире Мәүҗит Фәттахов (ул да ТР атказанган артисты) белән Түбән Кама театрына күчәләр. ТАССРның атказанган (1974), ТР халык артисты (1990).

Россия



Валентина ТЕЛЕГИНА (10.02.1915–4.10.1979) – **актриса.**
Новочеркасск шәһәрендә туа. 1937 елда Ленинград сәнгать институтын тәмамлап, Ленсовет исемендәге театрга эшкә урнаша. Кино сәнгатендә – 1934 елдан. Беренче зур роле – Сергей Герасимов куйган «Комсомольск» фильмында Мотя Котенкова. Сугыштан соң М. Горький исемендәге үзәк киностудиядә эшли. Аның героинялары – гади хатын-кызлар. Ул үзе дә: «Гомер буе бер генә роль уйнадым – гади рус хатынын», – дияргә яраткан. Тискәре геройларны башкарырга каршы торуы да билгеле. Тамашачы мәхәббәтен казанган «Дело было в Пенькове» фильмындагы көмешкәче хатын роленә озак ялынганнан соң гына риза була. РСФСРның халык артисты (1974).

Чит илләр



Сибилл ШЕПЕРД (18.02.1950) – **актриса.**
Американың Мемфис шәһәрендә туа. Унсигез яшендә Нью-Йоркта «Ел моделе» исеменә лаек була, АКШның мода йолдызы булып танылa. Лос-Анджелеста Калифорния университетын тәмамлый. Актриса булып китүенә исә бер бәхетле очрак «гаепле». 1970 елда яшь режиссер Питер Богданович «Соңгы киносеанс» фильмына актерлар җыя. Газета-журналлар киоскы янынннан үткәндә бер журнал тышлыгында Сибиллның фотосын күреп, аның нәкъ үзе эзләгән кеше булуын аңлый. Фильм уңышлы килеп чыга. Сибиллның аннан соңгы «Йөрәк яралаучы» фильмы да уңыш казана. «Таксист» фильмындагы роле – иң уңышлы эшләренең берсе.





БАЛЧЫК СЫН ДА ЕЛМАЯ...

Казандагы Ленин бакчасы каршындагы матур бинага урнашкан «Сәнгать кибете»н күпләр хәтерли булыр. Картиналар, батиклар, көмеш әйберләр эргәсендә тезелгән керамик вазаларга сокланып торган кешеләр керамика остасы Андрей Махинин исемен дә искәргәннәрдер. Хәзер сәнгати керамика бик дәрәҗәдә түгел кебек, чөнки теге яки бу илнең сәнгате хакында сүз барганда, сәнгать белгечләре күбрәк архитектураны, рәсем сәнгатен анализларга керешә. Югыйсә чүлмәк ватыклары археологларның иң яраткан табылдыгы лабаса. Бу хәл кайвакыт күңелсез бәхәсләр дә китереп чыгара. Әйтик, борынгы Кытай сәнгате хакында сөйләнгән хезмәттә керамика, ефәк турында әйтергә «онытканнар». Ә без менә җирле сәнгатебез белән таныштырганда Андрей Махинин исемен горурланып атый алабыз.

Бу оста Казанда яши, ә һөнәри белемне Ригада алган. Шуңа күрә аның иҗатында латыш сәнгати керамика мәктәбе нык сизелеп тора. Аның керамикадан ясалган әйберләре өчен этник компонентлар муллыгы, нингдидер әдәби җирлек булу хас. Латыш керамикасының йогынтысы техник алымнар сайлауда гына түгел, бәлки, гадәти тормыш кирәк-яракларын файдаланып яшәгән кешеләрнең дөньясын аңларга тырышуда да чагыла. Андрей Махинин образларны ачу өчен вак детальләрне файдалана белә. Әйтик, иске диванда йомарланган песи, урынсыз тагылган бишмәт төймәсе – кешенең холкын ачу өчен кирәкле вактөякләр рәтеннән.



Казан университетында алынган филолог белгечлеге рәссамга кешеләр тормышын, бигрәк тә «бу бәйрәмдә чит булган» кечкенә кешеләр дөньясын аңларга ярдәм итәдер.

Ләкин Андрей Махининнның керамик панноларындагы «кечкенә кеше»не без үзендә гадилек белән наивлыкны бергә кушкан, әмма үз дәрәҗәсен белә торган акыллы кеше итеп күрәбез. Бу эштә, әлеге дә баягы, вак детальләр ярдәм итә.

Андрейның чүлмәктән ясалган персонажларына ниндидер фаҗигалелек хас түгел. Киресенчә, аларда җиңелчә юмор төсмерләнә, аның балчыкны әвәләп ясаган әйберләреннән җылылык бөркелеп тора. Аларда кешене сагайта торган кискен почмаклар юк. Барысы да ашыкмыйча гына, уйлап кына ясалган кебек. Оста кулында гадәти үзле балчык тукыма, күн, металл кебек төрледән-төрле материалларның фактурасын тапшырырга сәләтле.

Андрей Махинин кулы тигән балчык эшләнмәләр лиризм белән аерылып тора. Рәссамның күп мәгънәле булырга тырышмавы, формализм белән мавыкмавы да кешеләр күңеленә хуш килә. Бәлки, шуңадыр да интернетта Махинин керамикасы белән сокланучылар матур-матур шигырьләр язып калдыра. Димәк, рәссамның керамикасы иң нечкә кылларны тибрәтергә дә сәләтле. Остаың үрнәге, бәлки, яңа осталарны кытай фаянсын кысрыклардай сәнгати әйберләр иҗат итәргә рухландырыр.

Римма БАЖАНОВА,
философия фәннәре кандидаты.




АНДРЕЙ МАХИНИН



ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРГА АРЗАН БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫП КАЛЫРГА АШЫГЫГЫЗ!

26 февральдән 7 мартка кадәр «Россия почтасы» газета-журналларга язылу ункөнлеге үткәрә. Әлеге ункөнлектә, федераль массакүләм мәгълүмат чаралары белән беррәттән, төбәкнекеләр дә катнаша. Төбәкләрдә чыгучы газета-журналларга узган яртыеллыкта булган язылу бәясеннән дә арзанракка язылып булачак. Бу ун көн дәвамында журналга язылучыларга «Сөембикә» 10 процент ташлама ясый. «Россия почтасы» исә язылу барышында федераль басмаларга тагын 5 процент, төбәктәге басмаларга 10 процент ташлама вәгъдә итә. Димәк, «Сөембикә» журналына узган яртыеллыктагы бәядән 20 процентка арзанракка язылырга мөмкин!

- Исегезгә төшерәбез: хәзер «Сөембикә» журналының электрон версиясенә дә язылырга мөмкин. Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен бу «Сөембикә»гә язылу өчен бердәнбер мөмкинлек! Россиянең ерак регионнарында һәм БДБ илләрендә яшәүче укучыларыбызга журналны PDF-форматта алдыру арзангарак төшәчәк, чөнки моңа почта чыгымнары өстәлмәгән.
- Электрон версиягә язылганда, почта бүлегенә барып, чиратлар тору мәшәкате дә читләп үтә: үзегезгә кайчан җайлы, шул вакытта интернет-сайтка керәсез, банк картасы яки «электрон акча» белән тиешле сумманы күчерәсез. Компьютерның нибары берничә төймәсенә басу җитә! Һәм яңа саннар укучыга күпкә тизрәк барып җитә – чөнки язылучының компьютерына алар, урау юллар үтмичә, журналның басма варианты типографиядән чыгып өлгергәнче үк килеп ирешә. Чит төбәкләрдә яшәүче укучылар өчен монысы бигрәк тә мөһим булыр.
- Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала. Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (www.syuyumbike.ru).
- Сайтыбызда журналның басма вариантына да язылып була. Ашыгыгыз!



16+